Безнең Мирас

НАШЕ НАСЛЕДИЕ

6

июнь 2021

ISSN:2500-011X

КЫЗЫКЛЫ ТАБЫШЛАР ● КАДЕРЛЕ ИСТӘЛЕКЛӘР ● ГЫЙБРӘТЛЕ ЯЗМЫШЛАР

Түбән Варта шәһәре татарлары
18 бит

ТАССРда беренче Сабан туйлары
22 бит

Ык буенда җил исә...
37 бит

ЗӘКИ НУРИ, ГАБДЕЛХӘЙ САБИТОВ, СИБГАТ ХӘКИМ. 1959 ЕЛ

Каләм! Калъбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Дәрдемәнд

Безнең МИРАС 12+

6
(330)
июнь 2021

Фәнни-популяр, әдәби-нәфис
һәм документаль журнал

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исеме белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

Баш мөхәррир
Ләбиб Лерон улы ЛЕРОНОВ (Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-85 (17-92)

Баш мөхәррир урынбасары
Фирдәвес Зарифуллина (Фирдәвес Зариф)
(843) 222-09-85 (17-93)

Киңәшче идарә

Ирада Әюпова
(ТРның мәдәният министры)
Айрат Зарипов
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Айдар Сәлимгәрәев
(«Татмедиа» Республика Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе)
Васил Шәйхразиев
(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)

Редколлегия

Альберт Борһанов
Рәмил Вәлиев
Радиф Җамалетдинов
Фәнилә Җәүһәрова
Фәйзелхак Исламов
Зиннур Мансуров
Хатыйп Миңнегулов
Ким Миңнуллин
Рузил Мөхәммәтшин
Григорий Родионов (Гәрәй Рәхим)
Данил Салихов
Индус Таһиров
Данис Шакиров
Ирек Шәрипов
Илдар Шәфыйков

Җаваплы мөхәррир
Ленар Гобәйдуллин
89196911406

Дизайнер һәм битләп салучы
Алмаз Фәйзуллин
(843) 222-09-85 (17-92)

Мөхәррир
Лейсән Данилова
(843) 222-09-85 (17-91)

Сайт мөхәррире һәм корректор
Зилә Хәсәнова
(843) 222-09-85 (17-93)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы,
2 нче йорт
Электрон почта: yanamiras@mail.ru
Сайт: beznenmiras.ru

«Безнен мирас» (Наше наследие)
Ежемесячный научно-популярный,
литературно-художественный журнал
(на татарском и русском языках)

Эчтәлек

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 Габделхәй Сабитов

ТАРИХИ МИРАС

4 Тимербәкнең ил-йортына сәяхәт (1404-1406) көндәлеге. *Руи Гонсалес де Клавихо*
8 «Җиде тотам ук атты...» *Л.Гобәйдуллин*
10 «Әй шәкертләр, ваемсыз булмагыз!» *Р.Мәрданов*
13 Кабиләчелек низаглары. *Ф.Әмирхан*
18 Түбән Варта шәһәре татарлары. *Ф.Бәйрәмова*
22 ТАССРда беренче Сабан туйлары. *Р.Шәрәфиева, Л.Гобәйдуллин*
26 Ачлык падишаһлыгы (Спас кантоны). *Ф.Сәйфи-Казанлы*
30 Кульязмалар табып булмасмы? Кульязмалар!.. *М.Госманов*

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны һәм фотоларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми.
Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенең 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон тәкъдим иткән, авторлардан һәм «Татар-информ»нан, Татарстан Милли музееннан, «Татар энциклопедиясе» тупланмасыннан, шулай ук «Татар тарихы»ннан алынган фотосурәтләр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

ТАТАР ГАМЕ

34 Мөслим турында уймак уйлар. *Р.Муллин*
37 Ык буенда җил исә... *Х.Әюп*
38 Төбәкне өйрәнүчеләр җыены
40 Ык елгасы үзәнлеге – ачылмаган тарих. *А.Борһанов*
43 Мөслим авылы метрикәләре. *З.Нәҗметдинов*
47 «Безнең мирас» котлый!

ДИНИ МИРАС

48 Ислам дөньясы. *Габдерәшит Ибраһимов*
55 Үтәмеш: дини хәрәкәт. *Н.Исхаков, Р.Исхакова*

ӘДӘБИ МИРАС

60 Сәйф Сараи лирикасыннан мисаллар. *Х.Миңнегулов*
64 Дөррәт әл-фахирә яки Ахирәтнамә. *Г.Утыз-Имәни*
70 «Кайсыгызның кулы җылы?» *Р.Ахунҗанова*

ХӘТЕР САНДЫГЫ

72 Мөслим бабай варислары. *Р.Хәбибуллина*
80 «Истәлек итеп сакларсың!» *Э.Сәлахова*
86 Каракош. *Э.Шәрифуллина*
92 Кара тәкъдир. *Р.Батулла*
94 Истә, һаман да истә!

ТЕЛ КҮРКЕ – СҮЗ

96 Матбугат һәм туган тел. *Р.Юсупов*

СӘНГАТИ МИРАС

102 Онытылмасын Гай бабай. *Ә.Зарипов*
106 Татар җырчылары. Кадерле мизгелләр. *З.Гыйльметдинова*
108 «Баламишкин» җыры
110 Милли музейда – ПЕ-2 самолеты. *Л.Нәгыймов*

ШАЯН МИРАС

112 Көлке куа килә...

БАЛАЧАК МИРАСЫ

114 Без барыбыз да – балачактан

116 «Безнең мирас» хәбәрләре
118 Мирасворд
119 «Безнең мирас» елъязмасы. *Июнь*

Заказ №Е-1685. Тираж – 3222 данә. Формат 70х100 1/16
Басарга кул куелды: 26.05.2021. Чыгу көне: 31.05.2021.
Айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Тышлыкның беренче битендә:
Зәки Нури, Габделхәй Сабитов, Сибгат Хәким. 1959 ел

Минем язганнарымны укыгач, сездә бер агач, һичьюгы, бер чәчәк утырту теләге уянса, үземне бәхетле санар идем.

Габделхәй Сабитов

Салда сәяхәт. Сулда – Габделхәй Сабитов. 1967 ел

ГАБДЕЛХӘЙ САБИТОВ

(1931-1995)

Уч төбемдә ипи валчыгы. Карыйм да уйланам. Ипекәй, син – тереклек чыганагы. Ипекәй, син – тән-әгъза куәте, игенченең буразнага тамган маңгай тире.

***

Беркайчан да тикмәгә генә тумыйдыр ул адәм баласында хис-тойгылар. Сабый чактан ук йөрәгеңне бер көйдереп узмаса, туган кадәресе дә бик сай буладыр, сусыз инеш кебек коры, алдагы тормыш өчен яраксыз буладыр.

***

Кадерле ул туган як. Кешегә генә түгел, хайванга да изге ул туган җир туфрагы.

***

Кеше бәхетенә кызыгып, кеше яккан утка кызыгып яшәү егет эше түгел.

***

Ат белән хатын дигән мал, китсә дә, кайта ул.

***

Ак болытлар, ак болытлар! Гомерем буена юлдаш булды алар миңа. Урманнарда йөрсәм, яфракларны аралап, зәңгәр күктән эзләдем. Су коенсам, дулкыннарга чалкан ятып, һаман күккә бактым. Җырласам, җырларыма керде шул өем болытлар, ятсам – төшләремә.

***

Җир-анага рәхмәт йөзеннән җылы туфракка бирәр орлык күмгәнең бармы? Шул хакта уйланыйк, дип яздым әсәрләремне.

Текстны журналга
***Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Тимербәкнең ил-йортына сәяхәт (1403-1406) көндәлеге

Руи Гонсалес де Клавихо

Дәвамы. Башы журналның 2 нче (2021) санында.

Бу җирләр бик бәрәкәтле – икмәккә, мал-туарга, йөземгә, җиләк-җимешкә, кош-кортка бай; курдюклы сарыклары шундый зур күренә, курдюгы кулга чак күтәреп торырлык, егерме футлар бардыр. Сарык көтүләре иксез-чиксез, ите дә арзан, Тимербәк яу сәфәрендә чакта ике бәрән бер дукат торган. Бүтән тауарлар да кыйммәт йөрми. Ипи хакы шулкадәрле арзан ки, аннан да арзанрак булуы мөмкин түгел. Дөяләр бик күп. Мондагы муллыкка хәйран калырлык. Шуңа күрә дә кала Сәмәрканд дип аталган. Аның дөрес исеме – Симезканд, ягъни симез, бай шәһәр, менә шуннан Сәмәрканд булып киткән. Бу илнең байлыгы ашау-эчү ризыкларының муллыгында гына түгел, монда ефәк, атлас, камка, тафта тукымалар эшләнә, тире-мех эшкәртелә. Тимербәк Сәмәркандны дөньяның беренче шәһәре итәргә тели, шуңа күрә яулап алынган илләрдән ул бик күп кешеләрне, бигрәк тә һөнәрчеләрне күпләп алып кайта.

Дәмәшекътән ул һөнәрчеләрне җыеп Сәмәркандка җибәртә: тукучылар, ук-җәя ясау осталары, пыяла, чүлмәк ясаучылар – Дәмәшекъ осталары – дөнья бәясе тора. Төркиядән ул нинди генә һөнәр ияләрен сайлап алып кайтмый: арбалетчылар, ташчылар, алтын-көмешчеләр – күпмесен кулга төшергән, барысын да үзенә тарткан. Шуңа күрә Сәмәркандта теләсә нинди һөнәр иясен табарга була. Моңа өстәп, ул яуда куллана торган таш, «грек уты» аттыру машиналары ясау осталарын, аңа аркан ишүчеләрне, тупчыларны да алып кайткан. Төрле халыктан, төрле илләрдән Тимербәк тарттырган кешеләрнең саны, ирләрне дә, хатын-кызларны да санап, йөз илле меңгә җитә, диләр. Болар арасында төрек, гарәп, мавр, әрмән һәм грек католиклары, нәсарилар һәм якобитлар, биткә ут бөркеп чукындыру ритуалын үти торган, дингә үзенчә карашлы христианнар да бар.

Бу чуар халык, шәһәргә, аның мәйданнарына, тирә-юньдәге авылларга гына сыеша алмыйча, тау куышларына кадәр урын алган.

Сәмәркандка төрле тарафлардан тауар агылып килә: Рушия (Русь?) һәм Тарталиядән күн-тире, киндер тукыма, Кытайдан ефәк, андый да затлы атлас-ефәк тукыма, бигрәк тә бизәксезе, Кытайныкы кебек сыйфатлы итеп дөньяның бер илендә дә эшләнми. Моннан кала, мускус (фәкать Кытайда гына эшкәртелә) китерелә. Шулай ук асылташлардан якут, алмаз, энҗе; рәвән һәм башка шундый ашка сала торган тәмләткеч үләннәр дә Кытайдан килә. Иң шәбе, иң кыйммәтлесе – Кытайдан китерелгән тауарлар. Кытайлар – ике күзле, франклар – бер күзле, ә маврлар тома сукыр була, шуңа күрә дә без, кытайлар, иң булган, иң оста халык, ни кылсак та, дөнья халыкларын уздырабыз, диләр кытайлар үзләре хакында.

Һиндстаннан монда иң затлы тәмләткечләр китерелә: мускат чикләвеге, канәфер, мускат чикләвеге кабыгы, дарчин, имбир кебек Александриягә килеп җитми торган бик күп нигъмәтләр. Шәһәрдә тозлаган, пешкән, төрлечә кыздырылган ит сата торган мәйданнар күп. Тәмләткечләр кушып әзерләнгән кош-корт итләре, камыр ризыклары, яшелчә сатыла торган бөтен урында да чисталык, пөхтәлек күзгә ташлана. Шулай ук яңа суелган эре мал, тавык, фазан итләре сата торган урыннар көнен дә, төнен дә эшли.

Шәһәрнең бер башында замок (сарай) тора, ерактан караганда, ул тигез урынга салынган шикелле, чынбарлыкта исә тирән сулы канау белән каймалап алынган. Тимербәкнең монда казна байлыгы саклана. Анда, шәһәр башлыгы һәм аның яраннарыннан кала, берәүгә дә керергә рөхсәт ителми. Шушы замокта ул әсирлеккә алынган меңләп останы – гаскәриләргә көбә кием, башлык, ук-җәя ясаучыларны ел әйләнәсе эшләткән.

Тимербәк Төркияне, Дәмәшекъне яуларга сәфәр чыгар алдыннан гаскәриләренә хатыннарын да үзләре белән алырга кушкан. Әгәр калдырып китәсез икән, хатыннарыгыз теләсә ни эшләргә хаклы, дигән. Ни өчен болай эшләгән, чөнки ул дошманнарын тар-мар итеп, Сәмәркандка җиде елдан соң гына кайтачагын белгән. Һәм ул бу замокка да җиде елдан соң гына керәчәгенә ант итеп, сүз биреп киткән. Хәзер инде менә Тимербәк Сәмәркандка әйләнеп кайткач, Кытай императорыннан илчеләр килеп җитеп, аның идарәчелегенә бу җирләрнең бирелүен, һәр ел саен ясак түләргә кирәк икәнен, инде җиде ел буена бер тиен дә түләнмәвен исенә төшергәннәр. Бәк аларның хаклы икәнен таныган, түләячәген, әмма илчеләргә юлда әрәм-шәрәм итәрләр дип ясакны бирергә теләмәвен, императорга үз кулы белән илтеп бирәчәген искәрткән. Әлбәттә, түләргә исәбе булмаганга, ул шулай шаярткан. Хәзер инде сигез ел вакыт узган, ә Кытай императорыннан ясак таләп итеп килүче күренмәгән. Моның сәбәбе нәрсәдә?

Кытай императоры өч улына үзе биләгән җирләрне калдырып үлеп китә. Олы улы, бөтен биләмәләрне үзенә эләктерергә теләп, кече энекәшен үтерә, уртанчысы абыйсына каршы сугыш ача һәм җиңеп чыга. Абыйсы, үзеннән яшьрәк энекәшенең өстенлек алуына гарьләнеп, үзенең ыстанына ут төртә, үзе дә, кешеләре дә янып үләләр, шулай итеп уртанчы ул илбашы булып кала. Илҗирендә тәртип урнаштыргач кына, ул, ясак түләвен таләп итеп, Тимербәк катына илчеләрен җибәрә. Алда әйтеп киткәнчә, нәкъ менә шул илчеләрне Тимербәк асып үтертергә җыенган иде, бу намуссызлыкка карата Кытайның илбашы нинди җавап бирәчәген хәзергә без әйтә алмыйбыз.

Сәмәркандтан алып Кытайның башкаласы Ханбалыкка кадәр җәяүләп алты ай барырга кирәк, ике ай буена тирә-юньдә бер генә җан иясе дә очрамый, аратирә генә мал көтүчеләрне күрергә мөмкин. Быелның июнь аенда Ханбалыктан Сәмәркандка тауар төялгән сигез йөз дөя килде.

Тимербәк яу сәфәреннән кайтып төшеп, Кытай илчеләренең фәрманын белгәч, бик нык ачуы килеп, дөя кәрванын тоткарларга ниятли.

Ханбалыктан дөя кәрваны белән килүчеләр испан илчеләренә император биләгән Кытай илендәге могҗизалар турында сөйләп туймадылар. Ә берсе болай диде: ул яши торган кала диңгез буенда икән, дөнья йөзендә иң зур кала, егерме Тәбризгә торырлык, ди. Тәбризнең бер ягыннан икенче ягына кадәр бер лига булса, аның шәһәренең зурлыгы егерме лига икән. Кытай императоры шулкадәр зур гаскәр тота, ди, яуга туплап алып киткәннән соң, илне саклаларга калган атлы гаскәре генә дә дүрт йөз меңнән арта, ди. Император шундый тәртип керткән: үз карамагында меңнән дә ким кеше тота алмаганга, атка атланып йөрү тыела икән. Ә атка атланып йөрүчеләр бихисап, ди. Бу ил турында нинди генә гаҗәп хәлләр сөйләп бетермәделәр. Император башта мәҗүси булган, хәзер инде христиан диненә күчкән.

Илчеләр Сәмәркандта чакта Тимербәкнең казна йортына җиде елдан соң гына керәчәкмен дигән антының вакыты чыкты. Гаҗәеп тантаналы көн булды ул. Шул еллар эчендә әсир осталар тарафыннан ясалган коралларны Тимербәк каршыннан күрсәтеп үттеләр. Болар арасында кызыл постау белән бизәлгән өч мең пар көбә кием бар иде: монда тимерне чыныктыра белмиләр, шуңа күрә, матур эшләнсә дә, ныклыгы чамалырак була. Аннары бәк каршыннан бик күп очлымнарны күрсәтеп уздылар. Боларның барысын да Тимербәк үзенең гаскәриләренә таратырга кушты.

Очлымнары түгәрәк, биек итеп эшләнгән, ике бармак иңлегендәге тимер тасма ияккә кадәр төшеп тора, кирәк чакта күтәреп тә, төшереп тә куярга була. Кылыч белән аркылы кизәнгән вакытта саклану өчен ясыйлар аны. Көбә күлмәкләр бездәге кебек эшләнгән, тик итәге генә икенче тукымадан, көбә астыннан киелгән күлмәк кебек тора.

Кытай тарафында, Сәмәркандтан унбиш көнлек юл өстендә, амазонкалар яши торган җир бар. Ирләрсез генә яшәү йоласын алар бүгенге көнгә кадәр саклап калганнар. Елның билгеле бер фасылында башлыклары рөхсәт бирә дә, амазонкалар, җиткән кызларын да үзләре белән алып, күрше җирләргә чыгып китәләр. Ир-атлар, боларны күргәч, тәкатьсез калалар. Амазонкалар, кайсы ир-ат ошый, шуның белән калып, ашап-эчеп, күңел ачып, истирахәт кылалар. Аннан соң инде үз җирләренә кайтып китәләр. Кыз туса, үз янында калдыралар, малай туса, әтиләре янына озаталар. Бу хатын-кызлар элек Кытай императорына караган, хәзер инде Тимербәк биләмәсендә яшиләр.

Алар – грек мәзхәбендәге христианнар, чыгышлары греклар җимерткән Троя амазонкаларыннан килә. Трояда амазонкалар ике төргә бүленә: беренчесе – шушындагы кебекләр, икенчесе – төрек кулындагылар.

Сәмәрканд шәһәрендә кануннар катгый үтәлә. Бер кеше дә икенче кешене рәнҗетми, бәк боерыгыннан башка җәзага дучар итә алмый, аның әмере буенча башкарылганнары да хәттин ашкан.

Тимербәк һәрчак үз янында казыйлар йөртә, алар ыстанны, ил-йортны үз карамагында тәртиптә тоталар, бүтән җирләрдәге халык та аларның сүзен тыңлый. Һәр казый үз эшен алып бара: берләре мөһим мәсьәләләрне, килеп чыккан бәхәсләрне хәл итә, икенчеләре бәкнең казна эшен алып бара, өченчеләре җирле идарә башлыкларының эш-гамәлен күзәтә. Ыстан корылуга, һәр казый үз тармагында эшкә керешә. Өч тирмә корып, шунда алар гозер белән килгән кешеләрне кабул итәләр. Тимербәк белән киңәшкәннән соң гына, казыйлар берьюлы биш-алты эшкә карата ярлык бирергә дип карар чыгаралар. Шунда ук бөтүче (сәркатиб) бернинди тоткарлыксыз язып тутыра, махсус дәфтәргә теркәп, мәгълүм бер билге куя. Шуннан соң ярлыкны бәкнең үзенә кертәләр, ул, көмештән уеп эшләнгән мөһерен, карага буяп, эчке битенә суга. Аннары, ярлыкны икенче казый алып, дәфтәргә терки дә үзенең түрәсенә бирә, анысы тагын карага манылган мөһер суга. Өч-дүрт казый мөһер куйганнан соң, ярлыкның урта бер җиренә «Дөрес» дип язылган патша мөһере сугыла; мөһергә өч түгәрәк рәвешендә билгеләр уелган:

ооо

Шулай итеп, һәр судья-киңәшченең үз бөтүчесе, үз теркәү дәфтәре бар. Ә инде бирелгән грамотадагы мөһерләрне һәм патша нишанын кайда гына күрсәтсәң дә, андагы карар шул сәгате-минутында ук берсүзсез үтәлә.

*Урысчадан **Марсель Галиев** тәрҗемәсе* ■

«Җиде тотам ук атты...»

Аларның төп кораллары – ук һәм җәя, кылыч һәм балта, кистән һәм сөңге, калкан, шишәк һәм көбә күлмәк.
Р.Фәхреддин

Урта гасырдагы мәргән.
М.В.Горелик реконструкциясе

Ук белән җәя – төрки халыклар иң еш кулланган хәрби һәм ау коралы. Аны ясау, хәрби һәм стратегик белем белән бергә, аучылык эшен яхшы белүне, зәвык һәм сәнгати осталыкны да таләп иткән.

Ук-җәя борынгы бабаларыбызның көндәлек коралы булуына дистәләрчә мәкаль һәм әйтем дәлил булып тора. Шуларның берничәсен искә төшерик:

Аткан ук кире кайтмый. Бер ук ике кошны үтермәс. Дошман юкта ук атсаң, үз кешеңә тияр. Укчы тидерә алмаганга, ук гаепле түгел. Туры ук – тәмеккә (мишень) тияр, кәкре җәя – кулда калыр. Аталмаган җәядән күрер. Мәргән – угы саен берне бәргән.

Җәя конструктив яктан бик гади. Ул өч өлештән тора: 1) тотка – кул белән тота торган үзәге; 2) тоткадан ян-як өлеше кибет дип атала, ул рычаг функциясен башкара; 3) җәяне бөгү өчен ике яктан тарттырылган бау – кереш.

Табигый тирәлеккә һәм хәрби традициягә бәйле рәвештә җәяне яхшы сыйфатлы каен, корычагач (ясень), чаган, чыршы, шомырт, чикләвек агачларыннан ясаганнар.

Кереш өч төрле материалдан булырга мөмкин. Шуларның иң яхшысы һәм кыйммәтлесе – ефәк. Керешнең тиредән яки сеңердән эшләнгәне дә еш кулланылган. Ат кылыннан ясалганы да яхшылардан саналган, әмма, сеңердән аермалы буларак, ул вакыт узу белән сузылган, эластиклыгын югалткан, дымны сеңдергән һәм кышкы чатнама суыкларда яки эсседә кибеп өзелергә дә мөмкин булган. Шунлыктан аны балавыз яки терлек мае белән эшкәртеп торганнар. Кайчакта кереш өчен ныклы киҗе-мамык,

киндер, җитен бау, махсус эшкәртелгән сарык эчәгесе дә яраган. Иң таза кереш 60 сүстән үрелеп, 3 мм калынлыкта булган.

Җәянең эшләү механизмы да гади. Мәргән керешне уң кулның баш бармагы ярдәмендә тарта, шулай итеп, кинетик энергия барлыкка килә. Җиңел булсын өчен, баш бармакка – мөгездән эшләнгән бармакча, ә җәянең сабын тоткан сул кулга, ук сабы хәрәкәт вакытында җәрәхәтләмәсен өчен, күн каеш белән буйга уентыклы оваль беләзек кидергәннәр. Укны уң колакка кадәр тартканнар һәм атып җибәргәннәр.

Җәядән атылган укның очып бару дистанциясе 60-150 метр тәшкил иткән. Аеруча нык һәм зур җәяләрдән 400 метргача атарга мөмкин булган. Госманлы империясендәге рекордны әлегә кадәр берәүнең дә узганы юк. Биредә укның 845,5 метр ераклыкка кадәр очып җитүе билгеле. Җитез укчы, дошманга төзәп, минутына 10-12 ук очыра алган.

Ук өч өлештән тора. 1) Очлыгы – башак киң тасмалы яки ромб формасында металлдан коелган. 2) Үзәктә – агачтан төз итеп ясалган сап, аның озынлыгы – 75-90 см (кайберләре 120 см), ә калынлыгы 7-10 мм булган. «Идегәй» дастанында «Җиде тотам ук атты...» дигән юл бар. Димәк, бу ук 7 уч, ягъни 70 см озынлыкта булган. Якын арага ату өчен кулланылган уклар – карагач, тирәк, ә еракка ата торганнары карагай, кедр, каен, талдан эшләнгән. Кайчакта агач урынына камыш та кулланылган. 3) Укның аэродинамика өчен җаваплы өлеше – арты (куз) икедүрт каурыйдан тора, 12-15 см тәшкил итә. Куз өчен бөркет һәм диңгез кошларының канаты иң яхшылардан санала, әмма Идел-Урал төбәгендә еш кына кыр казы һәм үрдәк каурыйларын еш файдаланганнар. Алар, төз атсалар да, укны авырайткан. Җиңел һәм еракка ату өчен эшләнгән укларның каурые бәләкәй булган. Саескан койрыгыннан ясалганнары аеруча төз аткан. «Идегәй» дастанындагы «Карга йонлы кузымны» дигән юлларны да искә төшерсәк, ук ясау өчен теләсә кайсы кошның канаты кулланылган дип уйларга мөмкин.

Укның тавышсыз булуы игътибарга лаек, шул сәбәпле ул җәнлекләрне куркытмаган. Әмма борынгы төркиләр дошман өстенә, куркыту өчен, сызгыра торган уклар яудырган. Беренче булып аны Мөде ханның кулланганы билгеле. Мондый ук очканда чыгарган тавышы белән дошманның йөрәгенә шом салган һәм гаскәргә кая хәрәкәт итәргә кирәклекне белдергән. Тавыш чыгарсын өчен, укның очлыгында куыш ясала торган булган.

Ук һәм җәя салып йөрү өчен күннән эшләнгән садактан файдаланганнар. Билгә каеш ярдәмендә асылган бер садакка 15тән алып 30га чаклы ук сыйган. Күнгә тотем хайван, үсемлек орнаментлары ясалган, затлылары сөяк, көмеш һәм алтын белән бизәлгән.

Текстны журналга ***Ленар Гобәйдуллин*** *әзерләде.* ■

Безнең мирас №6 июнь 2021

«Әй шәкертләр, ваемсыз булмагыз!»

Раиф Мәрданов

Татарстан Республикасы Милли китапханәсе хезмәткәрләре борынгы кулъязма истәлекләрне туплау максатындагы археографик экспедицияләрне ел саен дәвам итеп киләләр. Кызыклы һәм фәнни яктан әһәмиятле табышлар, әлбәттә, очрап тора.

Китапханәнең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «2221 т» шифры белән саклана торган кулъязма җыентыктагы бер язмага тукталыйк. Монда кулъязмага тулырак тасвир бирәбез.

Башындагы һәм ахырындагы битләре төшкән, гомуми күләме 58 кәгазьдән торган җыентык 1655-1671 нче елларда Голландиядә эшләнгән кәгазьгә язылган. Димәк, андагы текстлар XVII гасырның соңгы чирегендә теркәлгән.

Кулъязма җыентык китапханәгә 2016 елгы археографик экспедиция вакытында Арча районының Югары Пошалым авылында яшәүче Нургали Зариповтан алынган.

***

Бу җыентыкның 14 нче кәгазендә шәкертләр өчен язылган үгет-нәсыйхәт шактый кызыклы. Ул мәгариф һәм динебез тарихы өчен әһәмиятле. Әлеге текст хәзерге татар әдәби теленә күчермәдә тәкъдим ителә.

«Аллаһ газиз гомерләрегезне озын кылсын!

Әй шәкертләр!
Тыңлаучылар булыгыз!
Ваемсыз булмагыз,
Үкенүче булырсыз!

Үтәлергә тиешле унике нәрсәне остаз каршында җиренә җиткерегез:

Беренче – остазның күз алдында булыгыз.

Икенче – һәрвакыт хезмәттә булыгыз.

Өченче – остаздан рөхсәтсез эш кылмагыз.

Дүртенче – остаз алдында ятмагыз, әдәпсез утыру белән утырмагыз.

Бишенче – остаз нәрсә боерса да, ишеткән вакытта, «ишеттем һәм буйсындым», дип кабул итегез.

Алтынчы – остаз урынына утырмагыз.

Җиденче – остазны олылагыз, алдында каты аваз белән сүз сөйләмәгез һәм артыгызны борып утырмагыз.

Сигезенче – остазны гайбәт кылмагыз.

Тугызынчы – рөхсәтсез һич җиргә бармагыз.

Унынчы – остаз алдында көлешү кебек, бер-бере белән төртешү кебек, сугышу кебек, орышу кебек әдәпсез эшләрне кылмагыз.

Унберенче – остаздан даими куркуда булу.

Уникенче – сабыр булу.

Һәркем бу унике нәрсәне үтәсә, Аллаһы Тәгалә ул кешене ярлыкар, иншәАллаһ. Һәм ул кеше белән файда табар. Һәркемгә бу эшләрдән башка насыйп итсә, дөнья-ахирәттә файдасыннан мәхрүм булыр. Гыйлемлек – Кыямәт көн дәгъвачы булыр.

Янә моннан бүтән теләкләр һәм әдәпләр дә күп. Монда беразын бәян итәбез.

Әдәп белән теләгәнгә ирешү ансат, дип, җиңелгә санамагыз. Барлык эшләр башы – әдәп. Рәсүлуллаһ хәдисе дәлил, пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Әдәп – агач, гыйлем – аның әҗеренең җимеше».

Ул әдәпләрнең кайберсе болар:

Җәмәгатьнең арасында карендәш-ыру булып торыгыз, олыгызга хезмәт кылып, кечегезгә шәфкать кылып торыгыз! Тәмле телле булыгыз, ачык йөзле булыгыз, телегезне яман-ялганнан тыегыз! Зинһар, бозык сүзләрне гадәт итмәгез. Һәртөрле гадәт булса, аны ташлау мөмкин түгел, галимнәр әйтмешли, «чир китәр, гадәт калыр».

✪ Янә мәктәптән аяк атлап тышка чыксагыз, һәркем очраса – көр тавыш белән сәлам бирегез. Әгәр күрешердәй адәм булса, күрешегез.

✪ Кеше өенә барсагыз, рөхсәтсез эчкә кермәгез. Әгәр рөхсәт белән керсәгез, хуҗасы ишарә итмәсә, түргә чыгып утырмагыз. Һәм янә күзегезне өй эченә текәп утырмагыз.

✪ Ризык ашагач, дога белән китегез.

✪ Янә мәгълүм булсын, җәмәгатькә бару – фарыз гамәл. Аны ташламагыз, хайван кебек булып йөрмәгез.

✪ Аллаһы Тәгалә хакына, сәбәпсез, догадан алда мәчеттән чыкмагыз.

✪ Мәчеттә сафны төзек итеп утырыгыз, чыкканда акрынлык белән чыгыгыз. Артыгызны михрабка борып чыкмагыз. Баскычтан менгәндә һәм төшкәндә шак-шак итеп йөрмәгез.

✪ Һәм мәчеттә, һәм кеше өендә, кеше өеннән чыкканда йөгерешеп китмәгез, артыгыздан көлеп калмасыннар.

✪ Янә үз арагызда төнлә-көндез җыр һәм такмак белән гомер кичермәгез. Һәркем шәкерт булып, Аллаһтан хаҗәт өмет итмәсә, остаздан ризалык өмет итмәсә, бу сүзләр белән вәгазьләнсен. Кабул итеп, мондагы сүзләрне әйтсә, башкаларга да Аллаһның рәхмәте ирешер. Хөрмәтле пәйгамбәрләргә (г.с.) сәламнәр булсын».

***

XVII гасырга караган бу текстта остаз һәм шәкерт арасындагы мөнәсәбәтләр, шулай ук шәкертләр өчен махсус әдәп кагыйдәләре шактый тулы тасвирланган. Алар XVII гасыр кульязмасында теркәлгән булса да, электән күчерелеп килеп, башлангычы, әлбәттә, әүвәлге гасырларга тоташкан.

Шәкертләргә әдәп кагыйдәләре турындагы үгет-нәсыйхәт төрле авторларның китапларында да язылган. Шундыйлардан мәшһүр татар галиме Ризаэддин Фәхреддиннең «Шәкертлек адабе» дигән махсус китабы XX гасыр башында күп тапкыр басылган. Ул китапта XVII гасыр кульязмасына охшаш урыннар бар. Мәсәлән, *«Шәкерт улган кемсә остазының гайбәтене сөйләмәз, зарурәт улмаганда алдыннан йөремәз, урынына утырмаз, изененнән башка хозурында сөйләшмәз, ачуыннан куркыр, гөнаһ улмаган эшләрдә кушканыны йиренә китерер, мөмкин улган сурәттә остазының хезмәтене итәр»**. Моңа охшаш әдәп кагыйдәләре шул ук авторның «Нәсыйхәт» исемле күпсанлы китапчыкларында да очрый. ■

* Ризаэддин бине Фәхреддин. Шәкердлек адабе: гыйлем тәхсыйль иткән заманда шәкердләр өчен кирәк улан нәрсәләр (әдәбләр) бәйан иделмешдер. «Гыйльме әхлак»дан бишенче җөзъэ. Йиденче табыг. – Казан: «Милләт» матбагасы, 1909. – Б.10. *Адаб* – әдәпләр; *улган* – булган; *кемсә* – кеше; *изен* – рөхсәт; *табыг* – басма.

Кабиләчелек низаглары

Фатих Әмирхан

**Ерак Кабан янында Ф.Әмирханның атта йөрү мизгелләре.
Казан. 1909 ел, сентябрь**

Мәшһүр әдибебез Фатих Әмирханның бу мәкаләсе «Кояш» газетасының 1915 елгы 25 февраль санында басылып чыга. Нәсел-нәсәбе белән үзе үк Чистай мишәре булган язучы кайбер зыялыларның мишәрлек яки башка этник төркемнәр – «кабиләчелек» белән мактануларын тәнкыйтьли. Әлеге эшнең татар милләтенең бөтенлегенә куркыныч икәнен кисәтә.

Тиздән Россиядә җан исәбе алыначак. Шул уңайдан, 100 ел элек күтәрелгән мәсьәләләр бүген дә актуаль дип саныйбыз һәм бу мәкаләне хәзерге заман укучысына да тәкъдим итәбез.

Редакция

«Ил» гәзитәсенең соңгы номерларында Мәхбүбҗамал Акчурина ханымның җиңел кулы белән мишәрлек-татарлык мәсьәләсе кузгатылып җибәрелде.

Ханым әфәнденең мәсьәләне башлавы да чын-чын «хатын»нарча булып, иң кечкенә генә бер нәрсәдән олугъ мөгез чыгару юлы белән иде: татар мөхәррир вә шагыйрьләре үзләренең язуларында «җ» хәрефе кулланалар икән. Чынлыкта, бу хәреф мишәр телендә булмаганлыктан, аны куллану әдәбиятка җинаять саналыр мәртәбәсендә зур бер гөнаһ була икән. Менә шушы дәгъвадан ниндидер бер мөнәсәбәт чыгарып, ханым әфәнде «мишәрлек белән мактанырга тиешлек» хакында лаф ора, моңар ышанмаган кешеләр булса, үзенең исбат итәргә хәзер торганлыгын да белдерә.

Мәхбүбҗамал ханымны мондый дәгъва вә мондый лафлар белән матбугатка атылырга мәҗбүр иткән нәрсә миңа караңгы; монда бер мактанасы килү генә бу ханымны хәрәкәт иттерәме, яки мишәрлек-татарлык низагълары кубарып, бер мәдәни төркемгә оешып бара торган шималь төрекләре (төньяк төркиләре, ягъни татарлар. – **Ред.**) арасына кабилә кычкырышлары салырга теләү беренче урынны билиме, миңа мәгълүм түгел. Ләкин Мәхбүбҗамал ханымны ни хәрәкәт иттерсә иттерсен, «Ил»нең ул мактанчыкларга урын бирүенә, мәйдан ачуына мин һич мәгънә бирә алмыйм.

Бер ханым башына ниләр килмәс! Күптән түгел кулына каләм алган, җиңел уйлаучан бер кеше матбугатка нәрсәләр ыргытырга теләмәс, мактанчыграк кеше мактаныр өчен үзенә нәрсәләр тапмас. Ләкин болар һәммәсе дә кода-кодагыйлар арасында вә, бик күпкә китсә, дус-иш, күрше-күлән арасында калырга тиешле генә эшләр бит!

«Ил»нең язышучылары арасында шималь төрекләренең төрле кабиләләренә караган каләм әһелләре бар. Әгәр болар һәркайсы үз кабиләләре белән мактанышырга «Ил» сәхифәләрендә урын тапсалар, болар һәркайсы башка кабиләләрне «мактанышу көрәш вә кычкырышына» чакырсалар, вә бу низагълар матбугат сәхифәләреннән укучылар арасына да төшеп, ун данә шималь төркенең балалары җыелган һәрбер җирдә биш кабиләгә бүленешеп мактанышу китсә, моның нәтиҗәсе нәрсәгә кадәр барып җитәр.

Мишәрлек белән мактану моннан элек тә берничә мәртәбә баш күтәреп куйгалаган иде инде. Бервакыт Идрис Богъданов исемле берсе, «Югалган хатын» исемле бер пьеса сыман нәрсә язып, мишәр вә татарны чагыштырырга уйлады, аннан соң Зариф Бәшири исемле берсе «Бәянелхак» сәхифәләрендә мишәрлек белән мактанам, фәлән итәм, дигән шикелле тавыш чыгарып азапланды, менә хәзер инде ханым әфәнде бу мәсьәләне бөтенләй бер бәхәс рухында мәйданга сала.

Зәгыйфь каләмнәр вә зәгыйфь уйлар тарафыннан башланып-башланып та эшкә ашмаган мондый бәхәс рухындагы мактанчыклар асылда һичбер кыйммәткә ия булмасалар да, башка кабиләләргә караган шималь төрекләренең кайбер кешеләрендә каршы хәрәкәт кузгата башлавы хәзер инде шикнең тышындадыр.

Шул ук «Ил» гәзитәсенең үзендә дә яшь әдипләремездән Г.Рәхим әфәнденең бу тугрыдагы бер язмасы басылган. Г.Рәхим әфәнде «Җим мәсьәләсе» дип язган бу озын мәкаләсендә, тарихи мәкальләр белән әдәби телнең ничек барлыкка килгәнен аңлатканнан соң, түбәндәге нәтиҗәгә килә:

«Казан һәм Казан тирәсендә утырган «казан татарлары» дип аталган халык күптәннән бирле гомум Идел буе татарларының мәдәни мәркәзе булып,

бөтен татар мәдәниятен үзләренең аркаларына тагып килделәр.

Шуңар күрә татарлар үзләренә бер милләт икәнлекләрен, үзләренең телендә әдәбиятлары булырга тиеш икәнен аңлагач та, бик табигый гына шул Казан шивәсе татарның әдәби теле урынына менеп утырды һәм акрын-акрын эшләнә башлады. Егерме-утыз ел узганы юк, каршыбызда дистә-дистә газитә һәм журналлы, йөзләр-меңнәрчә китаплы, яхшы гына эшләнеп килә торган бер әдәби тел туды. Бу тел – чынлап та, гомуми вә әдәби тел. Бу телдә басылган әсәрләрне мишәрләр дә, башкортлар да, нугайлар да аңлыйлар һәм кулларына каләм алдылар исә, шул телдә яза башлыйлар һәм бик дөрес юл беләк баралар, димәк, безнең алдыбызда барлыкка килгән бер факт.

Татар һәм, гомумән, төрки телләрдә «җим» хәрефенең булмавын дәгъва кылу, әлбәттә, бик төпсез һәм коры бер аңлашылмаудан гына килгән бер эш. «Җим» хәрефе төрки телләрнең рухына һич хилаф түгел. Төрек кавемнәренең кечкенә генә бер таифәсен тәшкил иткән мишәрләрнең телендә бу хәрефнең кулланылмавы һич моңар дәлил була алмый. Теле иң саф көенчә сакланган бик зур бер төрек кавеме – кыргызларның телендә «җ» хәрефенең бик күп кулланылуы – аның төрек рухына каршы булмавына үзе дәлил.

Казан татарларының шивәсендә дә «җ» булуы шулай ук табигый бер хәл. Казан шивәсендә «җ» хәрефе, кыргызлардагы кадәр күп булмаса да, әйтелә. Сүзләрнең матурлыгын бозмаслык дәрәҗәдә кулланыла. «Җыелу, җыен, җим, җир, җәй, җәелгән, җитте, җибәр, җиңелү, җыр, җылан» шикелле сүзләрне мишәрчәләтеп, авыз бозып «йыйылу, йыйын, йим, йир, йәй, йәелгән, йитте, йибәр, йиңелү, йыр, йылан» дип әйтүнең килешсезлеге, ямьсезлеге һәрбер кешенең колагына чалынса кирәк...

Казан шивәсе һәм хәзерге әдәби телебез исә бу турыда кыл урталыкта тора. Анда ифратлар да (чиктән тыш арттырулар), тәфритләр (чиктән тыш киметүләр) дә юк. Ул һәркем өчен ишетелергә хуш, әйтергә җиңел рәвештә «җ» белән «й»не аралаштыра. Әлеге мишәр таифәсе эченнән чыккан шагыйрь һәм язучыларны да, үз сөйләшләрен ташлап, казан шивәсендә язарга мәҗбүр итә торган иң көчле сәбәп шушы.

Мәхбүбҗамал ханым бу фактларга илтифат итми генә түгел, ул хәтта әллә нинди гайре табигый булган «мишәрлек маниясе»нә дучар».

«

Соң бу сүзләр милләтебезгә, әдәбиятыбызга шулкадәр хезмәтләр иткән казан татарларына кырын күз белән карарга, әллә нинди яңа бер милләт, яңа бер әдәбият – «мишәр милләте» һәм «мишәр әдәбияты» төзергә өндәү түгелме? Соң бу яңа гына бер милләт булып оешып килә торган Идел буе татарларын яңадан берничә милләткә бүлү, туып килә торган мәдәни берлекне җимерү, бер милләтнең төрле таифәләре арасына аерма һәм дошманлык салу дигән сүз түгелме? Тагын башкорт һәм нугай әдәбияты һәм милләтләре ясарга юл ачу булмыймы? Бу фикерләрне, чынлап та, «мишәр шовинизмы» дип атасы килә.

Моннан соң Г.Рәхим әфәнде, Акчурина ханымның «мишәрлек белән горурланырга тиешмез» дигән сүзенә күчеп, түбәндәге бик садә, ләкин чын уйланып, кызыклы итеп тезелгән фикерләрне бәян итә: *«Соң бу сүзләр милләтебезгә, әдәбиятыбызга шулкадәр хезмәтләр иткән казан татарларына кырын күз белән карарга, әллә нинди яңа бер милләт, яңа бер әдәбият – «мишәр милләте» һәм «мишәр әдәбияты» төзергә өндәү түгелме? Соң бу яңа гына бер милләт булып оешып килә торган Идел буе татарларын яңадан берничә милләткә бүлү, туып килә торган мәдәни берлекне җимерү, бер милләтнең төрле таифәләре арасына аерма һәм дошманлык салу дигән сүз түгелме? Тагын башкорт һәм нугай әдәбияты һәм милләтләре ясарга юл ачу булмыймы? Бу фикерләрне, чынлап та, «мишәр шовинизмы» дип атасы килә. Бу «горурланырга тиеш» дигән сүзләрдән, ни өчендер, мишәрләрне башкортлардан өстен куярга тырышу, башка татар таифәләренә өстен торып, ихтирамсызлык белән карау исе килмиме соң? Мәхбүбҗамал ханымга, һич булмаса, бу фикерләре белән матбугатка чыкмаска кирәк иде».*

«Безнең кайсыларымыз гына үзенең канында кырык төрле төрек кабиләсенең канын тапмас. Безнең кайсымыз гына атасы ягыннан мишәр булса, анасы ягыннан, әбисе ягыннан башкорт, казан татары, нугай, әллә кем түгелдер.

Моннан соң Г.Рәхим әфәнде Акчурина ханымның мишәр телен бөтен шималь төрекләренә әдәби тел итеп куярга азаплануына иң садә генә бер игътираз белән җавап бирә:

«Әдәби телебезгә мишәрнең «й»ләрен тутыру да, шул ук провинциализм, димәк, әдәби телебезгә каршы булган җинаятьтер. Чөнки «й»ләре артыннан мишәрнең «бак»лары, «каракаш»лары, «кучат» һәм «ызба»ларының да әдәбиятка кереп утыра башларга җөрьәт итүләре ихтимал», – ди.

Г.Рәхим әфәнденең бу мәкаләсе, өмид итәмез, моннан соңгы кабилә шовинизмын матбугатка чыгарырга тырышучыларга бер дәрес була алыр.

Бу көнгә шикелле бөтен шималь төрекләре башында гомуми бер төшенкелек хөкем сөргән вакытта, гаммә тарафыннан икърар ителгән вә гомум шималь төрекләрен үз канаты астына җыеп килгән лидерымызның *(сүз Исмәгыйль Гаспралы хакында бара)* арамыздан җуялган елында, гомуми тел, әдәбият вә мәдәниятемез нигезләнеп җитмәгән бер дәвердә бу низагъларны шуларны башлап матбугатка чыгарган кешеләрнең йөзләренә генә ыргытырга тиештер.

Әгәр кабиләләр белән мактанышу китсә иде, бөтен шималь төрекләренә иң матур көйләр биргән башкорт кабиләсе, иң куәтле вә иң ялкынлы бер шагыйрьне биргән башкорт кабиләсе башкалар алдында мактанырга юл тапмас идемени?

Әгәр мондый мактаныш китсә иде, төрек теленең иң күп лөгатьләрен саклап килгән, төсләрендә чын төреклек әсәрләре алып килгән казакълар мактанырга юл тапмаслар идемени?

Әгәр мондый мактанышлар китсә, бөтен милли бәйрәм вә милли гадәтләрнең шагыйранәләрен саклап килгән нугайлар мактанырга сүзләр тапмаслар идемени?

Сулдан уңга: Ф.Әмирхан (көймәдә), Кәбир Бәкер (яр буенда), Рауза Аитова (Исмәгыйль Аитов хатыны). Казан, Ерак Кабан. 1913, июнь

Болар һәммәсе дә сүз табарлар иде!

Ләкин бу мактануларның һәммәсе нәрсәгә? Аллаһ хакы өчен әйтегез, нәрсәгә? Моның кемгә һәм нинди максатлар өчен кирәге бар? Булса-булса, моның кирәге шималь төрекләре өчен түгел, башкалар өчен булыр!

Әүвәл шималь төрке була белергә кирәк, аннан соң да әле мишәр, татар, башкорт, казакъ булырга өлгерермез. Әүвәл бер мәдәният астына кереп, кеше төсле торып карарга кирәк, әгәр ул тормыш ошамаса, аннан соң да төрле кабиләләргә бүленеп сугыша башлауны булдыра алырмыз. Оеша башлаган әдәби тел, җөйләнә башлаган милли барышка үзләре генә баш булырга теләүче кабиләләр табылалар икән, болар инде башка кабиләләр тарафыннан әдәпкә кертелергә тиешләрдер. Әгәр махсус кабиләнең хосусый мактанчык балалары шундый хәтәрле дәгъвалар белән матбугатка чыгалар икән, бу кеше иң башлап шул кабиләнең алдынгы затлары тарафыннан авызлыкланырга тиештер.

Эш эшләргә уңай куәт кирәк булса да, эшләнгән нәрсәләрне бозарга иң зәгыйфь вә начар куллар да ярыйдыр. Шуңар күрә ул зәгыйфь вә уңышсыз кулларны да игътибарга алырга вә милли тормыш тирәсеннән читләштерергә мәҗбүрият күренәдер.

Безнең кайсыларымыз гына үзенең канында кырык төрле төрек кабиләсенең канын тапмас. Безнең кайсымыз гына атасы ягыннан мишәр булса, анасы ягыннан, әбисе ягыннан башкорт, казан татары, нугай, әллә кем түгелдер. Кабилә низагълары күрергә теләгән кешеләрнең урыны бүгенге мәдәни милләтләр арасында түгел, бәлки, коруне вөстаның *(урта гасырның)* бәдәвият чүлләрендәдер; соңга калган бу шовинизм белән дөньяга чыгарга инде бүген оялырга тиешләрдер. ■

Түбән Варта шәһәре татарлары

Фәүзия Бәйрәмова

Котыпта урнашкан Ханты-Мансийск, Сургут, Салехард, Югорск, Советский, Урай, Пойковский, Нефтеюганск, Когалым, Покачи, Лангепас, Мегион, Түбән Варта, Муравленко, Яңа Уренгой, Ноябрьск, Радужный, Яңа Аган, Пыть-Ях һәм башка шәһәр һәм бистәләр – мин аларның барысында да булдым... Моннан 40-50 еллар элек Татарстаннан һәм Башкортстаннан Көнбатыш Себергә күчкән «яңа татарлар»ның тарихларын, тормыш юлларын, проблемаларын җентекләп өйрәндем, бигрәк тә милли һәм дини яшәешләренә зур игътибар бирдем.

Түбән Вартадагы Муса Җәлил бюст-һәйкәле янында

Котып – үзебезнеке!

Котып, дигәч, безнең күз алдына Төньяк Боз океаны, калын кар-боз астында калган Арктика, мәңгелек туң белән капланган тундра, җир читендәге Ямал ярымутравы, Кар диңгезе буйлары, Көнбатыш Себернең кара урманнары, төпсез сазлыклары килә... Әйе, болар барысы да дөрес. Безнең әби-бабаларыбыз аны бер сүз белән – «котып», ә фәнни әдәбиятта шималь, ягъни төньяк ягы дип йөрткәннәр. Котып-Себер ул үзе тулы бер дөнья, ачылмаган тарих, кар-боз астында калган бөек цивилизация, серле һәм дәһшәтле җирләр... Юкка гынамы бүген Президенттан башлап галимнәргә кадәр Котып Себерен өр-яңадан өйрәнергә чакыра башладылар?! Кайберәүләр моны ул төбәктә иксез-чиксез җир асты байлыклары, нефть һәм газ белән бәйләп аңлатырга тырыша, әмма монда сәбәп башкада. Даһи Менделеев әйткәнчә, дөньяның кендеге Котыпта, башы һәм азагы шунда, шул сәбәпле бүген кешелек дөньясының да карашы анда төбәлгән...

«Даһи Менделеев әйткәнчә, дөньяның кендеге Котыпта, башы һәм азагы шунда, шул сәбәпле бүген кешелек дөньясының да карашы анда төбәлгән...

Безнең өчен Котып – милләтебезнең борынгы тарихы һәм бүгенгесе. Заманында Татар дәрьясы дип йөртелгән Төньяк Боз океаны суларына, Кар диңгезе дулкыннарына төрки-татар атамалары тарих тарафыннан мәңгелеккә кушылган, бу җирләр дөньяның

барлык карталарында ТАРТАРИЯ дип күрсәтелгән. Әйе, Котыпка да татар хуҗа булган, бу хәл Нух пәйгамбәр заманыннан башланып, Алтын Урда, Себер ханлыклары чорына кадәр дәвам иткән.

Анда дистәләгән заманча шәһәрләр төзелгән, бирелән Европага кадәр нефть һәм газ торбалары сузылган, алардан нефть һәм газ елга урынына агып тора... Боларның барысын да булдыручылар, хәрәкәткә китерүчеләр арасында йөз меңләгән милләттәшебез бар. Көнбатыш Себер, Ханты-Манси һәм Ямал-Ненец автоном округлары безнең өчен дә чит-ят җирләр түгел, анда милләтебезнең борынгы тарихы бар һәм бүгенгесе языла. Шуңа күрә безнең бу яклар белән кызыксынуыбыз табигый хәл, үткәннәр аша без киләчәгебезгә күпер салабыз.

Хәзер Көнбатыш Себердә милли үзәкләрнең берсенә әйләнгән, татарларның рухи башкаласы булып торган Түбән Варта шәһәре һәм аны күтәргән милләттәшләребез турында кыскача мәгълүмат биреп үтәргә телим.

Түбән Вартага кайчан һәм кемнәр нигез салган?

Әйе, Томск өлкәсе чигенә урнашкан Түбән Варта (Нижневартовск) шәһәре – Ханты-Манси автоном округында, Сургуттан кала, икенче иң зур шәһәр. Ул Россиянең нефть башкаласы булып санала һәм иң бай шәһәрләр исемлегендә йөри. Түбән Варта чыганакларда 1909 нчы елларда искә алына. Бирелдә зур гына Варта авылы булган. Әмма русларга кадәр Обь елгасы буендагы әлеге уңайлы урыннарда себер татарлары һәм җирле остяк-вогуллар яшәгән.

Түбән Вартаның башта – бистәгә, аннан зур калага әйләнүе Самотлор нефть ятмаларын ачу белән бәйле. 1965 елда ул удар комсомол төзелеше, дип игълан ителә һәм бирегә бөтен ил буенча халык агыла башлый. Алар арасында татарлар да бик күп була. 1970 нче елларда Түбән Вартада башта – аэропорт, аннан тимер юл вокзалы ачыла, Сургут ягына поездлар йөри башлый, ә 1982 елда аңа инде шәһәр статусы бирелә. Бүгенге көндә Түбән Вартада «Роснефть»нең бөтен эре ширкәтләре эшли.

«Көнбатыш Себердә иң беренче Сабан туйлары да Түбән Варта шәһәрендә уздырылган, бу хәл моннан кырык ел элек – 1981 елда булган.

Рәсми мәгълүматлар буенча, Түбән Вартада 23 мең татар яши. Әмма татарлар үзләре бу санны 40 мең тирәсе, диделәр. Ә мөселманнар исә ике тапкыр күбрәк. Татарлар бирелдә сан ягыннан икенче урында тора. 1965 елда бистәнең беренче урамына ук хакимият карары белән Муса Җәлил исеме бирелгән, хәзер анда шул исемдәге мәйдан һәм шагыйрьгә бюст-һәйкәл тора. Милли хәрәкәткә аны куйдыру өчен өч ел буе йөрергә туры килгән. Көнбатыш Себердә иң беренче Сабан туйлары да Түбән Варта шәһәрендә уздырылган, бу хәл моннан кырык ел элек – 1981 елда булган.

Милли тормыш һәм игелекле милләттәшләр

Шәһәрдә 45 предприятиенең генераль директоры – татарлар. Алар, атом бозваткычлары кебек, бөтен милли һәм дини тормышны тартып алып баралар. Бирелдә менә егерме ел инде татар автономиясе эшләп килә, аның рәисе – зур җитәкче, генераль директор **Рафаэль Мөхәммәтҗанов.** Түбән Варта шәһәрендә татар балалар бакчасы

да бар, өч татар сыйныфы да ачылды. Кыскасы, бу шәһәрне төзүчеләр дә, аны югары дәрәҗәдә тотучылар да – татарлар, милләтнең рухи ихтыяҗларын кайгырту да милләттәшләребезнең үз өстендә. Түбән Варта шәһәрендә татарлар бик актив, алар монда үзләрен хуҗа итеп тоталар.

Якташыбыз **Хәмит Миркасыймов** та милли эшләргә күп вакытын бирде, күп көч куйды. Ул биредә татар автономиясе рәисе урынбасары вазыйфаларын башкарды, инде рухы шат булсын! Аның тирәсендә шәһәрнең булдыклы татарлары, эшмәкәрләре тупланды, милләтнең бөтен эш-проблемаларын шушы егетләр хәл итте.

«…Түбән Вартада менә инде 1976 елдан бирле «Самотлорның ак төннәре» дип аталган фестиваль уздырыла, ул июнь уртасына туры килә.

Түбән Варта шәһәрендә зур урыннарда эшләп киткән тагы бер милләттәшебез турында мәгълүмат бирәсем килә. Ул –**Фирдәвес Хөснетдин улы Галиев.** Фирдәвес әфәнде 1947 елда Татарстанның Мөслим районындагы Иске Карамалы авылында туган. Ул Октябрьск шәһәрендә нефть техникумын, аннан Мәскәүдә шундый ук институтны тәмамлый, Лениногорск шәһәрендә НГДУ җитәкчесе ярдәмчесе булып эшли. 1978 елдан Фирдәвес Галиев Себердә эшли башлый, Самотлор нефть ятмаларын чыгаруда катнаша. «Нижневартовскнефть» НГДУсының генераль директоры була, аннан «Самотлорнефтегаз»ның генераль директоры булып хезмәт куя. 2001 елда Фирдәвес Галиев Түбән Варта Шәһәр Думасына депутат итеп сайлана, 2006 елдан Дума рәисе урынбасары вазыйфаларын башкара. Бу чорда да аның Түбән Вартада халык өчен күп эшләр башкарганын әйтәләр, милләттәшебезне рәхмәт белән искә алалар.

Түбән Вартада милләтебезнең мәдәни тормышы да җайга салынган, биредә үзешчәннәр дә, Татарстан һәм Башкортстаннан килгән профессиональ артистлар да яратып чыгыш ясый, заллар шыгрым тулы була. **Раилә Юмагулова** җитәкләгән **«Шатлык»** татар-башкорт ансамбле Түбән Вартада гына түгел, ә бөтен Ханты-Манси автоном округында билгеле, анда утызга якын кеше йөри. Шәһәрдә менә инде 30 ел дәүләт карамагындагы татар-башкорт китапханәсе эшли, анда өч мең китап бар. Татар китапханәсе каршындагы **«Сердәш»** клубында төрле бәйгеләр, әдәби чаралар еш үткәрелә. Хәтта минем «Безне онытмагыз» драмасыннан да өзекләр куйганнар, аны халык алдында уйнап күрсәткәннәр. Шулай ук «Баһадиршаһ» тарихи-документаль романым буенча да китап укучылар белән очрашу уздырганнар. Китапханә җитәкчесе **Зөлфия Заһидуллина** һәм китапханәче **Ралия Сабитова** Казан язучылары белән дә элемтәгә керү юлларын тапкан – алар белән видеоочрашулар оештыра башлаган. Түбән Вартага һәр баруымда да бу китапханәдә булдым һәм истәлеккә китапларымны биреп калдырдым. Бүгенге көндә китапханәдә Түбән Варта татарлары турында библиографик белешмә әзерләнә. Аларның хезмәтләре, һичшиксез, тарихка теркәлеп калырга тиеш.

…Түбән Вартада менә инде 1976 елдан бирле «Самотлорның ак төннәре» дип аталган фестиваль уздырыла, ул июнь уртасына туры килә. Бу бәйрәмгә бөтен илдән җыелалар, концерт программаларында татарлар да катнаша. Соңгы елларда шәһәрдә зурлап «Татар мәдәнияте көннәре» дә оештырыла башлады. Анда ел саен Казаннан Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле килә. Аларның чыгымнарын җирле татар эшмәкәрләре күтәрә.

Түбән Вартада иман нуры

Инде Түбән Вартада дин мәсьәләләренең торышына да бераз тукталып үтик. Бу шәһәргә килгән саен Обь елгасы буенда таралып яткан зур төзелеш мәйданына барам. Биредә **«Сабыр»** дип аталган җәмигъ мәчет булачак икән ул. Әмма озак еллар буе төзелә. Әйткәнемчә, зур нефть-газ ширкәтләре бу төбәктә мәчет төзелешләре өчен акча бирмиләр, әлеге изге эш җирле мөселманнарның үз өстенә кала. Зур проект төзеп, дини-милли комплекс булдыру ниятеннән башланган әлеге төзелешнең шактый еллар буе очы-кырые күренмәде. Дөрес, аның янында гына вакытлыча мәчет эшләп килә, халык шунда намаз укый, әмма җомга һәм гает намазларын уздыру өчен ул кечкенә.

Шәһәр читендә зур булмаган тагы бер мәчет бар. Ул 1994 елда ачылган. Анда имам вазыйфаларын Балтачтан килгән милләттәшебез **Марат Гыйльфанов** башкара. Мин бу мәчетләрнең икесендә дә булдым, намазларымны укыдым, теләкләремне теләдем. Иң зур теләгем, әлбәттә, Түбән Вартада җәмигъ мәчетнең төзелеп бетүе иде... Һәм мин бу көннәрдә шатлыклы хәбәр алдым – **«Сабыр»** җәмигъ мәчетенең инде диварлары өелгән, манаралары торгызылган, эчке эшләре генә калган. Бу олы, изге эшне милләттәшебез, Пенза мишәре **Ринат Әбүзәров** исемле кеше башлап йөри, диделәр. Аңа Аллаһының рәхмәтләре булсын!

Мегионның үз Болгары бар!

Түбән Варта шәһәре Мегионга терәлеп диярлек тора, шуңа күрә күп эшләрне алар бергә башкаралар. Әйткәнебезчә, Түбән Вартадан утыз чакрымнар гына ераклыкта Мегион шәһәре бар, бу ике калада да милли эшләр уртак башкарыла. Мегион җирле хантлар телендә «ерактагы йолдыз» дигәнне аңлата икән. Анда да биш меңләп милләттәшебез яши. Данлыклы Самотлор нефтен чыгарырга татарлар бирегә моннан алтмыш еллар элек килеп урнашалар һәм янәшәдәге Түбән Варта шәһәрен төзүдә дә алар катнаша. Бүгенге көндә дә Мегион-Түбән Варта татарларына уртак хезмәт күрсәтүче кайбер данлыклы милләттәшләребезнең исемнәрен язып үтәсем килә. Алар – «Болгар» оешмасын гамәлгә куючылар һәм бүгенге көндә дә бөтен эшләрне алып баручылар: **Фатыйхҗан Шакирҗанов** – зур бер төзелеш оешмасының генераль директоры; **Рамил Кыямов** – зур төзелеш оешмасының баш белгече, хәйрияче; **Радик Гайнуллин** – эшмәкәр; **Мәнфәс хәзрәт Садыйков** – имам; **Ринат Шәйморатов** – укытучы, «Болгар» оешмасының элекке рәисе; **Зөһрә Бикташева** – «Болгар» татар милли-мәдәни мохтарияте җитәкчесе.

***

Әйе, Көнбатыш Себердә җир күп, байлык хисапсыз, мөмкинлекләр зур, әмма шул ук вакытта табигать шартлары бик кырыс, эш авыр, тормыш җиңел бирелми. Шуңа күрә биредә теләсә кем яши һәм эшли алмый. Бары тик бик тырыш, булдыклы, түзем, максатчан кешеләр генә Котыпта тамыр җибәрә ала... Татарлар – әнә шундыйлардан, моны тарих исбат итте, вакыт күрсәтте. Инде шушы мәңгелек туң җирләрдә милләт булып та сакланып калырга иде. Монысы, бәлки, нефть-газ чыгарудан да авыррак булыр. Хәзер Котып илен ислам нуры белән нурландырырга кирәк, монысы да безнең өстә, бәлки, безнең төп миссиябез дә шушыдыр... Мәкаләмне ак карларга тезләнеп намазлар укыган, кара урманнарда мәчетләр салган, шәһәрләр төзегән, зәмһәрир салкыннарында нефть-газын чыгарган, ерак Себердә дә тормышын кешечә алып барган милләтем әлеге олы бурычны да үтәр, Котыпта да мөселман-татар булып калыр дигән өмет белән тәмамлыйм. Аллаһы Тәгалә кайда да милләтемә ярдәм итсен, милләтем һәр җирдә Аллаһка, иманга тугры калсын иде! ■

ТАССРда беренче Сабан туйлары

Сабан туенда көрәшкә әзерләнгән балалар

ТАССРның беренче елларындагы Сабан туе бәйрәмнәре сәяси төсмер алуы белән үзенчәлекле. Дөрес, әлеге процесс Октябрь түнтәрелешеннән соң ук башлана. Милли бәйрәмне оештыру эше хәйрия җәмгыятьләре һәм авыл җәмәгатеннән алынып, тулысынча совет хакимияте, районнардагы партия комитетлары кулына күчә. Әйтик, милли уеннардан тыш, күмәк шигырьләр уку, декламацияләр сөйләү, спектакльләр уйнау, балалардан оешкан хорлар чыгышы бәйрәм өчен яңалык була. Кайбер авылларда Сабан туе рухын митинг рәвешенә кертеп, төрле салымнар, яңа декрет һәм кануннар турында сөйләгәннәр.

1920 елда Сабан туе авылларда, гадәттәгечә, чәчүгә чыгар алдыннан, май башында оештырылса, Казан шәһәрендә ул шактый соңарып, 2 июльдә генә уздырыла. 1921 елда милли бәйрәм 25 июнь, 25, 26, 28 июль һәм 1 август көннәрендә Казан мөселман ирекле янгын сүндерүчеләр дружинасы файдасына үткәрелә. Ачлык булуга карамастан, бу елда милли бәйрәмнең кайбер авылларда да уздырылуын күрәбез. Ә инде 1922 елдагы Казан Сабан туеннан кергән акчаның ачтан интегүчеләргә ярдәм итү фондына һәм ачыгучы студентларга җибәреләчәге хакында хәбәр ителә. Кабан өстендә диңгез сугышы, Идел һәм Кабан өстендә аэропланда очу, көймә ярышы кебек тамашалар әлеге бәйрәмнең яңалыгы була.*

* Шәрәфетдинов Д.Р. Татар барда Сабан туе бар. – 2003. – Б. 121, 124.

Авылларда яңа эш

Тәтеш өязендә татарлар иң күп булган Яңа Сала, Бәке, Барыш һәм Никифор волостьлары татар укытучылары оешмасы һәм шул район коммунистлар комитеты тәшәббесе *(тырышлыгы)* белән әлегә кадәр бер җирдә дә булмаган бер рәвештә Сабан туе ясалды.

Югарыда күрсәтелгән дүрт волостьның берләшкән Сабан туе 29, 30 нчы апрель һәм 1 нче майларда Бәге авылы янындагы мәшһүр Чабыр ярминкәсе (җыены) тавында булып, Тәтеш өязе мәсьүлиятле эшчеләре мәзкүр Сабан туена килделәр.

Сабан туенда электән бирле гадәт булып килгән уеннардан башка да бик күп яңалыклар бар иде. Ат чабыштыру, көрәшү, тартышу вә башка шуның шикелле уеннарга башка төрле: шигырьләр уку, декламацияләр сөйләү, спектакльләр, концертлар булды.

Бу Сабан туе көннәрендә югарыда әйтелгән дүрт волостьның укучы балалары кулларына төрле лозунглар язган әләмнәр белән төрле шигырьләр, җырлар җырлап, башларында мөгаллимнәре булган хәлдә тәртип белән тезелеп, Сабан туе була торган Чабыр тавына килделәр. Балалардан оешкан хорлар авыл халыкларына бик тәэсир итә торган җырлар җырладылар.

Бу көннәрдә һәр авылда һәм Сабан туе була торган җирдә укучы балаларга махсус ашлар пешерелеп ашатылды. Халык һәр өч көндә дә бик күп иде. Чиктән тыш шат булып таралдылар. Төрле яңа уеннар күрделәр. Хатын-кызлар да бик күп килгән иде.

Көрәшчеләр бер-берсенең сәләтен *(егу рәтен)* белергә тырыша

Бу Сабан туенда бигрәк тә яшьләр бик шатлык белән катнаштылар.

Митинглар вакытыннан бик тәэсирләнгән муллалар да, халыкның алай шатлык белән бәйрәм итүен тәбрик итеп, нотыклар сөйләделәр.

Бу Сабан туе әле бу якта беренче тапкыр гына булса да, бөтен өязгә бик яхшы эз калдырды.

Бу район Сабан туеннан соң һәр авылның үзенә махсус, әлегә кадәр була торган рәвештә Сабан туйлары булды.

Эшче. – 1920. – 11 май.

Сабан туе ясалу мөнәсәбәте белән

Татарларда иске-искедән язның көнен бәйрәм белән каршы алу, язын кыр эшләренә, сабан сукасына тотыныр алдыннан туй ясау гадәте хөкем сөреп килгән. Бу бәйрәмгә без Сабан туе дибез. Бу безнең искедән калган, искедән

бу көнгә кадәр сакланып килгән үз халкыбызның – тик кул көче белән генә көн күрүче игенче халкыбызның бәйрәме. Шуңар күрә дә без халкыбызның бу бәйрәменә кушылырга, аның киң колачта мәйданга ашуына ярдәм итәргә тиешбез.

Шуңа күрә дә без Хәрби коллегия хозурындагы Сәяси шөгъбә тарафыннан 2 июльдә, җомга көн ясалган Сабан туен, аның соң ясалуына да карамыйча, тәбрик итәбез.

«Тимер ага баласы».
Эшче. – 1920. – 5 июль.

Сабан туенда чәй эчкән чакта

Балалар көрәшенең кызган мәле

Пороховой төбәгендә Сабан туе

Бу ел беренче, икенче һәм өченче майларда Пороховой төбәгендә, Пороховой районы Добровольный пожарныйлар иҗтиһадлары белән, тантаналы рәвештә Сабан туе булып узды.

Пороховой төбәгендә җитешкән батальоннарның һәм укучы яшьләрнең иштиракы *(катнашы)* белән ясалган бу елгы Сабан туе үткән елгы Сабан туйларына караганда күп дәрәҗә өстен һәм күңелле иде. Сабан туенда яңа уеннар күрсәтелгәндә һәм бик тәртипле үткәнгә, халык бик мәмнүн булып таралды.

Шәйхетдин Уразаев.
Татарстан хәбәрләре. – 1921. – 5 май.

Авылларда Сабан туйлары

Бу елгы язның авырлыгына карамастан, авылларда Сабан туйлары ясалуы көтелмәсә дә, халык, ата-бабалардан калган гореф-гадәт буенча, күп авылларда Сабан туйларын ясап үткәрде.

Шулар җөмләсеннән Арча кантоны Балтач авылында 21 апрельдә, пәнҗешәмбе көн ясалган Сабан туе гаять тантаналы рәвештә булып үтте. Укытучы иптәшләрнең катнашуы сәбәпле, башка елларга караганда яхшы, мөкәммәл узды, дияргә мөмкин. Ат чаптыру, көрәш һәм башка төрле иске уеннар өстенә кызык-кызык яңа уеннар күрсәтелде.

Иртәгесен Балтачта «Карл Маркс» театрында укытучылар тарафыннан «Галиябану» уйналды. Авыл тормышыннан алынып язылган бу драма кирәк мөндәриҗәсе *(эчтәлеге)* ягыннан булсын, кирәк уйналуы ягыннан булсын халыкка бик ошады.

«Галиасгар улы».
Татарстан хәбәрләре. – 1921. – 6 май.

Карамал авылында Сабан туе

Минзәлә кантоны Карамалы авылында 19 апрельдә Сабан туе булды. Сабан туена тирә-юньнең байтак аңлы кешеләре җыелган иде. Сабан туе, гадәттәгечә, уеннар белән үтте.

Ләкин Сабан туенда икенче бер начар гадәт күзгә күренеп тора иде. Шул райондагы яхшы гына мәсьүлиятле *(җаваплы)* урында хезмәт итүчеләрнең бутылка-бутылка самогонкалар сатып һәм өй саен эчеп йөрүләре халыкка начар тәэсир калдырды.

Әдәби бер күренеш, митинг кебек нәрсәләрнең исләре дә юк иде. Дөресендә дә, Совет властендә мондый Сабан туйларының ясалуына гаҗәбкә каласың.

Ишкуватов.
Татарстан хәбәрләре. – 1921. – 15 май.

Мәсгуд волостенда Сабан туе

Бөгелмә кантоны Мәсгуд волостенда бу ел Сабан туе башка елларга караганда икенче төстә булды. Һәр авылда Сабан туе вакытында спектакль, митинг булып, халык натуральный налог, яңа декретлар белән таныштырылды. Күңелле уеннар күрсәтелде.

Татарстан хәбәрләре. – 1921. – 15 май.

*Текстларны басмага **Рәйсә Шәрәфиева** һәм **Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.* ■

Безнең мирас №6 июнь 2021

КОТОЧКЫЧ АЧЛЫК

СӘХИФӘ ИДЕЛ БУЕНДАГЫ 1921-1922 НЧЕ ЕЛГЫ АЧЛЫКНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА ҺӘМ АЧЫГЫП ВАФАТ БУЛГАН МӘРХҮМНӘР ИСТӘЛЕГЕНӘ БАГЫШЛАНА.

Ачлык падишаһлыгы

(Спас кантоны)

Фатих Сәйфи-Казанлы

1922 елгы плакат: «Ун тук кеше бер ач кешене коткарырга тиеш! Ун тук кеше өчәр кадактан аена 30 кадак икмәк бирсен!»

Орлыклар...

Кара тау төсле олуг иген баржасы яр буена килеп туктады. Яр өстендә орлык төяргә килгән авыл халкы кырмыска оясындагы шикелле ыгы-зыгы килә.

Орлык төялгән арбалар бөтен урамны тутырган, ял итү юк...

10-15 арба берьюлы баржага керәләр дә бер минут эчендә зур үлчәүле батман белән арбаларын тутырып алга таба китәләр.

– Бер орлыкны әрәм итмә, орлык саны саен чәчеңне бөртекләп йолкырмын, – дип, кемдер кемгә тәнбиһ *(кисәтү)* ясый.

Өрсәң егылырга торган агайларга орлык килгәч хәл кергән, ашыга, кутәрә, йөгерә, тирләгән була...

– Солысын кара әле, тутырган тавыкмыни?

– Борчак белән катыш!

– Бөртеген дә калдырмый чәчәмен!

Кешеләр ябык, тутык бакыр төсле кызылаеп тиреләре сөякләренә ябышкан җирбиткә әйләнгән. Төягән йөктәге торыпша җәймәне шырпылый алмыйлар. Шулай да эш бара. Теше белән, тырнагы белән тарта, йөк, төялеп, авылларга таба ага...

Орлык баржасы янына киләмен...

Кулымда портфель булганга, мине Казаннан килгән берәр түрәгә кабул итеп, үземне чолгап алалар да, төрлесе төрле яктан:

– Бәрәңге буламы? – дип сорый.

– Булачак, булачак!

– Туган, нигә орлыкны атсызларга бирмиләр? – дип гаҗәпсенә.

Икенче берләре, аңар кушылып:

– Мин атсыз түгел, минем дүрт атым бар иде, үзем бишенче ат урынында эшлидер идем, менә бу кыш кына бетте. Миңа орлык бирмиләр, мин көрәк белән казып булса да чәчәр идем. Инде без кая барыйк, – кебек аптырашлы сөальләр яудыралар...

– Атсызларга ун кадак тары, ди.

– Аның белән без нишлик инде?

Тынычландырырга тырышамын, ләкин дәшмәсәләр дә, чәчми калып, тагын шул ачлык дәһшәтен күз алларына китереп булырга кирәк, йөзләрендә авыр хәсрәт эзен югалта алмыйлар.

«

Үлемнәр...

Авылның кыр капкасыннан керүгә, үлем исе килә. Ни өчендер, каберлекнең тышкы ягына чыгарып зур-зур яңа каберләр ясаганнар.

Мин моны сорадым. Бу зур каберләрне «ачлар кабере», диләр.

– Монда бер генә түгел, унар, егермешәр кешене бергә күмгәнгә, алар шулай зур күренәләр, – дип изах *(аңлатма)* бирәләр.

Күрше баржа тирәсендә дә күренеш шундый. Монда кәгъбә бодае төйиләр...

– Америкадан килгән!

– Америкадан килгән!

– Тәме борчак тәме икән!

– Аннан җиңелрәк...

– Советка рәхмәт, үлемнән коткара!

Сүзләр шул тирәдә.

– Әле моны, малай, ару килеш кенә ашасаң, бер атнада кеше булыр идең!

Бу күренешләр кантонның иң күңелле, парлак ягы...

***

Кырлар...

Очсыз-кырыйсыз җәелгән уҗымнардан гына тукылган яшел паласлар дисез-ме? Юк!

Бу ел андый бер үлчәүдәге уҗым шакмаклары белән генә тулган кырларны күрергә мөмкин түгел... Уҗым матур. Арыш көпшәләнә башлаган. Чыгышы тигез, хәзер уҗым төбе күренми. Җирдә дым күп. Өстенә карасаң, җан рәхәтләнә.

Бер-ике җир уҗымны узсаң, уҗым бетә, каты басуга охшаган бер күренеш башлана.

Электә бит уҗым кырында бер генә чәчелмәгән буш шакмак күренмидер иде. Ләкин хәзер уҗым басуын кинәт танып булмый, чөнки чәчелми калган җирләр, өстенә үскән төрле үләннәр белән уҗым кыры төсен югалтканнар, алар каты басу шикелле күренәләр...

Авыл халкы узган саен уҗым кырына карый да:

– Әрәм җирләр! – дип әрни.

Бу кырларда узган ел ачлыгы бөтен сыны белән күтәрелгән.

***

Авыллар...

Кем генә яз көне кояш чыгар алдындагы авыл күренешен белми?..

Авыл иртәнге томан эчендә баткан булса да, ерактан, ярты чакрымнан, бере аркылы бере сузылып киткән әтәч тавышы, этләрнең бергәләп өрүе һәр авылның бик садә *(гади)*, һәрвакыттагы билгеләре...

Хәзер ул юк...

Шәһәр төсле зур авыл янына килсәң дә, ялгыш булсын, бер эт өргәнен, бер әтәч кычкырганын ишетмәссең! Ерактан ук дәһшәтле тынлык. Мондагы көр тавышлы әтәчләр, этләрне җир упканмыни?!

Хәзер бит чәчү өсте...

Иртә белән шакы-шокы сука калагы тавышы бөтен урамны тутыра, таң атуга бөтен авыл хәрәкәткә киләдер иде. Хәзер ул да юк!

Иртә белән зур авылга керсәң, арба тавышы юк, чәчүгә ашыгучылар да күренми, бары шомлы тынлык. Як-ягыңа карасаң, иртәнге шау-шу көтәсең, эзләнәсең, ләкин як-яклап сузылып киткән урам буендагы йортларның кадакланган тәрәзәләре, бикләнгән капкалар, җимерелгән йортларыннан башка бернәрсә юк.

Бөтен авыл, шагыйрь уйлаганча, тынлыктан гына үлмәгән...

Ул бөтен тормышы, җаны белән үлгән! Кешеләре дә, урамы, йортлары, сука калаклары, атлары, этләре, мәчеләре, тавыклары, әтәчләре – барысы да үлгәннәр...

Ямьсез, авыр хәсрәтле күренеш. Акылдан язарга мөмкин. Әйтерсең, бу авыл өстеннән көчле тагун *(чума)* җиле искән дә бер төн эчендә барысын да үтергән!

Әллә Исрафил үлем сурын өргәнме?

Бусы да түгел, монда шәфкатьсез ачлык суры өрелгән...

***

Үлемнәр...

Авылның кыр капкасыннан керүгә, үлем исе килә. Ни өчендер, каберлекнең тышкы ягына чыгарып зур-зур яңа каберләр ясаганнар.

Мин моны сорадым. Бу зур каберләрне «ачлар кабере» диләр.

– Монда бер генә түгел, унар, егермешәр кешене бергә күмгәнгә, алар шулай зур күренәләр, – дип изах *(аңлатма)* бирәләр.

Зур сугышларда гына кешеләрне бер кабергә әрдәнәләп *(рәт-рәт тезеп)* күмәрләр иде, монда сугыш та булмаган, ни өчен мондый җир икътисады кирәк булды икән дип уйларга була. Миңа бер агай бик ипләп кенә, бер дә исе китмичә шулай ди:

– Соңгы ике айда үлемнәр бик күп булды; берәүдә дә үлгәнне кабер казып күмәрлек көч юк. Билгеле, аны өйдә сасытып яткырып булмый, шуңар күрә аны аннан-моннан караштыргалап, күбесен бер дә җумыйча ук каберлек өстенә чыгарып ташлыйлар, шулай итеп һәр көн сигез-тугыз, кайсы көн егермеләп үлек җыела. Арада баерак, тазарак, туганлы үлек булса, шул үз туганы өчен кабер казый да, шул кабергә бер-ике көн җыелган үлекләрне тутыралар, – ди.

Дини җолалар онытылган. Корсак кануны өскә чыккан: кабер газабы онытылган, гүр куркынычы булмаган, фидия-мидия тагын юк. Һавелне *(куркуны)* искә төшерүче дә юк. Коръән укуны да берәү дә сорамый...

– Тизрәк өйдән чыгарсалар иде дә, күмсәләр иде, – диләр.

Берәр йортка барып, ач үлеме алдында Коръән укый башласа, ач, муллага тилмереп карап, бармагын тешләп күрсәтеп, бер кабым икмәк сорый. Аның өчен бер кабым икмәк мең ясиннән артык һәм саваплырак шикелле!

***

Дәһшәтләр...

Борынгы ачлыкларда кеше ашаулар да булган, имеш, дип сөйлиләр иде. Гаҗәпсенүгә калмады. Бу ачлыкта кеше ашау гади күренешкә әйләнгән. Ашыйлар...

Исән калганнарның үзләре дә дәһшәт...

***

Күләгәләр...

Койма буеннан тотынып, акрын гына кыймылдап килгән кеше – ригаясез үлем белән сугышучы яз көне һава иснәп, кошларга карап туенмакчы була...

Хатыннар үзләренең өч баскычлы өйләреннән дүрт аякланып төшәләр, туры басып төшәргә хәлләре юк...

Бу күренешләр уйланганнан, хыялдан бик күпкә дәһшәтлерәк.

Авыл халкының бер шатлыгы, өмете булса, ул да басуның яшеллеге, уҗымнарның матурлыгы. Тырышырбыз, тырмашырбыз, яңага җитәрбез, дип, үзләрен җанландыралар.

Хәзерге «кукуруз» – Америка азыгының балаларның йөздән сиксәненә бирелүе әлегә үлем дулкынын аз гына баса төшкән.

Әле авыл халкы үткән кышның дәһшәтеннән хисап бирә алмый. Өлкәннәр югалганнар хакында уйлый да алмый, чөнки әле аның мие туңган, башы әйләнгән. Алар хәзер бик каты авырудан айнып килүче кеше төсле капшап, тотынып урамга чыгалар да кояшка каршы кызынып торалар.

Татарстан. – 1922. – 23 май.

*Сәхифәне **Рәйсә Шәрәфиева** һәм **Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.* ■

Безнең мирас №6 июнь 2021

Кулъязмалар табып булмасмы? Кулъязмалар!..

(Идел буе археологик экспедициясе көндәлеге)

Миркасыйм Госманов

Миркасыйм Госманов Сарай-Бәркә шәһәрлеген казый

01.-06.09.1961.

1961 ел, 1 сентябрь таң белән сәгать 4 тә «Пар[ижская] коммуна» пароходына утырып, Сталинград өлкәсенә киттем. Максат: А.П.Смирнов җитәкчелегендә Сарай-Бәркәдә бара торган археологик экспедициягә кушылып эшләү.

Пароходта 4 көн йөреп, 5 сентябрьдә Сталинград шәһәренә килеп җиттем. Сталинградта бер кич кунып, иртәгесе көнне сәгать өчләрдә Ленин районының Сарай (Царевка) авылы янындагы экспедиция лагерена килдем. А.П.Смирнов юк, аның урынына экспедициядә начальник булып доцент Г.А.Федоров-Давыдов калган икән. Казаннан килгән отрядның башлыгы И.Вайнер иде.

Тиешле хатларны, документларны тапшырдым.

07.09.1961.

Бүген эшкә чыктым. Эш ярыйсы. Безнең отряд казый башлаган йорт казылмасында эшләдем. Берара хәрабәләрдә «сәяхәт» ясадым. Бик зур мәркәз булган бу Сарай-Бәркә.

Төштән соң өйнең идәнен казыган чакта, бер калак сөяге таптым. Әйләндереп караган идем: ике кеше башы ясалган, игътибар белән карасам, астында гарәпчә язулар да булып чыкты. Вайнер әйтмешли, «колоссальная вещь»! Моңарчы Алтын Урда казылмаларында язу табылмаган иде әле!

Көннең икенче яртысы шул калак сөяге тәэсире шаукымы астында үтте. Авызы колакларына җиткән Вайнер бер литр аракылык «һәдия» итте.

Герман Алексеевичның сүзе шул булды: «Мы, москвичи, думаем, что вас переплюнули, оказывается, вы нас переплюнули! Поздравляю с этой находкой!»

Язуны укып булмый: сөяк тозлы җирдә ятып тозланган, әмма «рух» сыман сүзне анык укып була. Сөяк фотога алынды. Төрелде. Мәскәүгә илтеп, реставрация ясатырга кирәк.[1]

08.-10.09.1961.

Көннәр беркөе эшләп үтәләр. Иртән 5тә торабыз, ашап, эшкә китәбез, сәгать 12дә тагын ашыйбыз, аннан 3кә кадәр эшлибез, аннары көндезге аш һәм ял. Һәркөнне кичен диярлек Актүбәгә барып балык тотабыз. Елга балыкка әкәмәт бай!

11.09.1961.

10 сентябрь кич белән күрше Сарай авылына килеп, Әзһәр Мөхәммәдиев белән Мирзаҗан дигән кешеләрдә кундык. Әйбәт кенә кунак иттеләр.

Мондагы татарлар, нигездә, мишәрләр булырга кирәк. Сөйләшүләре шулай. Иртә белән торып, Мирзаҗан белән зиратка барып, кабер ташларын карадык. Борынгы ташлар юк, бар булса да, язусыз.



Алексей Петрович Смирнов (1899-1974) – фин-угыр һәм болгар археологиясе буенча белгеч, тарих фәннәре докторы, МДУ профессоры.

Герман Алексеевич Федоров-Давыдов (1931-2000) – Алтын Урда археологиясе һәм нумизматикасы буенча белгеч, тарих фәннәре докторы, МДУ профессоры.

[1] Федоров-Давыдов Г.А., Вайнер И.С. О надписи и рисунке на кости из Нового Сарая // Советская археология. 1963. – №2. – С.245; Усманов М.А. О языковых особенностях надписи из Нового Сарая // Советская археология. 1963. – №2. – С.246-248.

Кутуй бабайга кереп чәй эчтек. Чәйдән соң авыл читендәге бер ярга килеп, Әзһәрнең инициативасы белән, казына башладык. Разведка максаты белән.

Адәм сөякләре, чакма тимере, ниһаять, сыңар алка һ.б. Чери башлаган ук очы... Бер мәетнең үкчә сөяге бер кисәк тузга төрелгән булып чыкты. Игътибар белән карый торгач, аның итекнең яки кәвешнең үкчә катыргысы булуы беленде.

Шулай ук ярдан кызыл кирпеч стенаның почмагы чыкты. Казый-казый алҗып беттем, ләкин нәрсә булуын әйтүе кыен! Иртәгә Г.А. белән килеп тикшерергә кирәк булыр, ахрысы. Иң кызыгы: бер пар өзәңге черемәсе, йөгән авызлыгы!

Лагерьга килеп әйткәч, сенсация күтәрелде: табылган әйберләрне төреп куюга ук, машина белән шунда киттек. Планга алынды. Гер[ман] Алек[сеевич] безне кыздырып алды: казымый торып, аларга әйтергә кирәк булган икән.

12.09.1961.

Бүген тагын ял бирделәр: кичәге ялны эшләгән өчен. Әзһәр белән Актүбәгә барып, балык тоттык. Бер зур шомба (ярты метрдан озынрак) һәм шуның кадәр бер судак.

Лагерьдагыларның авызлары ерылды.

13.09.1961.

Бүген төнлә дежур тордым, лагерьны күзәттем, сакладым. Төшке ашка балык кыздырып ашадык.

18.09.1961.

Көннәр казып үтәләр. Узган кичне балыкка барып, төнлә тоттым: 1 кечкенә селдь һәм 6 судак, зурлыгы 70 см булыр, әмма бик авыр! Лагерьдагылар хәйран калдылар.

19.09.1961.

Шәһәр валын казыдык: бик бай. Иң кызыгы: чүлмәк водопровод трубасы, 2 данә һәм башка чүлмәк сыныклары, бакыр тәңкәләр... Вайнер, гадәттәгечә, шапыра һәм мактана, мактана һәм шапыра! Бу буш куык кайчан гына шартлар икән?! Гыйльми мөртәтләр, фикри фахишәләр менә шундый бәндәләрдән чыгадыр инде...

Маләй авылыннан эшләргә килгән татар яшьләре белән сөйләштем – типик мишәрләр: палаталь к, г, моновтонглашу, чуар лексика, әмма бераз башка кабиләләрдән дә кушымта бар кебек.

20.09.1961.

Казылмадан кайтышлый, җирдән бер бөтен чүлмәк казып алдым. Вайнерның авызы колагына җитте: «Опять переплюнули москвичей!» – менә сиңа фән кешесе!.. Премия итеп 2 сум 50 тиен бирде, элекке премиягә кушып, малайлар белән эчтек. Бүген төнлә мин дежур.

21.09.1961.

Узган төнне Мәскәүдән А.П.Смирнов малае Кирилл белән килде.

Иртән подъем... Савыт-саба юу...

Бүген шифаханәдән Әзһәр кайтты, анда бер атна ятты бит! Бүген көн яңгыр, ачы җил, суык, көне буе диярлек чатырда яттым: капчыкта шундый җылы... Алла боерса, берсекөнгә китәчәкбез...

22.09.1961.

Бүген эшкә чыкмадык. Вак яңгыр, ачы җил, азык... Ә капчыкта шундый җылы! Иртәгә сәфәр...

23.09.1961.

Сәгать 12 нче яртыда Сталинградка килдек. Мин, Вайнер белән исәп-хисапны бетереп, 12дәге Ярославль-Астрахань пароходы белән («Волга») Әстерхан ягына йөзеп киттем.

Пароход кузгалып китү белән үк, душка кереп юындым, әй рәхәтләнеп юындым! Иске хәрабәләрнең тузаныннан 20 см ысланган тән яңадан анадан туган кебек булды. Ә кер дигәнең... бер илле... Салкын су белән генә тәнне керсез тотып булмасын яхшы аңладым: Сарай Бәркәдә су кереп тора идем бит!

24.09.1961.

Бүген сәгать 4тә Әстерханга килеп җиттем. «Крестьян йортына» урнаштым. Монда, мөгаен, 3-4 көн булырмын. Иртәгә адрес белән бер кешегә барып чыгасы бар. Аннан вокзалга барып алдан билет алып куярмын... Шәһәрне дә яхшылап аралармын... Кульъязмалар табып булмасмы? Кульъязмалар!..

Бүген пароходта казакъчадан «Алдар-көсә» әңгәмәләрен[2] тәрҗемә итә башлаган идем, хәзер шуңа тотынам: монда эшләргә мөмкинлек булыр кебек, бүлмәдә ике генә кеше торабыз. Ярар.

Нәтиҗә: Вәлид Алиев дигән кешедә тарихи кульъязмалар, дипломатик хатларның копияләрен күрдем. Алдырам.

28.09.1961.

Бүген сәгать 18дә «Бородино» теплоходы белән Казан тарафына йөреп киттек.

30.09.1961.

Теплоходта кеше әз, бу минем өчен бик әйбәт: тыныч кына «Алдар»ны тәрҗемә итәм.

03.10.1961.

Йөзәбез. Кичә кичен «Алдар»ның тәрҗемәсенең караламасын[3] бетердем. Бик әйбәт эшләнде: вакыт иркен, бернинди мәшәкать юк, күңел тыныч.

Бер уңайдан Лион Фейхтвангерның «Ялган Нерон»ын укып бетердем. Шәп әсәр! Их!..

04.10.1961.

Барабыз. Әмма Казанга соңгарып килербез, 6-7 сәгатькә. Салисәгә телеграмма биргән идем: каршы алырмы-юкмы?.. Дулкынланам, ягъни вокзалда 6 сәгать көтеп утырырмы?! Һәрхәлдә, бу кичә күп нәрсә турында сөйләячәк...[4]

*Текстны басмага **Диләрә Госманова** әзерләде.* ■

[2] «Алдар-көсә» – казакъ әкиятләрендәге фольклор персонаж.
[3] Бу әсәрнең тәрҗемәсе, мөгаен, басылмаган.
[4] Миркасыйм Госманов белән Салисә Кәримова 1961 елның 3 ноябрендә өйләнешә.

Безнең мирас №6 июнь 2021

Мөслим турында уймак уйлар

Рамил Муллин

Мөслим муниципаль районы башлыгы Рамил Хәмзә улы Муллин

Дин – кешелекнең, тормышның нигезе. Татар халкы дингә килми, ә дингә кайта. Чөнки милләтебезнең үткәне иманлы, әби-бабаларыбыздан калган бай дини-рухи мирасыбыз бар.

Кайсы гына гасыр әдәбиятын укысак та, мәңгелек төшенчәләр белән очрашабыз: мәхәббәт һәм нәфрәт, югалту һәм табышлар… Бу табигый, чөнки кешенең эчке дөньясы үзгәрми, тышкы тирәлеге генә үзгәрә.

Районда иң кадерлесе – кеше. Аның биредә – кендек каны тамган туган җирендә калуы киләчәгебез өчен бик мөһим.

Демография – иң актуаль проблема. Пьянобор чорында ук Мөслим җирендә кеше яшәгән икән, моннан соң да төбәк гөрләп торырга тиеш. Шәһәрдә яшәү җиңел, ләкин кеше анда үз-үзен, хәтта кешелеген дә югалтырга мөмкин. Милли рухны, мирасыбызны саклауда авылларның урыны бик зур.

Идеологиянең массаларга йогынтысы бүгенге заман күзлегеннән тикшерелмәгән зур мирас әле ул! Моны өйрәнеп, хәзерге тормышка да кулланышка кертәсе иде. Халыкның, дәүләтчелекнең идеологик кыйбласы булмаса, ул таралып бетә. Тел, гореф-гадәт кенә аңа нигез була алмый.

Аллаһы Тәгалә күпме хезмәт куйган колхозларны ни сәбәпле юкка чыгарды? Болар барысы да – рәнҗетелгәннәрнең күз яше, каргышы нәтиҗәсе. Кеше хакына керү, килешүләрне үтәмәү дә булгандыр… Кеше хакы, җәмгыять, милләт хакы дигән төшенчәләр бар! Алар – кагылгысыз!

Мөслимдә «Курай», «Пушкин» һәм «Тукай» скверлары, «Кояшлы Ык» паркы эшләнде. Максатыбыз – бөтен традицияләрне саклап, яңалыкны кертү. «Әлеге эшләрнең бәясе күпме?» – диләр. Мин: «Моны акчага эшләп булмый!» – дип җавап җирәм. Бу – күмәк хезмәт. Ә күмәк хезмәт таулар күчерә.

Табыннар мул, йортлар әйбәт, ләкин кешеләрдән зар-интизарны еш ишетәбез. Ни өчен зарлана? Чөнки шөкер итми! Шөкер итми икән, аның күңеле тыныч булмый. Күңеле тыныч түгел икән, җаны да бәргәләнә. Җаны тыныч булмагач – ул бәхетсез! Мал бар, әмма тынычлык юк! Кеше һәрвакыт нәрсәдер эзли, аңа һаман нидер җитми…

Мөслим матурлык үзәгенә әйләнде. Миңа кайчакта, тәнкыйтьләп: «Нигә матурлыкка ул кадәр игътибар итәргә кирәк инде?!» – диләр. Аллаһ матурлыкны ярата. Аның бер исеме – Җәмил, мәгънәсе – күркәм дигән сүз. Без матур җирдә бәхетле яшәргә тиеш.

Матурлык матурлыкка өнди! Матурлыкны күреп үскән бала гына киләчәктә гүзәллеккә омтылачак. Аларга дөрес нәсыйхәт тә бирелсә, безнең киләчәгебез өметле булачак.

Матурлык инвестиция китерә ала. Без моңа үз мисалыбызда инандык. Матурлыкны тудыручы – тырыш, тугры һәм намуслы кеше. Аңа ышанырга була.

Тарихын, телен, динен белмәгән халыкның киләчәге юк. Мөслим халкы үзенә генә хас күркәм милли йолалары, милли киеме, милли ашлары белән тормышны алып барырга, башкалардан аерылып торырга тиеш.

Бүгенге авыл хуҗалыгы «ДТ» тракторы түгел, ә заманча, комфортлы машиналар, югары технология! Хәзер кешене интектерергә кирәкми, максатыбыз – аз көч кулланып, мул табыш алу.

Иң мөһиме – кешенең рухи дөньясы! Матди дөнья матур булса да, рухи дөнья сай. Җәмгыятьтә булган фаҗигаләрне мин шуның белән бәйлим.

Кешенең рухи дөньясын камилләштерү – иң алдынгы юнәлеш. Тирә-юньне матурларга, гүзәл биналар төзергә була, ә анда нинди рухлы кеше яши?! Монысы бигрәк тә актуаль.

Ватанпәрвәрлек булдыру – төп максат. Үз җирлегендә туып, үз телендә сөйләшеп, милләтенә, туган авылына тугры, әби-бабасын, үз тарихын белгән кеше генә җәмгыятькә файдалы булып, үз урынын таба ала.

Тарих, тел, әдәбият, мәдәният, мәгариф, дин бергә кушылса гына көчле. Ә аларның барысын да шушы җир – Мөслим туфрагы берләштерергә тиеш.

Тарихы булган, үткәнен белгән, җирлектәге шәхесләре белән горурланган кешенең генә киләчәге бар.

Тормыш – театр ул. Әгәр дә син бу тормышта үз ролеңне тапмасаң, һәрвакыт пәрдә артында булачаксың. Ә безгә һәрчак сәхнәдә, алдынгылар сафында калырга кирәк!

Музей иске әйбер җыю гына түгел! Ул – зур тәрбия чарасы, мәгариф учагы!

Иман нуры белән яшәсәң, җирлектә бәрәкәт була. Кешенең тәкәбберлеге, мин-минлеге аңа күп вакытта комачаулый. Гамәлеңне Аллаһы Тәгалә рәхмәте өмет итеп кыласың икән, әлһәмдүлилләһ, Аллаһы Тәгалә җиңеллек бирә. Милләтебезне, телебезне сакларга уйласак, бу эшне иман нуры белән алып барырга тиешбез. Кайда иман нуры көчле, анда халык бай һәм матур яши.

Мөмкин булганча милли чаралар үткәрик. Битараф булмыйк! Татар һәрвакыт басылган, әмма ул хикмәтле халык булган. Дин, тел шул сәбәпле генә сакланып калган. Бүген дөньяның нигъмәтенә баттык, әмма хикмәт җитми. Бар нәрсәне хикмәт белән эшләргә кирәк.

Кеше ләззәтне аракыда, зина кылуда түгел, ә китап укуда, гыйлем-тәрбиядә табарга тиеш. Әгәр дә без балаларыбыз алдына зур максатлар куймасак, аларга төпле тәрбия бирмәсәк, безнең киләчәгебез дә юк дигән сүз.

Рус телен һәм мәдәниятен ихтирам итәм, әмма иң зур теләгем: үз балаларым, райондагы балалар татарча сөйләшсен, иманлы булсыннар иде!

Үз баласы катнашкан Сабан туе, беренчедән, бала өчен кадерле, икенчедән, әти-әнисе мәйданга: «Минем улым-кызым катнаша бит!» – дип килә. Аның өчен бәйрәм аеруча кадерле булачак, чөнки ул – аның мирасы, аның традициясе һәм аның киләчәге! ■

Ык буенда җил исә...

Харрас Әюп

Ык буенда тын каберлек,
Ык буенда җил исә... –
Искән җилдә сибелә комнар,
Сибелә берни белмичә.
Сибелә ачык ярага –
Гасырларның ярасы.
Ничек түзә археолог? –
Көяр күк пумаласы.
Сибелә комнар...
Асларыннан
Богаулы куллар чыга.
Чишегез дигән шикелле,
Каршыга еллар чыга,
Салдырып ала богавын...
Җанда әрну, газап тик:

Кемгә шатлык – ничә гасыр
Соңга калган азатлык?!
Чорларны азат иткәндә,
Чишкәндә богауларын,
Археолог бар дөньяга
Бирәдер сорауларын:
«Елларны һаман да шулай
Богаулап салабызмы?
Кемнәр килеп богаулардан
Аралап ала безне?..»
Ык буенда тын каберлек,
Ык буенда җил исә...
Искән җилдә сибелә комнар,
Сибелә берни белмичә. ■

Төбәкне өйрәнүчеләр җыены

19-20 майда Мөслим авылында **МӨСЛИМ РАЙОНЫ ҺӘМ КӨНЧЫГЫШ ТАТАРСТАН: ҮТКӘННӘН – БҮГЕНГЕ КӨНГӘ (ЭТНОМӘДӘНИ ҮСЕШ, ТЕЛЛӘР, ТРАДИЦИЯЛӘР ҺӘМ НОВАЦИЯЛӘР)** исемле Бөтенроссия фәнни-гамәли, тарихи, туган якны өйрәнүчеләр конференциясе узды.

Игътибарыгызга әлеге фәнни чарадан фотолар һәм берничә мәкалә тәкъдим итәбез.

Фоторепортаж белән
***beznenmiras.ru* сайтыннан**
танышырга мөмкин

Ленар Гобәйдуллин фотолары ■

Безнең мирас №6 июнь 2021

Ык елгасы үзәнлеге – ачылмаган тарих

Альберт Борһанов

Археолог, профессор Альберт Борһанов

2016-2017 нче елларда Табын, Ташлы Яр, Шуган, Керәш-Шуран, Салауз-Мухан, Тамьян, Иске Чакмак авылларында юлыккан 620дән артык экспонатны тәфсилләп өйрәнгәннән соң, Мөслим Туган якны өйрәнү музеена тапшырдым. Табылдыклар арасында аю тешләреннән ясалган сөяк амулет, акула тешләре, күкәй сыман формадагы керамик ядрә аеруча зур кызыксыну уята. Соңгы предмет эче тиз янучан сыеклык белән тутырылып, дошман өстенә ыргытыла торган утлы корал буларак кулланылган. Ядкярләрнең төп өлешен төрле орнаментлар белән бизәлгән савыт фрагментлары тәшкил итә. Аларның шактые бронза һәм тимер дәверләренең башлангыч чорына карый.

2015 елда Тамьян авылы янында археологик казу эшләре оештырдык. Бу тикшеренүләр барышында биредә б.э.к. I меңьеллыкта ук кешеләр яшәгәнлеге ачыкланды. Әлеге борынгы җирлекнең хәзерге рельефы курганны хәтерләтә, мәдәни катламы 130 см тәшкил итә. Табышларның төп өлешен керамик савыт-саба, имезүче хайваннарның сөякләре, бронза очлык, сөяктән һәм таштан ясалган әйберләр алып тора. Эш барышында бу объектның Ык елгасы бассейны төбәге тарихының баш-

лангыч этапларын алга таба тикшерү өчен перспективалы урын булуы ачыкланды.

Музейга тапшырылган табылдыкларның бер өлеше урта гасырларның башлангыч чорларына, Идел Болгарстаны, Җүчи Олысы (Алтын Урда), Казан ханлыгы һәм Нугай Урдасы дәүләтләре чорларына карый, шулай ук XVII-XIX гасырларга нисбәтле керамик савыт-саба фрагментлары да бар. Табылдыклар арасында кием-салымның металл өлешләре, ат йөгәннәрен бизәү элементлары, төсле металл эшләнмәләр дә аз түгел.

Б.э.к. III-б.э.ның III гасырына караган, бронзадан ясалган бизәкле, эполетсыман берничә перәшкә кызыклы. Шулай ук күкрәкчәләр, кыңгырау формасындагы бизәнү әйберсе, алкалар һәм медальоннар да табылды. Кыйммәтле ташлардан, керамикадан, пыяладан, сөяктән һәм металлдан ясалган муенса рәвешендәге бизәнгечләр дә игътибарга лаек. Табылдыклар арасында бизәнү әйберләренең төсле металлдан вак элементларын ясау өчен таш калып та бар.

Шулай ук археологик экспонатлар арасында X-XIV гасырларга караган ук очлары, скиф төрендәге акинак (б.э.к. VI-IV гасырлар), тимер балталар, сөңге очлары, гарпуннар, кискечләр, кадаклар, йозаклар һәм ачкычлар барлыгын да искәртәбез.

2021 елның май аенда да район үзәге Мөслимдә, аның Ык буендагы Кооператив, Пушкин һәм Бакча урамнарында казу эшләре оештырдык. Нәтиҗәдә, VI-VIII гасырларга нисбәтле Кушнаренко культурасына караган кызыл һәм кара балчык керамика, XVI-XIX гасырларда пыяладан ясалган савыт-саба, тимер урак, чүкеч һәм кадак калдыклары, патша заманында сугылган тәңкәләр, хатын-кыз бизәнү әйберләренә юлыктык. Хәзерге вакытта бу табышларны җентекләп өйрәнү белән шөгыльләнәм. Алар барысы да Мөслимгә моннан 300 ел, ә бәлки, аннан да элегрәк нигез салынуын дәлилли. Әлбәттә, аңа кадәр үк Мөслим җире үзләштерелгән, биредә бай мәдәни катлам калган.

Археологик казу эшләре барганын ишетеп, авыл халкы да борынгы ядкярләр алып килә. 2021 ел

Археологик казу эшләре. Мөслим авылы, Ык буе. 2021 ел, май

Равил Темкин фотолары

Мөслим авылы метрикәләре

Зыятдин Нәҗметдинов

Киров өлкәсенең Нократ Аланы районындагы Иске Пенәгәр авылы имамы, тарихчы Зыятдин хәзрәт Нәҗметдинов конференция кунакларын Мөслим авылының метрикә кенәгәләре белән таныштыра.

Ләбүдә ханым һәм Мөслим баба

Кукмара төбәкне өйрәнү музееның директоры Ләбүдә ханым Дәүләтшинаның туган җире – Удмуртия Республикасының Алнаш районы. Ул үзенең нәселен өйрәнә башлады һәм миңа шул райондагы Туембаш авылының метрикә кенәгәләрен гарәп язуыннан тәрҗемә итәргә бирде. Аның бабалары имамнар, бик укымышлы кешеләр булган. 1883 елда указ алган Низаметдин улы Фәттахетдин мелла да Туембашта имам булып тора.

Ләбүдә ханымның эзләнүләре буенча шушы имамнарның башлангычы Мөслим авылына барып тоташырга тиеш иде. Мөслим авылының 1860-1868 нче еллар-

дагы метрикә кенәгәләрен укырга туры килде миңа. Дөрестән дә, 1860 нчы елларда Фәттахетдин Низаметдин улы Мөслимдә мәзин булып тора. Соңыннан ул, Самара губернасының Бөгелмә өязендә белем эстәп, Диния нәзарәтендә указ ала һәм Туембаш авылына имам итеп җибәрелә.



Мөслимнең метрикә кенәгәсендә никахларны теркәү бите. 1860 ел

Әлбәттә, аның Мөслимдә мәзин булып торуы метрикә кенәгәләрендә чагылыш таба. Мәсәлән, 1867 елның 23 апрелендә узган никах язмасында: «Мәзин Фәттахетдин Низаметдин улы кулым куйдым», – дигән юллар бар.

Без, шушы нәселнең Мөслимдәге тамырларын өйрәнүне дәвам итеп, игътибарыбызны халык санын алу материалларына да юнәлтеп, калган буыннарын ачыкладык. Шушы имамнар нәселе Муса улы Мөслим бабайның үзенә барып тоташты. Мөслим бабай 1669 елда туган. Аның улы Мөэмин старшина итеп билгеләнә. Мөэминнең балаларыннан берсе Габдерәшит булган. Аның оныгы – Габделкәрим улы Габделбасыйр. Габделбасыйрның оныгы – Низаметдин улы Фәттахетдин. Аның оныгы – Удмуртиянең Алнаш районындагы Туембаш авылыннан Кукмара төбәгенә кияүгә чыгып, шунда тормыш корып, соңыннан Кукмара төбәкне өйрәнү музееның җитәкчесе булып торган Ләбүдә Әхмәдфида кызы Дәүләтшина.

Әлеге фактларны ачыклаганда, безгә Мөслим авылының халык санын алу материалларын, берничә елгы метрикә кенәгәләрен гарәп язуыннан күчереп, өйрәнергә туры килде. Бу материалларның барысы да бездә бар. Аларны мин аларны бирегә бүләк итеп алып килдем. Тарихыгызны, нәсел шәҗәрәләрегезне, Мөслим тарихын өйрәнүдә бу материаллар ярдәм итә алса, бик шат булыр идек.

«Ул чорда Мөслим кешеләренә бик матур, үзенчәлекле исемнәр кушылган: Бәдрелбанат, Нурлытаифә, Камәрниса, Хәсәнкамал, Бибисәрвихәрам, Бибигайнелхәятсания, Зәйнелбәшир, Миңлеәхмәтнәгыйм һ.б.

Мөслимнең метрикә кенәгәләре ни сөйли?

Ә инде Мөслим авылының метрикә кенәгәләренә кыскача күзәтү ясаганда, шактый кызыклы нәтиҗәләр чыгарырга мөмкин. Беренчедән, алар бик матур язылган. Димәк, мулла талантлы хаттат, каллиграф. Иң элек күзгә чалына торган нәрсә – никах язмаларындагы тамгалар. Алар безнең як тамгаларына охшама-


جزء اول وجوده کیلانلر حقنده

صنف مذکر مؤنث	وجوده کیلانلرنک اسملری	آیلاری وکونلری	وقایع وجنسدان آتاسی وآننک آناسی	ونه دیارده وجوده کیلدی

Мөслимнең метрикә кенәгәсендә балаларны теркәү бите. 1860 ел

ган, артык катлаулы, үзенчәлекле. Ә менә хатын-кыз тамгалары безнең якта да, Мөслимдә дә охшаш. Әйтерсең лә, бар хатын-кызларны бергә җыйганнар да бертөрле тамга салырга өйрәткәннәр.

Соңгы вакытта без еш сүз алып бара торган темаларның берсе – «башкорт сословиесе». Метрикә кенәгәләрендә ул акка кара булып ярылып ята. Мөслим авылы сословие буенча икегә бүленә: «ясаклылар» һәм «башкортлар». «Башкорт» сословиесе күпчелекне – барлык халыкның 90 процентын тәшкил итә. Аңлашыла ки, монда сүз милләт турында бармый.

Ул чорда Мөслим кешеләренә бик матур, үзенчәлекле исемнәр кушылган: Бәдрелбанат, Нурлытаифә, Камәрниса, Хәсәнкамал, Бибисәрвихәрам, Бибигайнелхәятсания, Зәйнелбәшир, Миңлеәхмәтнәгыйм һ.б.

Мөслим авылының метрикә кенәгәләрендәге мәһәр күләме күрсәтелгән. Кукмара төбәгендә 200-300 сум булса, Мөслимдә исә 400-500 сум итеп билгеләнгән. Мәһәр күләме никахны саклауның бер чарасы булып торган. Аерылышканда, хатын-кыз ир-атка мәһәрне тулысынча кайтарырга тиеш булган.

Никах язмаларында тагын бер кызыклы очрак күзәтелә. «Мәзин Фәттахетдин Низаметдин улы, йортта булмаганлыктан, бу мәҗлестә булмады», – диелә анда. Гадәттә, никах язмасына ике имам һәм мәзин кул куярга тиеш була. Аңлашыла ки, мәзин, авылда булмау сәбәпле, әлеге никах мәҗлесендә катнашмый һәм кул куймый. Ләбүдә ханым белән фикерләшкәннән соң, шундый нәтиҗәгә килдек: бу елларда мәзин гаиләсе хәзерге Удмуртиянең Туембашына күченеп йөрмәдеме икән? Фәттахетдин еш кына авылда күренми, әмма язмаларда искә алына, димәк, рәсми рәвештә үз вазыйфасында кала.

1860-1868 нче еллар аралыгында Мөслим кызлары, Мөслимнән кала, Әтрәкле, Чүбекле, Иске Теләнче, Куян, Колын, Мәллә Тамак, Бүләр, Иркәнәш, Ташлыяр, Туйкилде, Тугаш, Карамалы, Сәет, Иске Чакмак һәм Метрәй авылларына кияүгә чыккан. Электән килгән гадәт буенча, никах Мөслимдә укылган.

Вафат булучыларның үлем сәбәбе игътибарга лаек. Метрикә кенәгәләрендә кешеләрнең «эч зәхмәте», «тир рәнҗүе», «зыяндаш» «кызамык зәхмәте», «бизгәк рәнҗүе», «валәдәт, бала рәнҗүе», «ютәл зәхмәте», «чәчәк зәхмәте», «йөрәк рәнҗүе», «шеш рәнҗүе», «валәдәтин рәнҗүе», «аяк җәрәхәте», «күкәк зәхмәте», «фәлеҗ зәхмәте», «бирән зәхмәте», «картлык белән» бакый дөньяга күчкәнлеге языла. Кызганыч, картлык, ягъни табигый үлем белән вафат булучыларның саны бик аз. Бу елларда мөслимлеләрнең гомер озынлыгы уртача 50-60 яшь тәкил иткән, сабый балаларның вафаты табигый күренеш булган. Шунысы игътибарга лаек: озын гомер кичерүчеләр (ә алар бик сирәк) метрикә кенәгәләрендә «картлык белән» түгел, ә төрле зәхмәт һәм чирләрдән үлгән дип күрсәтелә. Әйтик, 85 яшьлек Сафуан Ярмөхәммәд кызы – «тир рәнҗүе»ннән, 90 яшьлек Хәмидулла Габдулла улы – «бизгәк зәхмәте»ннән, 80 яшьлек Хисаметдин Шәриф улы «эч рәнҗүе»ннән якты дөньядан киткән. Әлбәттә, бу «диагноз»ларны бернинди табиб та, патологоанатом да түгел, ә авыл мулласы үзе, мәрхүмне шәхсән белеп яки якыннарыннан сорап куйган.

Төбәгебез тарихи, мәдәни, икътисади яктан да бик нык җепләр белән береккән. Барыбыз бер булып, ярдәмләшеп, тапкан материалларны бүлешеп яшәсәк, Аллаһының ярдәме белән, хакыйкый, чын тарихны торгызырбыз, дип, ныклы ышаныч белән әйтергә мөмкин. ■

«Безнең мирас» котлый!

Қазақстан Республикасының
Президенті

Город Нур-Султан, Акорда

25./02./2021

Л.Х. Хамидуллину

Уважаемый Лирон Хайдарович!

В честь 175-летия великого поэта казахского народа Абая Кунанбайулы выражаю Вам искреннюю благодарность за особый вклад в продвижение духовного наследия Казахстана, укрепление культурных связей между нашими странами и желаю Вам новых успехов в Вашей творческой деятельности.

Касым-Жомарт ТОКАЕВ

24 майда Казан Федераль университетының Император залында тарих фәннәре докторы, профессор, ТР Фәннәр академиясе академигы, РФнең һәм ТРның атказанган фән эшлеклесе Индус Таһировка 85 яшь тулуга багышланган тантаналы чара узды.

Әлеге чарада катнашып, могтабәр юбилярны – «Безнең мирас» журналының редколлегия әгъзасын һәм актив авторын басмабызның баш мөхәррире Ләбиб Лерон да котлады.

***

Татарстан Язучылар берлегендә Казакъстанның Казандагы Генераль консулы Жанболат Мурзалин тәрҗемәче, язучы Лирон Хәмидуллин һәм галим, филология фәннәре докторы Хатыйп Миңнегуловка казакъ-татар мәдәни бәйләнешләрен үстерүгә керткән өлешләре өчен Рәхмәт хатлары тапшырды.

Лирон Хәйдәр улы Хәмидуллин – Казакъстан Президенты Касым-Жомарт Токаевның Рәхмәт хаты, Хатыйп Миңнегулов Казакъстанның Мәдәният министрлыгы Рәхмәт хаты белән бүләкләнде.

Мөхтәрәм авторларыбызны ихластан котлыйбыз! ■

Безнең мирас №6 июнь 2021

Ислам дөньясы

Габдерәшит Ибраһимов

Мукден шәһәре янында

Мукденның әйләнә-тирәсендә

Мукденда өч меңгә якын мөселман яши, өч мәчет һәм өч мәдрәсә бар икән.

Иртәгесе көнне Мөхәммәд Җәмалетдин әфәнде белән Мукден әйләнә-тирәсен карап йөрергә дип чыктык. Мукденның як-ягы киң сахра, авыллар һәм кечкенә шәһәрчекләр бик күп. Болар арасында мөселман авыллары да аз түгел.

Без, әлбәттә инде, башта мөселман авылларын барып күрдек. Дөрес, боларның авыл дип әйтерлек җире дә юк. Балчык сылап ясалган алачыкларында, килгән кеше утырып торыйм дип урын эзләсә, аны таба алмый. Тик шулай булса да, һәр авылда мәчет кебек бер җирләре бар, биредә азаны Мөхәммәди әйтелә һәм күбесенең янәшәсендә мәдрәсә дә бар. Бу яктан күпмедер дәрәҗәдә ислам белгесе бар дип әйтергә мөмкин. Халыкның күпчелеге фәкыйрь булса да, юклык эчендә яшәп ятса да, боларда бертөрле җитдилек һәм эшчәнлек тә сизелә. Бу халыкның кыргый җәнлек дип әйтерлек кайбер шундый яклары бар: мөселман булмаган кытай кешесенең тәне су күрми, гомерендә бер тапкыр да юынмый, арулыкның ни икәнен дә белми. Шул ук вакытта, аларга башка бик әһәмиятле үзенчәлекләр дә хас: ул яктан караганда, кытайларның мәдәнилеге иң нык, какшамас мәдәнилек булып күренә. Кытай кешесе әйткән сүзен беркайчан да аяк астына салмый. Әйтик, сәүдә эшләрендә килешү кәгазенә-фәләнгә хаҗәт юк. Мәсәлән, әгәр бүген бер тауарны алырга дип сөйләшкән, бәясен тәгаенләгән һәм «тауар минеке» дигән икән, иртәгесе көнне ул тауарның бәясе ике тапкырга кимегән булса да, кытай кешесе сүзеннән кире кайтмый. Үзе сата торган тауарга карата да нәкъ шулай. Мин, Мукден янындагы авыл һәм шәһәрчекләрдә йөргәндә, мондый хәлләрне күп тап-

---

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

кырлар үз күзләрем белән күрдем. Шаһит та юк, язу-фәлән дә юк, әлеге мөгамәлә бары тик гадәт ысулы белән башкарыла.

Юлдашым Мөхәммәд Җәмалетдин әфәнде бер авылда шактый гына сарык хайваны сатып алды. Берсе-берсе 4 доллар диелгән иде, гадәт буенча сәүдә мөгамәләсен башкардылар, саткан кеше иртәгесе көнне сарыкларны Мукденга кадәр куып китерәсе һәм акчасын аласы иде. Нәкъ шулай булды да. Тик малларның хуҗасы сарык көтүен куып китергәндә, базарда сарык бәясе бик нык төшкән иде. Шулай булуга да карамастан, Мөхәммәд Җәмалетдин килешенгән бәяне түләде. Менә ул Шәрык мәдәнияте!

Тагын шуны да әйтеп үтәсем килә. Бу халыкта сату-алу ысулы бик сәер, ул дөньяда башка бер генә халыкта да юктыр дип уйлыйм, чөнки күргәнем дә, ишеткәнем дә булмады. Сатучы белән алучы икесе дә кулларын, күрешкән кебек итеп, бер-берсенең җиңе эченә тыгалар. Җиңнәре исә киң һәм озын. Менә шулай җиң эчендә бармаклары белән бәяне билгелиләр һәм килешү тәмам була. Телләре белән бер сүз дә әйтмиләр, бөтен сатулашу җиң эчендә бара. Яннарында йөз кеше торса да, тауарның бәясеннән генә түгел, сатылуыннан яки сатылмавыннан да хәбәрләре булмый. Шул рәвешле, сату-алу эше бары тик ике кеше арасында гына кала. Ләкин шулай булса да, бер генә сәүдәгәр дә соңыннан үз сүзеннән кире кайтмый.

Безнең егерменче гасыр сәүдәсендә әллә никадәр килешү ысуллары булса да, эченнән йөз мең «күз буяулар», «төпсез көймәгә утырту»лар килеп чыга.

Авыл истәлекләре

Кайсы гына авылга барсам да, рус-япон сугышы елларында булган вакыйгалар белән кызыксындым. Бар да рус офицерларының кәеф-сафа коруга бик күңел биргәнлекләрен сөйләделәр. Бигрәк тә Петербург офицерлары, барысы да, әле килгәндә үк, яннарында берничә хатын-кыз китерәләр икән. Хәтта дүртәр, бишәр хатын китерүчеләр дә булган. Шампан шәрабын су урынына эчәләр икән. Бер шешәсенең бәясе 50-100 сумга кадәр җиткән, аннары бар нәрсәгә дә базарда шуңа карап бәя куела торган булган.

Мукден тирәсендә һәм Мукденда яшәүчеләр һәр ике як гаскәрнең хәлләрен күреп гыйбрәтләнгәннәр. Башта ул җирләрдә рус гаскәре торган, аннары япон гаскәре килгән. Икесе турында да фикерләре бар иде.

Рус гаскәре торганда, якын-тирә авыллар бик күп акча эшләп калган. Бер кеше әгәр үзе генә, кул хезмәте белән эш эшләсә, көненә 5 сумнан 9 сумга кадәр генә акча эшләгән. Әгәр ат яисә башка хайван белән эшләсә, көненә 25 сумга кадәр хезмәт хакы алган. Сату-алуда да вак акча дигән нәрсәләр онытылган. Гаскәриләрнең учлары тулы йөзлекләр, ягъни рус акчасы белән йөз сумнар икән.

Ә инде рус гаскәре чигенеп, Мукден тирәсенә япон гаскәре килеп урнашуга, бар нәрсәгә дә тариф билгеләнгән. Сату-алу һәм эшчеләр хезмәтенә, белмим ни өчендер, хөкүмәт тарафыннан бәя куелган. Инде бар да, күпме эшләсә, шулкадәр генә акча алырга тиеш булган.

Бер грузин кешесен очраткан идем. Русия подданные, бу җирләр Русия кулына күчкәч, бирегә килеп, азык-төлек кибете ачкан булган. Руслар чигенгәч, кибетен бикләп, аны бандитларның талавыннан саклап калган, япон гаскәренең килүен көткән. Япон гаскәре килгәч, кибетне ачканчы ук, үзенеке икәнен белдереп, алдан-алы төзегән тауар исемлеген күрсәткән. Гаскәриләр, кибетне ачтырып, исемлекне чагыштырып тикшергәннән соң, моңа болай дигәннәр:

– Биредә сәүдәгезне дәвам итәргә теләсәгез, тауарыгызны менә бу тариф буенча, сатулашусыз сатачаксыз. Әгәр дә бу бәяләр эшегезгә ярамаса, малыгызны алып китәрсез дә рус гаскәренә барып кушылырсыз.

Грузин сәүдәгәр рус гаскәренә барып сыенуны өстен күргән. Японнар аны, тауары белән бергә, почта атлары ярдәмендә рус гаскәренә илтеп тапшырганнар. Малына бер тиенлек тә зыян килмәгән. Рус гаскәренә килеп урнашуга, грузин сәүдәгәр, 1гә 100 процент табыш алырлык итеп, ике-өч сәгать эчендә бөтен тауарын сатып та бетергән.

Бу кеше японнардан зарлана, русларны мактый иде. Анысы, әлбәттә, бик тә табигый хәл. Тик кешелек күзлегеннән чыгып караганда, кайсы як хаклы икән соң?!.

Авыл кешеләренең дә күбесе японнардан зарлана, әмма ризасызлыклары гел әлеге тариф куелу, акча умыру мөмкин булмау белән бәйле иде.

Без иртәдән кичкә кадәр авыллар буйлап йөрибез дә, кич җитүгә, Мукденга кире кайтабыз. Беркөнне кичен Мукденга кайтканда, башымда туган фикерләр белән бәйле рәвештә, Мөхәммәд Җәмалетдин әфәндегә сораулар бирдем. Ул исә миңа: «Мин бу сорауларга лаеклы рәвештә җавап бирә алмыйм. Дөресрәге, тиешле дәрәҗәдә оештырып әйтеп бирә алмаячакмын. Безнең биредә, бәлки, бөтен Маньчжуриягә бердәнбер бай мөселман кешесе бар. Ул кеше бик мәгълүматлы да, рус телен дә бик яхшы белә. Сезнең бар соравыгызга да җавап бирә алыр. Сез дә канәгать калырсыз, ул да Сездән канәгать калыр. Бик яхшы кеше. Иртәгә үк барып күрешербез», – диде. Мин бик шатландым.

Икенче көнне иртән бу кешенең өенә бардык. Ул безне бик ихтирам белән каршы алды. Исеме Җи-Җан-Лу-Айһав икән. Мөхәммәд Җәмалетдин әфәнде безне таныштырды. Җи-Җан-Лу-Айһав әфәнденең русчасы чынлап та бик яхшы иде. Мин, бу форсаттан файдаланып, бик күп нәрсә сорашып белдем.

Бу кеше дә японнарны бер дә яратмый, тик аның яратмавының ниндидер бөтенләй башка бер фикергә нигезләнгәне ачык аңлашыла иде. Миңа болай диде:

– Японнар бик яхшы милләт, эшчән, тырыш милләт. Русларны җиңделәр. Ләкин, оят нидер – белмиләр, җәй җиттеме, чишенеп ташлыйлар, тыелган җирләрне каплау исләрендә дә юк. – Шулай дип сөйләп китте дә, аннары: – Японнар бик минминлекле халык, – дип куйды.

– Ничек мин-минлекле, аңлап җиткермәдем.

– Боларда җаһиллек шул дәрәҗәдә ки, үз күзләребез белән күргәч, хәйран калдык. Сугыш вакытында бик аз япон кешесе әсир төште, чагыштырмача һич төшмәде дип тә әйтергә мөмкин. Моның сәбәбе шул: болар: «Мин әсир төштем», – дип бирелмиләр, үзләрен гел сугыш эчендә кебек тоталар, бер батальон рус гаскәрие бер японны әсир алырга җыенса, теге тере килеш кулга төшми, берүзе сугыша яки акылдан язган кебек һөҗүмгә күчә дә, шактый кешене кырганнан соң, ирешә алса, үзен дә үтерә. Биредә, безнең Мукден хастаханәсендә, яралы килеш әсир төшкән бер япон бар иде. Моны бер рус табибы дәвалый иде. Ничек булган да, моның кулына пычак эләккән һәм бу, шул пычак белән табибны, бер офицерны һәм ике эшчене чәнчеп үтергәннән соң, үзен дә юк итте. Карагыз инде сез менә шул хәлгә: үзе яралы, үзе, әсир була торып, дүрт кеше үтерде.

– Мин биредә аптырарлык берни күрмим, бу үзенә күрә тугрылык белән күңел омтылышы: үлсә үлә, ләкин дошманын дошман дип белә.

– Яхшы яклары да юк түгел, билгеле. Русларда ришвәт бик күп, ә японнарда ул бөтенләй юк. Сугыш вакытында да күренмәде. Бу яктан бик ышанычлы алар. Иң кечкенә түрәләре дә, хәрбиләре дә ышанычлы, нык, бер тиен ришвәт алмый-

лар. Әлбәттә, бу яклары мактауга лаек. Офицерларының күбесе хезмәт хакларын яралыларга бирде. Күчмә хастаханәләре дә тулысынча болар биргән акчага эшли иде. Без алар белән шактый аралаштык, күрдек: бер тиен акчалары читкә китми, әрәм булмый, гел милләт өчен сарыф ителә иде.

– Һәр милләттә, яхшы кешеләр белән бергә, начарлары да була. Мин Сезнең фикерегезне бик үк урынлы түгел дип саныйм. Һичшиксез, күренештә башка максатларга хезмәт итү фикерендә булганнар да бардыр. Гомумән, безнең русларда фидакярлек юк, бу яктан Сез японнарны руслар белән чагыштыра алмассыз. Руслар алар көч белән сугыша, японнар исә акыл белән, чара күреп сугышалар. Араларында менә шундый аерма бар. Мин Сездән шуны сорарга тели идем: японнар русларны чынлап та җиңдеме, әллә бу эшкә бераз хәйлә-мазар яки хыянәт-фәлән дә катнаштымы икән?

– Безгә мәгълүм булганча, японнар, һичшиксез, җиңделәр һәм хаклы буларак җиңделәр. Бер ел буе берөзлексез һөҗүм иттеләр. Бөтен сугышлары һөҗүмнән торды. Руслар гел саклану сугышы алып бардылар һәм бөтен җирдә җиңелеп чигенә бардылар. Мин үзем бу хакта бик тәфсилләп сөйли алмыйм. Биредә бер рус сәүдәгәр бар, хәзер телефоннан хәбәр итәрмен, килсен. Ул кеше Сезгә бик күп мәгълүмат бирә алачак, чөнки сугышның башыннан ахырына кадәр гаскәр белән бергә иде.

Ул шул арада телефоннан ниләрдер әйтте. Минем барыбер эшем юк, мондый кешеләр табылып, ни генә сөйләсәләр дә, тыңлаячакмын. Сорау бирдем:

– Ул рус сәүдәгәре кем?

– Батоев исемле зур сәүдәгәр. Биредә банкы бар, башка төрле сәүдәсенең барысы да Тензиндә[1]. Анда пароходлары бар. Бик яхшы кеше, 25 еллап аралашабыз. Чыгышы белән Русиядән, кайчандыр килеп Тензингә урнашкан. Күптән түгел биредә банк ачты. Бер ай бардыр инде, күрше булып яшибез. Хәзер килер, күрерсез.

Генерал Куропаткин

Ул арада безгә чәй китерделәр. Ун минут үткәндерме-юктырмы, ишектән симез гәүдәле бер рус кешесе керде. Бүреген салып сәлам бирде. Йорт хуҗасы: «Минем 25 еллык дустым Батоев, таныш булыгыз, Ерак Көнчыгышта Ватаны өчен тырышучы русларның берсе», – дип, мине бу кеше белән таныштырды.

Мин, күрешергә кулымны сузып:

– Шатмын, – дидем. Ул да, минем кулымны кысып:

– Мин үзем танышыйм. Сез минем абзыемны танып беләсез. Мин чыгышым белән Петербургтан, – диде.

– Алайса бик яхшы таныйм. Сезнең дә йөзегез таныш, – дидем һәм икебез

[1] Тензин – Кытайда бик борынгы шәһәр, кытай телендәге әйтелеше –Тяньцзянь *(тәрж.иск.)*.

дә арабызда электән таныш кешеләрдә була торган бертөрле якынлык барлыгын күрсәттек.

Күрешүебезгә шат булуымны белдергәннән соң, сөйләшүне һаман да шул сугыш вакыйгаларына таба бордым. Шунда Батоев дускай, бик тирән итеп көрсенеп, болай диде:

– Бу хакта бик тәфсилләп сөйли алмыйм, чөнки вакытым бик тар. Бары бер-ике мәсьәләгә генә кагылып китәрмен. Вакытым аз, хатыным Петербургка киткән иде, бүген кайта, аны каршы аласым бар. Бераз гына безнең русларның кимчелекләре турында әйтеп үтәргә телим. Безнең руслар мин-минлекле милләт. Мәмләкәт, Ватан үзе өчен фидакярлекләр таләп итә. Сугыш та бераз хәйлә һәм астыртынлык белән була, гел көч белән генә булмый. Безнекеләр, көчләре белән масаеп, җиңелүгә дучар булдылар. Японнар, Ходай өчен дөресен әйтергә кирәк, иң олы дәрәҗәдәгесеннән алып иң кечесенә кадәр барысы да Ватаннары өчен ныклык күрсәтеп тырыштылар. Уйлап кына карагыз: шул 14 ай буе барган сугышта японнардан нибарысы мең әсир килде. Без исә 75 мең әсир бирдек. Әйе, югалтулар аларда чагыштырмача күбрәк булды, бәлки әле, ике тапкыр артыктыр да. Тик безнекеләр форсаттан файдалана алмадылар, күпме үкенсәләр дә аз. Куропаткин бик зур хата ясады: Мукден сугышында искиткеч зур югалтуга дучар булдык, һава да бик начар, күз ачкысыз җил-буран иде. Куропаткин чигенү планын әзерли башлады. Шулвакыт мин Куропаткинга: «Мин – гаскәрне ризык белән тәэмин итүче һәм дә рус улы, русмын. Бик күптәннән монда яшәгәнгә, телләрен аңлыйм, гадәтләрен беләм. Ике арада йөргән хунхузлар[2] аша ике якның да нинди көчкә ия булуы турында мәгълүматым бар», – дидем.

Сугыш тактикасы ягыннан да Куропаткин өчен чигенүдән башка юл калмаган; чигенеп качмаса, үзе үк әсир төшәчәк иде. Тик японнарның да инде тыннары кысыла башлаган иде. Мин Куропаткинга шуны тәкъдим иттем: «Рус гаскәре Мукденнан чигенеп чыгып киткәндә, Сез миңа рөхсәт итегез, сәгате-минутында ук 40 мең хунхуз белән урыныгызга мин килеп урнашыйм. Әгәр җиңелә калсам, Сездән бер тиен дә алмам. Ул 40 мең хунхуз җанын фида итәр, бетәр. Әмма җиңеп чыксам, 8 миллион сум акча бирерсез. Минем 40 мең хунхузым коралланган килеш әзер тора», – дидем.

Хунхузлар

Менә уйлап карагыз инде: Куропаткин минем ул тәкъдимемне кабул итмәде. Шуннан соң ике сәгать үткәндерме-юктырмы, шәһәрне калдырып, чигенеп чыгып та китте.

[2] Хунхуз – XIX гасыр ахырлары-XX гасыр башларында Кытайның төньяк-көнчыгышында (Маньчжуриядә) талаулар белән шөгыльләнүче банда кешесе. Кытай теленнән «кызыл сакаллы» дип тәрҗемә ителә *(тәрҗ. иск.)*.

Мукден шәһәре. Император сарае капкасы

Кытайлар сугыш алдыннан авылларыннан качалар.

Мин, бик нык гаҗәпләнгәнгә, уңга-сулга каранып, нәрсә әйтергә дә белмичә торам. Шунда Җи-Җан-Лу-Айһав сүзгә кушылды:

– Әйе, нәкъ шулай булды, без ул вакытлар бергә идек. Хунхузларны җыюны мин оештырган идем. Ләкин берни дә булып чыкмады. Әгәр Куропаткин кабул иткән булса, японнар да бик арыганнар иде инде, 40 мең хунхуз, һичшиксез, җиңеп чыгачак иде, без 8 миллион акчалы буласы идек.

– Әгәр җиңелсәгез, нәрсә булган булыр иде?

– 40 мең хунхузның берсе дә калмаячак, үлгәнче сугышачаклар. Килешү шулай иде. Безнең русларда милләтенә бирелгәнлек юк, гаскәребез менә дигән, тик әгәр

командирлар һәм офицерлар юк икән, аннан ни файда? Офицерлар бөтенләй дә сугышка кермиләр, җитәкчелек итү гел бичара лейтенантларга төшә. Русларда әхлак бозылган, әхлагыннан язган милләт сугыша алмый. Хәтта, әфәндем, сугыш бетәр-бетмәс, мине мәхкәмәгә чакырдылар, теге тәкъдимем өчен мине җәзага тартырга маташтылар. Дар агачына аскан да булырлар иде, әле дә ярый ришвәт дигән нәрсә бар, шуның белән генә башымны коткарып калдым. Ватан өчен нәкъ менә мин корбан китә яздым. Ярар, руслар шулай булды. Сугыштан соңгы бу ике ел эчендә Маньчжуриянең бөтен җиренә, хәтта авылларга да японнар килеп урнашты, безгә берни калмады. Узган ел мин биредә банк ачарга йөргәндә, безнең Русия консулы нинди генә каршылыклар чыгармады, әйтсәм, ышанасыгыз килмәс. Шундый комачаулыклар ясады ки, моның булуы мөмкин түгел, диячәксез. «Ай Алла, мин Сезнең ватандашыгыз! Сезнең мине яклавыгыз кирәк түгелме соң?! Ә Сез, киресенчә, мине батырырга телисез, бу дөрес эшме?» – дип кычкырдым. Хатынымны Петербургка җибәрдем, ул барып мәсьәләне шуннан хәл итте. Әгәр эш безнең консуллыкка калган булса, өмет тә итәсе юк иде. Безнең рус түрәләре менә шундый инде: ришвәт алмаса, бер эшкә дә рөхсәт бирми, әхлак бозылган.

Сәгатенә карап алгач, безнең белән саубуллашты да, Батоев китеп барды.

Мин гаҗәпләнеп тик торам. Ай-һай, мәдәният кайларга кадәр тәрәккый иткән: бер сәүдәгәр 40 мең кешене сугышка кертәчәк, барысы бергә үлеп бетсәләр дә, һич кайгырмый, гаиләләре хәерчеләнер, балалар ач калыр-фәлән дип уйлау юк. Әйе, җиңеп чыккан булсалар, кырыйдан карап торган өчен Батоев 8 миллион сум акча алачак. Торып-торып исем китә: дөньяда кешеләр әнә нинди форсатлардан да файдаланалар икән. Әгәр Куропаткин ризалашкан булса, Батоев, әлбәттә, 8 миллионны кесәсенә салган булыр иде.

Шуннан соң мин дә өй хуҗасы белән саубуллашып, мәдрәсәгә кайтып киттем. Монда шәкертләр белән бераз сөйләшеп утырдым. Төштән соң без Мөхәммәд Җәмалетдин әфәнде белән тагын йөрергә чыктык, Мукденның бар җирен карап йөрдек. Шәһәр зур түгел, әйләнәсе таш диварлар белән уратып алынган. Аның Шәрык мәмләкәтләренең шактый төзек һәм борынгы шәһәрләренең берсе булуы мәгълүм.

Шәһәрнең без аяк басмаган бер җире дә калмагандыр. Түрәләр, полиция кешеләре бар да кытайлар, тик хәрби кешеләрнең япон гаскәриләре булуы күзгә ташлана. Өлкәнең идарәсе кытайлар кулында булса да, төп әмир һәм хаким кешеләрнең японнар булуы ачык аңлашыла иде. Японнарның сәүдәханәләре, почта һәм телеграфханәләре бөтенләй аерылып тора.

Мукденның киләчәктә гаять зур үзәк булачагы шик уятмый. Бер яктан – Порт-Артур юлы, икенче яктан Пекин юлы килеп, биредә берләшеп кенә калмый, атнага өч тапкыр поезд сәфәре белән Аурупа юлына тоташа. Шулай да, Пекин-Урга-Байкал юлы төзелеше тәмамланса, Мукденның икътисади әһәмияте бераз кимер кебек, әмма сәяси әһәмияте мәңге калачак.

Японнар инде Мукденда ныклап урнашканнар. Хәрби көчләренең бу өлкәне һәрвакыт кулда тотачагы ачык аңлашыла. Тик кытайлар японнарга искиткеч зур нәфрәт белән карыйлар: кулларыннан килсә, боларны бер генә көн дә монда тотмаслар иде. Ләкин чаралары юк, үзләрен 99 елга сатканнар бит инде. Әлбәттә, японнар да, шул вакыт үтмичә торып, бу җирләрне бик алай җиңел генә калдырып китмәсләр.

Төрекчәдән ***Асия Рәхимова*** *тәрҗемәсе* ■

безнең мирас №6 июнь 2021

Үтәмеш: дини хәрәкәт

Нияз Исхаков, Резеда Исхакова

«Безнең мирас» журналының ошбу елгы май санында Үтәмеш авылының беренче мәхәллә мәчете һәм имамнары тарихы турындагы мәкаләбез басылып чыккан иде. Әлбәттә, архивларда эзләнә торгач, икенче мәхәллә, авылдагы мәктәп-мәдрәсәләр, керәшеннәрнең исламга кайтуы һәм дини яңарыш хакында да өстәмә мәгълүматлар тупланды. Әлеге фактларны бергә җыеп, укучыларыбыз хозурына тәкъдим итәргә булдык.

Икенче мәхәллә имамнары

Икенче мәхәллә мәчетенең имамы **Лотфулла Хәсән улы Галимбәков** 1879 елның 9 октябрендә Буа өязендәге Татар Безднасы авылында туа. Югары Каракитә авылында имам булып эшли. 1903 елда Үтәмешнең яңа төзелгән икенче мәчетенә имам-хатыйб булып сайлана һәм 1910 елга кадәр шунда хезмәт итә. Бу вакытта мәхәлләдә 268 ир-ат һәм 254 хатын-кыз яши.

1910 елның 24 августындагы мәхәллә җыены тарихта кала. Җыенда катнашучылар исемлеген авыл старостасы Габделвәли Саттар улы имзалый. Анда, Лотфулла Хәсән улының туган авылы Татар Безднасына баш имам булып китүе сәбәпле, **Мөхәммәтгариф Хөснетдин улы Рәшитов** имам-хатыйб итеп сайлана. Буа мәдрәсәсен тәмамлаган хәзрәт бу вакытта Үтәмештә яшәгән була. 1930 елда Мөхәммәтгариф Рәшитов һәм аның гаиләсе, кулаклар исемлегенә кертелеп, Үтәмештән сөрелә.

СВИДѢТЕЛЬСТВО.

Настоящее свидѣтельство, съ приложенiемъ надлежащей печати, отъ Симбирскаго Городского трехкласснаго училища выдано крестьянину Симбирской губернiи ...

въ удостовѣренiе того, что онъ успѣшно выдержалъ испытанiе въ знанiи русскаго языка, установленное для кандидатовъ на должность сельскаго муллы.

г. Симбирскъ 7 октября 1910 года.

При семъ фотографическая карточка.

Члены

Печ. въ Симб. губ. тип.

Сембер губернасының Янтуган авылы крестьяны Мөхәммәтгариф Хөснетдин улының Сембердәге 3 класслы шәһәр училищесында рус теленнән имтихан бирүе турындагы таныклык. 1910 ел

Кулакларны сөрү турындагы 1930 елгы документлар белән танышкач, сөрелергә тиеш булганнар исемлегендә Г**ыйниятулла Сибгатулла улы Сибгатуллинның** да булуы ачыкланды. Исеме халыкка бик билгеле булмаган хәзрәт хакында: *«Үтәмештә ярлы гаиләдә туган, 1917 елга кадәр һәм аннан соң да укытучы, мулла иде»,* – дип язылган. Бу мәгълүмат Гыйниятулла Сибгатулла улының Үтәмеш мәчетендә икенче дәрәҗәле мулла булуын күрсәтә, чөнки ул имам-хатыйблар исемлегендә юк.

Үтәмеш – мәгариф учагы

Күп очракта имамнар, мәчеттә эшләүдән кала, мәктәпләрдә ислам нигезләрен өйрәтү һәм мөдәррис, мөдир, мөгаллим, хәлфә хезмәтләрен дә башкарган. Дини я нәзарәтендә имтиханнар тапшырганда, мәхәллә имамы булу өчен сынаулар үтүчегә мөгаллим – башлангыч мөселман мәктәбе укытучысы белгечлеге дә бирелгән.

1866-1869 нчы еллар өчен Сембер өязе буенча төзелгән исемлектә Үтәмештә башлангыч училище һәм анда 32 укучы бала булуы күрсәтелгән. 1892 елда Үтәмештә яшәүче крестьяннар җәмгыяте тарафыннан мәдрәсә ачыла. Анда укыту эшләрен авыл муллалары башкара. Алар шәкертләргә татарча һәм гарәпчә укуязу, санау (хисап) буенча сабак бирәләр. Казан университеты басмаханәсендә нәшер ителгән «Әлифба», «Иман шарты», «Ясин», «Һәфтияк-шәриф» һәм башка шундый китаплардан файдаланып, ислам нигезләрен өйрәтәләр. Бу елда шәкертләр саны 30 кеше тәшкил итә. Уку-укыту эшләре мәчет янында урнашкан бинада алып барыла. Балалар үз хисапларына яши.

1894 ел өчен менә мондый саннар билгеле: укучы ир-балаларның гомуми исәбе – 50; алардан 20 бала – 1-2 нче елын, 15 бала – 3 нче елын, 10 бала – 4 нче елын, 5 бала 5-6 нчы елын укый. Үтәмеш мәдрәсәсендә авыл балаларын татарча укырга-язарга өйрәтәләр.

Үтәмешнең 2 нче мәхәллә мәдрәсәсе 1905 елда ачылган. Әмма мәдрәсә ачу өчен рөхсәт алынмаган һәм рус теле укытылмаган. Мәдрәсәдә балаларны указлы мулла Мөхәммәтгариф Хөснетдин улының укытуы мәгълүм.

1912 ел өчен мәгълүмат: рус теле укытылмаган, укыту эшләрен, шул исәптән, дин дәресләрен указлы мулла Сөнгатулла Хөснетдин улы башкарган. Мөгаллим Самара ахуны Шиһабетдин Минушев мәдрәсәсендә гыйлем эстәгән.

Керәшеннәрнең мөселманлыкка кайтуы

Сембер губернасын оештырганда, ягъни 1780 елда Үтәмеш авылында 93 ясаклы һәм 14 чукынган татар яшәгән. 1834 елгы ревизия вакытында Үтәмештә 5 гаиләдән торган 11 чукынган татар исәпкә алына. 1905 елда да нибары 5 гаилә керәшен булып саналган. Димәк, 125 ел дәвамында Үтәмештә керәшеннәр саны үзгәрмәгән, әмма авыл халкы ун мәртәбә арткан. Бу хәлне болай аңларга кирәк: керәшен дип саналучы үтәмешлеләрнең кайберләре үзләрен рәсми исемлектән төшертеп калдыруга ирешә алган. Шуңа да карамастан, үтәмешлеләр һәм андагы руханилар өчен керәшеннәр хәле көнүзәк мәсьәлә булып кала биргән.

20 нче йөзнең 60 нчы елларында Сембер һәм Буа өязләрендә яшәүче керәшеннәрнең бердәм рәвештә мөселманлыкка кире кайту омтылышы башлана.

Керәшен булып саналучы үтәмешле Әхмәтсадыйкның әлеге көрәштә актив катнашуы, авылдашларын да ислам диненә кайтырга «котыртуы» билгеле. Әмма бу вакытта әлеге мәсьәлә ахыргача чишелә алмый, патша хакимияте, чиркәү бу хәрәкәткә тулысынча каршы була. Әмма үтәмешлеләр көрәшне дәвам иткән: керәшен булуга карамастан, мәчеткә йөрмәсә дә, намаз укыган, ураза тоткан, мөмкинлеге булса, корбанын да чалган.

«Манаралар сүтү эшен башкаруга чит авылдан татар булмаганнарны китерделәр. Бу хәлне авыл халкы өй артына бакчага чыгып карап тору белән генә чикләнергә мәҗбүр булды».

Үтәмештә яшәгән һәм керәшеннәр дип саналганнарның рәсми рәвештә мөселманлыкка кире кайтуы тулысынча 1905 елда гына хәл ителә. Бу елның 22 сентябрендә Сембер губерна идарәсенә *«православие динендә торалар»* дип саналучы Үтәмеш крестьяннарының гаилә башлыклары Хөсәен Хәсәнов, Хөснетдин Хөсәенов, Дәүләтша Әхмәтов, Миңлегали Фәткуллов, Әхмәтҗан Мохтаровлардан үтенеч язуы килә. Гаризаның эчтәлеге шуннан гыйбарәт: *«Әлегә кадәр без һәм безнең гаиләләр метрика кенәгәләренә язылмаган һәм һичкайда мәхәллә булып исәпләнмибез; шул сәбәпле Үтәмешнең 1 нче мәхәлләсенә кертү турында әмер бирүегезне үтенәбез; үтенеч язуын тапшыру өчен үз арабыздан Хөсәен Хәсәновны вәкил итеп җибәрәбез».* Үтенеч язуына православие динендә дип саналучыларның, ә чынбарлыкта инде күптән ислам динендә булучыларның исемлеге беркетелә.

1905 елның 30 октябрендә Сембер өязе приставы Үтәмешкә килә һәм исламга рәсми кайтуны үтенүче гаиләләрнең исемлеген тикшерә, сорау алу үткәрә һәм шуңа инана: *«Үтенүчеләр православие динендә дип исәпләнсәләр дә, чынбарлыкта ислам динендә торалар – ураза тоталар, корбан чалу йолаларын үтиләр, мәчетләрдә гыйбадәт кылалар, рухи ихтыяҗлары белән муллага мөраҗәгать итәләр, православие динен бөтенләй белмиләр. Беренче мәхәллә мәчетенә беркетелергә телиләр».*

Сембер губерна идарәсенең 1905 елның 17 ноябрендә җибәргән рәсми кәгазенә Сембер Духовный консисториясе, тарта-суза ярты ел вакытны үткәреп, 1906 елның 29 апрелендә мондый эчтәлектәге хат белән җавап бирә: *«Хөсәен Хәсәнов һәм башкаларны, хатка беркетелгән исемлек буенча барысы биш гаилә, православлар саныннан чыгару һәм Сембер өязе Үтәмеш авылының мөселман динен тотучылар исемлегенә кертү өчен Епархия җитәкчелеге тарафыннан законлы каршылыклар юк».*

Менә шундый күп баскычлы һәм озакка сузылган тикшерүләрне үтеп, керәшеннәр дип саналучы үтәмешлеләр, ниһаять, максатларына ирешә – Русия хөкүмәт органнары тарафыннан кысрыклауларсыз һәм чиркәү эзәрлекләүләреннән арынып, ислам дине йолаларын ирекле рәвештә үти алу мөмкинлегенә ия була.

Дингә һөҗүм

Әмма большевиклар христиан миссионерларыныкыннан да куркынычрак һөҗүмнәр оештыра. Билгеле булганча, 1930 нчы елларда СССРда барлык

мәчетләр диярлек ябыла, манаралары һәм миһраблары сүтелә. Бу хәл Үтәмеш мәчетләрен дә читләтеп узмый. Шушы эшләрнең Үтәмеш мәчетләренә карата ничек итеп оештырылган һәм башкарылганлыгы турында ул вакытта 9 яшендә булган Фәрит Әбүбәкер улы Йосыпов менә болай сөйләгән иде: *«Манаралар сүтү эшен башкаруга чит авылдан татар булмаганнарны китерделәр. Бу хәлне авыл халкы өй артына бакчага чыгып карап тору белән генә чикләнергә мәҗбүр булды».*

Үтәмеш мәчетенең хәзерге замандагы күренеше

Совет хакимияте елларында рәсми рәвештә илнең барлык төбәкләрендә дә дин тулысынча дип әйтерлек бастырылып торды, ә «мулла» иң түбән, дәрәҗәсез сүз булды. Әмма ул заманнарда да әби-бабаларыбыз һәм урта яшьтәге хатын-кызларның бер өлеше ураза тотты, гает һәм башка дини бәйрәмнәрне искә алып, билгеләп үтә иде. Үтәмештә дә гает намазларын уку аерым бер йортта уздырылып, бу эшне Минуш Мостай улының дүртенче буын оныгы **Халит Хәлилрахман улы Минушев** оештырды. Авылыбызда барлык дини йолаларны башкаручы да, соңгы юлга китүчеләрне юып, кәфенләп, җеназа намазын укып озатучы да әлеге мөхтәрәм шәхес булды. Дингә ихлас күңел биреп, чын йөрәге белән инанып йөрүе, сөйләгән вәгазьләре аша авыл халкына дини мәгълүмат җиткереп торуы белән ул мөгаллим дә, остаз да иде. Халит Хәлилрахман улы шул рәвешле авылдашлары арасында хөрмәт казанды.

Үтәмеш халкында совет чорында дин исламны саклап калуда, кызганыч, хәзер инде исеме мәгълүм булмаган һәм күпләр тарафыннан *«Остазбикә әби»* дип аталучы абыстаебызның да роле зур булды. Ул читтән килгән иде һәм 1960 нчы елларга кадәр Яңа урамда яшәүче Бибисара Ильясованың кунагы булып кала бирде. Сугыштан соңгы елларның берсендә *«Остазбикә әби»* җитәкчелегендә Үтәмештән бер төркем әбиләр Шәһри Болгарга сәфәр кылды.

1980 нче еллар ахырында илебездә яңарыш чоры башлангач, сәяси ирек бераз киңәйде, коммунизм идеологиясе читкә этәрелде һәм шуның белән бер үк вакытта үтәмешлеләр мәчет төзү эшенә кереште. Бу хәл, гомумән алганда, авылдашларны берләштерүче мөһим бер вакыйга булды, чөнки мәчет төзү эшләре бөтен авыл халкы катнашында алып барылды. Шушы зур күләмле, катлаулы эшләрне оештыручылар һәм гамәлгә ашыручылар рәтендә ике шәхес – **Харис Муса улы Ибраһимов** һәм **Харис Бәдретдин улы Камалиев** аеруча актив катнашты. Яңа мәчет төзү эшләре 1997 елның октябрь аенда төгәлләнде.

Кыяметдин Җиһанша улы Әхмәтшин 1939 елда сүтелгән мәчет манарасында

булган айны саклап кала алган. Аның теләгән балалары тормышка ашыра: айны яңа төзелә торган мәчеттә куллану өчен Харис Муса улына тапшыра. Элекке мәчет манарасындагы ай 58 елдан соң яңа гыйбадәтханәдә урын алды. Хәзер ул Үтәмеш мәчетенең ишек өстен бизи. Ул дин ислам йолаларының совет чорында да өзлексез, әмма яшерен башкарылуын символлаштыра һәм гыйбрәтле билге булып кабул ителә. Бу айның ясалу тарихы да үзенчәлекле. 2 нче мәхәллә мәчетен төзегән вакытта (1903 ел) манарага куелачак айның макетын **Сираҗетдин Мөхәммәтша улы Батталов** ясый һәм аны Түбән Тагил осталарына алып бара. Анда, макеттан файдаланып, мәчет өчен ярымай ясыйлар. Бу хәбәрне безгә Сираҗетдин Мөхәммәтша улының Әлмәттә яшәүче оныгы Зөһрә ханым җиткерде.

Ярымайны һәм аның җайланмаларын ясау күпкырлы һәм махсус белем сорый торган хезмәт. Үтәмешнең яңа мәчет манарасына куелган ярымайны ясаганда элеккеге мәчет ае үрнәк итеп алынды. Кирәкле булган сызымнарны 1:1 масштаблы итеп, мәчет айлары ясауда тәҗрибәле булган инженер-конструктор **Әнсәр Галимов** әзерләде. Шушы сызымнар буенча ярымайны ясау Казанның Оргсинтез берләшмәсендә башкарылды. Бу эшне, берләшмә җитәкчелеге белән килешеп, **Ринат Бәдретдин улы Камалиев** оештырды һәм ярымайны ясауда турыдан-туры катнашты.

Халит Минушев – Минуш бабайның дүртенче буын оныгы, совет һәм аннан соңгы елларда Үтәмеш имамы

Беренче көннән үк мәчеттә мулла вазыйфаларын башкаруны, үтәмешлеләрнең теләге һәм хуплавы белән, Халит Хәлилрахман улы Минушев үз өстенә алды. Хәзрәтебез моңа тулысынча лаеклы иде, чөнки, югарыда әйткәнебезчә, Советлар хакимлек иткән дистәләрчә еллар дәвамында асылда авыл мулласы вазыйфасын ул башкарды. Үзлегеннән өйрәнеп, дини белемен яңартып, мәчет имамы вазыйфаларын үтәү дәрәҗәсенә ул күптән әзер иде.

Халит Хәлилрахман улыннан соң Үтәмешкә мулла итеп **Рамил Җәүдәт улы Камалов** билгеләнде. Ул дини белемне бай тарихлы Буа мәдрәсәсендә алган. Хәзерге вакытта Үтәмеш халкына Аллаһ сүзен һәм пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) сөннәтен җиткерүдә аның хезмәте гаять зур һәм ихтирамга лаек. ■

Безнең мирас №6 июнь 2021

СӘЙФ САРАИНЫҢ ТУУЫНА 700 ЕЛ

Сәйф Сараи лирикасыннан мисаллар

Сәйф Сараи. ***Надия Фәхретдинова рәсеме***

II. [Күренер (газәл)] (263 б.)

Күрекле йөзеңә баккан күзләргә җан күренер,
Даим мөрәссәгъ (нурлы. – **Х.М.**) агзың гәүһәр-фишан
(гәүһәр сибүче кебек. – **Х.М.**) күренер.
Базар эчендә хөснең гишвә (назлылык, «кокетство». – **Х.М.**) сатыб,
алыр җан,
Бостан эчендә каддең (буен. – **Х.М.**) сәрве рәван күренер.

Хак соңгы (Ходай яраткан. – **Х.М.**) ай йөзеңне кыйлмак өчен тамаша,
Һәр собхдәм (иртәдә. – **Х.М.**) капуыңда (капкаңда. – **Х.М.**)
халкы җәһан күренер.

Ахыры. Башы журналның 5 нче (2021) санында.

Иртә-кичә күземдән китмәс өчен хәйалың,
Ни йиргә баксам, анда хөснең гайан (ачык. – **Х.М.**) күренер.

Сәйф Сараи назмы хөснең сыйфаты берлә
Даим бу ил телендә хуш дилсетан
(искиткеч; мавыктыргыч. – **Х.М.**) күренер.

[Күзләрең (газәл)] (263-264 б.)

Корыб кашы йасен кара күзләрең,
Атар керпек укын мәңа күзләрең.

Бер ук берлә Рөстәмне атдан екар,
Ничә атса кылмас хата күзләрең.

Каракчы бәла кылса төз йазида (далада. – **Х.М.**),
Кылыр даим илдә бәла күзләрең.

Алыр сабыр җандан, күңелдән карар,
Кемә бакса бер гәз (мәртәбә. – **Х.М.**) кыя күзләрең.

Күңелләрне баглаб кара зөлфенә (чәченә. – **Х.М.**),
Усанмасмы (туймасмы. – **Х.М.**) җанлар ала күзләрең.

Ни йулдан бу Сәйф Сараиның уш,
Түкеб канын эчәр кана (комсыз. – **Х.М.**) күзләрең.

Әгәр «һай!» димәсәң, җәһанны хараб
Кылыр гамзә (күз кысуың. – **Х.М.**) берлән йәнә күзләрең.

[«Күрккә баем...» (газәл)] (264-265 б.)

Йаңа айдыр кашың, әй күрккә баем,
Кылыр бәйрәм йөзеңне күрсә саим (ураза тотучы. – **Х.М.**).

Су эчкәндә дудагыңдан (иренеңнән. – **Х.М.**) су тамса,
Бөтәр канд-у шәкәр ул йирдә даим
(Ул җирдә һәрчак шикәр камышы үсәр. – **Х.М.**).

Җәмалыңдыр – бу көн галәм сафасы,
Хәйалыңдыр – һәмизә җан физаем
(Һәрчак күңелемне күтәрүче. – **Х.М.**).

Кирәк үлтер, кирәк асра, – колыңмән,
Мөбарәк боерыгыңдыр, котлы раем (теләгем. – **Х.М.**).

Мөфәррих (сөенеп. – **Х.М.**) назм итеб Сәйф Сараи,
Сыйфатыңны укыр, әй күрккә баем.

Робагый

Кем килде исә җәһанга шәкк йук ки, китәр,
Гакыйл кәлибән (килеп. – **Х.М.**), бу йирдә күб хәйр итәр.
Сән игелек ит, дәгый тиңизгә салгыл,
Йазида (далада. – **Х.М.**) сәңа, йакыйн (якын. – **Х.М.**)
бел, ул хәйр йитәр (266 б.).

III. «Сөһәйл вә Гөлдерсен» (1394) дастаныннан өзек
(хәзерге телгә Н.Арсланов тәрҗемәсе) (284-285 б.)

Бу язма бер хыял җимеше түгелдер,
Ике гашыйк турында, булган эш бер.

Дәвернең сөйлим аглап бер җәфасын,
Бер ирнең кыйссасын, газап-хафасын.

Тимерләнг Үргәнечкә яу китергәч,
Колак тонды, ә күзләр булды күрмәс.

Сугыштан купты бар галәмдә туфан,
Агызды, су кебек, җир өстенә кан.

Игенче өйләрен яндырды утта,
Бодай тапталды, туфрак булды ботка.

Үлеп калды сугышта Туктамыш хан*,
Туганнан аерылып калды туышкан.

Сөһәйл – гаскәр башы әсир ителде,
Бу хәл һәркемгә зур кайгы китерде.

Сугышчылар кылалмый калды чара,
Бу кайгы булды бар күңелгә яра.

Йосыфтан да егет матур чырайлы,
Йөзендә балкыйдыр алманың алы.

Гаҗәп сыйфатлары бар, сүзе татлы,
Гашыйк итәр Шириндәй пәри затны.

Ләкин язмыш ташы төшеп башына,
Башын салган егет гаме кашына.

Залимнәрдән рәхим-шәфкатьме тапсын,
Моңын кемгә сөйләп эчен бушатсын!

Моны күргәннәр аһ итә, елаша,
Очар кошлар аның хәлен сораша.

Гөлестан җырчысы – былбыл тыналмый,
Өзеп моңлы итеп сайрый да сайрый.

Башын игән тулып алтын башаклар,
Башакларны җыярга җитте чаклар.

Игәр илгә дип ашлык гел игенче,
Аның бар иккәне – бәхет һәм энҗе!

Агачларда үсәр татлы җимешләр...
Бу җирне бик дөрес оҗмах димешләр.

Сөһәйл юлдан бара, йөзе ваемлы,
Кара көйгән җаны, күзләре дымлы.

Аның күңеле боек, йөзендә яшьләр,
Күренми күзенә гөлләр, агачлар...

*Әсәрләрне журналга филология фәннәре докторы, профессор **Хатыйп Миңнегулов** әзерләде.* ■

* Төгәлсезлек киткән булса кирәк. Чынлыкта Алтын Урда ханы Туктамыш (1406)/1407 елда һәлак була *(тәрҗ. иск.)*.

Безнең мирас №6 июнь 2021

Дөррәт әл-фахирә яки Ахирәтнамә

Габдерәхим Утыз-Имәни

Сыйфаты нәфгы әс-сур

Бәян улды үлекнең анча хале,
Дәхи әйтәй кабердин соң мәәле.
Урулса сур Кыямәт көндә, әй хак,
Чыкарлар кабредин һәр чост, чалак.
Дәхи мәхшүр уланча ула мәсьүл,
Хәйре – шәррдин нә микъдар итде мәгъмүл.
Сәгадәтлә шәкәвать анда тәфсыйл,
Табар җөмлә мәганиләр би-тәгъдил.
Бу әһвал Кыяматкә би-тәгъйин,
Кәрәк иман кәтүрсәң содк-у-тәмкин.

Дәвамы. Башы журналның 5 нче (2021) санында.

Дәхи тәхсил идәрсәң содкы иман,
Көнүн сәгый ит, хөләсә эстә дәрман.
Бәһар керми өчүн сайә идәрсән,
Кышның салкынлыгына хәүф идәрсән.
Кыйлурсән дәфгычүн чук хәйлә, тәзвир,
Сарай вә ханә вә мәнзил би-тәүфир.
Җәһәннәм һәрридин низ сайә дәр-кяр,
Кышның салкынлыгы дик зәмһәрир бар.
Колакыңга дукынса ошбу әхйар,
Телең берлән дийәрсән сад камәз бар.
Вәли фигълеңдә йук асәре тәсдыйк,
Фигалең җөмләсидүр фигъле зәндыйк.
Хәбәр вирсә сәңа бер дусты-ярың,
Хәзәр кыйл: зәһри вардур бу тәгамның.
Телең берлә аны тасдыйк идәрсән,
Әлең берлән тәнавил әйләйүрсән.
Телең тасдыйкыны батыйл идәр ул,
Тәмам адәмләреңдүр шөйлә бәд халь.
Булынмаз бу гасырда әһле тәхкыйкъ,
Телең тасдыйкыни фигъле мосаддыйк.
Тәмам итмеш нәфәскә икътидасын,
Теле ялган сөйләрдин интимасын.

Тәрҗемәсе:

Сур быргысын кычкырту бәяны

Үлекнең андагы хәле бәян ителде.
Һәм дә әйтәм кабердәге соңгы халәтен.
Сур өрелсә Кыямәт көнендә, әй мөселман,
Чыгарлар кабердән барлык зирәк, үткен, булдыклылар.
Һәм дә мәхшәр көненәчә җаваплы булыр алар –
Никадәрле игелек һәм яманлык эшләгәнгә.
Бәхет белән бәла анда аерып аңлатылган.
Табар ул барлык мәгънәләрне гаделлек белән.
Бу куркулар Кыямәт көненә ачык күрсәтер (чын халәтне),
Иман китерү кирәк, эчкерсез буйсыну белән.
Һәм дә тугрылык белән иман китерсәң,
Көн дә тырышлык күрсәт, чын күңелдән көч-куәт эзлә.
Язга кермәс борын күләгә эзләрсең,
Кышның салкынлыгыннан куркырсың.
Аңардан саклану өчен күп хәйлә, саклану күрерсең,
Сарай, йорт һәм торактан файдаланырсың.
Җәһәннәм кызулыгыннан шулай ук күләгә кирәк,
Кышның салкынлыгы кадәр көчле эссесе бар.
Колагыңа килеп җитсә бу хәбәрләр,
Телең белән әйтерсең: «Йөз адым бар».

Әгәр эшләреңдә булмаса боларны чын раслау,
Барлык гамәлләрең чынлыкта динсез булыр.
Сиңа хәбәр бирсә бер якын дустың,
Саклан: агуы бардыр бу азыкның.
Телең белән ул сүзләрнең дөреслеген танырсың,
Кулың белән аның ашын ашарсың.
Телең белән раслаганны ул яраксызга чыгарыр,
Барлык кешеләрнең хәле шундый бозык булыр.
Булмас бу гасырда хакыйкатьне тапкан кеше,
Теле белән раслаганның эше белән дөреслеген ныгытучы.
Барысы да нәфсегә ияргән булыр,
Теле ялган сөйләүдән котыла алмас.

Дүртенче баб
Фи бәяне нәфгы әл-җәүр

Сурың шәкли ирүр бер кырун әгъзам,
Вакыт йитсә, кыйлур аңа милке дәм.
Бу хальдә агзыйга алуб торубдур,
Качан фәрман кәлүр дип монтазыйрдур.
Качан фәрманы ирүшсә, ул орур дәм,
Улыр ул дәм тәмам фәрзәндә адәм.
Йир вә күк әһли, бәлки, калмагай хәй,
Котылмас җан ияседин берәр шәй.
Мәгәр калур сәламәт түрт мокаррәб,
Улыр вакты билән ул түрт мөһәззәб.
Кырык елдан йәнә бер сурны үргай,
Тәмам әмват терелеп тугры торгай.
Идүп мәхшәр йиригә интизари,
Сәгадәткә йитүшмәк ифтикари.
Улур барча бәрһәнә, башлар ачык,
Улумаз сәр-у-сәр җаи качык.
Табулмас бер посук җай йир йөзидин,
Ятур ирдүң посып адәм күзидин.
Булынмаз анда әшҗар, таш вә тагы,
Улумаз һәм дәхи пәст вә бөләнди.
Улур һәмвар зәмин бер ак көмеш дик,
Мисале гүйә бер мәбсут адым дик.
Нәҗүмләр асмандин түкәлүрләр,
Дәхи матмус улур шәмсе камәрләр.
Йарылур ул вакыт күкләр тәмами,
Бузулур һәр шәй анда интизами.
Ирүб, түкүлүр йирә, ирмеш күмүшдик,
Улур таглар һавада һәмчү йондик...

Тәрҗемәсе:

Җәфа күрүнең файдасы турындагы бәян

Сур өрүнең вакыты тулы бер гасыр булыр,
Вакыты җитсә, аны хөкемдар шундук өрер.
Бу чакта аны авызына алып торыр,
Кайчан боерык килер, дип көтеп торыр.
Боерык килеп җитсә, ул шундук өрер,
Шул ук мизгелдә аны бар кеше белер.
Җир һәм күк йөзендә беркем исән-сау калмас,
Җан иясеннән берсе дә котылып калмас.
Әгәр калса сәламәт дүрт якын кеше (дүрт мәзһәб иясе),
Вакыты җиткәч, булыр алар дүрт яхшы, әдәпле.
Кырык елдан соң тагын бер сурны өрер,
Барлык мәетләр терелеп аякка басар.
Мәхшәр урынын зарыгып көтеп торырлар,
Бәхеткә ирешер өчен, барлык фәкыйрьләр.
Барысы да ялангач булыр, башлары ачык,
Булмас яшерен эшләр өчен җайлы урын.
Табылмас бер яшерен урын җир йөзендә,
Ятар идең кеше күзеннән посып.
Булмас анда агачлар, таш һәм тау,
Шулай ук булмас иңкүлек һәм биеклек.
Булыр бер тигез җир – ак көмеш кебек –
Гүя бер зур адым кебек.
Йолдызлар күк йөзеннән төшәрләр
Һәм дә юк ителгән булыр кояш һәм айлар.
Күкләр ул вакыт тулысынча ярылыр,
Бозылыр анда һәрнәрсәнең тәртибе.
Эреп түгелер җиргә (һәрнәрсә) көмеш кебек,
Булыр таулар һавада гүя йон кебек…

Сыйфаты сират

Җәһәннәм өстендә бер хәбәре мәхдүд,
Сират атлыйг кылычдан тиз вә мәхдүд.
Гөзәргяһдер кичәрләр ул сиратдин,
Үтәр бәгъзы кеше тиз йүгрүк атдин.
Үтә бәгъзы кеше яшьнәр яшендик,
Үтәр бәгъзы кеше күзне йумандик.
Исәр йилдик үтәр бәгъзы кешеләр,
Үтәр бәгъзы мәшәкъкатьлә имәкләр.
Таярлар әксәре әүвәл кадәмдин,
Тотар каршы зәбанилар дузәхдин.
Чыкар гауга-фөган анда бәшәрдин,
Үтәр кирәк улур ошбу гөзардин.
Екылган чук улур анда пиа-пи,

Җәһәннәм кагрыйдә улур анда җаи.
Кеше бу дөньяда чук тотса һирас,
Хәлас тапкай Кыямәтдә ушал кәс.

Тәрҗемәсе:

Сират күпересенең сыйфаты

Җәһәннәм өстендә бер үлчәү бар чикләнгән,
Сират исемле, кылычтан үткен һәм чикле.
Узгынчылар кичәрләр ул сираттан,
Үтәр кайбер кеше тизрәк йөгерек аттан.
Үтәр кайбер кеше яшьнәр яшен кебек,
Үтәр кайбер кеше күзен йомган көе.
Искән җил кебек үтәр кайбер кеше,
Үтәр кайсысы күп мәшәкатьләр белән.
Таярлар күбесе беренче адымнан ук,
Каршы алыр тәмугта (аларны) газап фәрештәләре.
Чыгар гауга, кычкырыш кешеләр арасында.
Үтәргә кирәк булыр бу үтәргә тиешле юлдан.
Егылганнар күп булыр анда бер-бер артлы,
Җәһәннәм чокырында булыр аларның урыны.
Кеше бу дөньяда күп куркып яшәсә,
Котылу табар Кыямәттә ул кеше.

Сыйфате әл-шәфәгати

Хода изени билән тыңла Кыямәт,
Кыйлурлар әнбийа чәндан шәфәгать.
Дәхи галимләр вә салихлар идәр,
Дәхи һәр кәс Ходаның изени йитәр.
Җәһәннәм кагрига лаек уланлар,
Зәлаләтдин гомри заигъ идәнләр.
Шәфәгать абинә тәшнә улурлар.
Рузи итсә, тәмам бәһрә алурлар,
Гөнаһы чук улан бәгъзы мөселман,
Дузәхнең йулига төшсә би-саман.
Шәфәгать итсә, аны кайтарурлар,
Биһишт йулига дахил әйләйүрләр.
Дузәхка төшдүк соңра үлмәисәр,
Шәфәгатьдин монафигъ килмәисәр.

Җәһәннәмдә һәзаран әһле гыйсьян,
Шәфәгатьдин табарлар җөмлә дәрман.
Шәфәгатьлә чыкарлар ул һаидин,
Биһишт сари китәр барча шаидин.
Вирүлүр җөмләсигә җаи андәк,
Вәләкин һәрберигә бу җиһандәк.

Илаһи, бәндәңә кыйлгыл гыйнаять,
Насиб әйлә ушал көндә шәфәгать.
Әгәрчә җөрем вә гыйсйан чук кыйлупмыз,
Өмид улкем сәни вахәд белепмез.
Чыкарсаң җанымызни тәнемездин,
Айурма сидкымызни җанымыздин.

Тәрҗемәсе:

Шәфәгать итүнең сыйфаты

Ходаның рөхсәте белән тыңла, Кыяматтә
Пәйгамбәрләр күп шәфкатьлек күрсәтерләр.
Һәм дә галимнәр һәм изгелек кылучылар шундый булыр,
Һәм дә һәр кешегә Ходаның рөхсәте җитәр.
Тәмуг чокырына лаек булганнар
Азгынлыктан гомерләрен бушка уздырырлар.
Шәфәгать суына сусаучы булырлар.
Ураза тотса, тулы файда алырлар.
Гөнаһы күп булган кайбер мөселман
Тәмуг юлына төшәр дини байлыксыз.
Рәхимлелек кылса, аны кайтарырлар,
Оҗмах юлына кертеп җибәрерләр.
Тәмугка төшкәннән соң инде булмас,
Шәфәгатьтән инде файда күрелмәс.

Җәһәннәмдә меңнәрчә җинаятьчеләр
Рәхимлелектән табарлар барлык көч-куәтне.
Рәхимлелек белән чыгарлар ул коедан (тәмугтан),
Оҗмахка таба китәрләр бары лаеклы рәвештә.
Бирелер һәммәсенә аннан урын,
Вәләкин һәрберсенә ул бер дөнья кебек булыр.
Илаһым, бәндәңә күрсәт ярдәмеңне,
Насиб ит ул көндә шәфкатеңне.
Әгәр гөнаһ-җинаять күп кылган булсак,
Сине бердәнбер коткаручы дип өметләнәбез.
Чыгарсаң җаныбызны тәнебездән,
Аерма тугрылыгыбызны җаныбыздан...

Текстны журналга филология фәннәре докторы
***Әнвәр Шәрипов** әзерләде.* ■

«Кайсыгызның кулы җылы?»

Авыр миңа, авыр... Ярый әле баш куярга,
тынып көч алырга халкымның җылы
йөрәге бар... Нишләр идем югыйсә?
Хәсән Туфан көндәлегеннән



Хәсән Туфан

Хәсән Туфан татар халкының бәгыре иде. Тормышын вак-вак хәрефләр белән яшел карага манып язды ул.

Безнең өчен сабырлык үрнәгенә әверелгән Туфанга күп еллар дәвамында дистәләгән шигырьләр багышланды.

Булачак шагыйрь Туфанга шигъри орлыклар Башкортстан туфрагында салынган. Аның шигърияте тугандаш башкорт халкына да бик якын иде. «Кайсыгызның кулы җылы?» шигыре башкорт телендә дә басылды.

Туфанга хатынының үлгәнлеген ишетү трибунал карарыннан да авыр була. Нәкъ бер ел элек амнистиягә эләксә дә, шагыйрьнең кайту юлы бикләнә, чөнки Себердәге рус авылы карантинга ябыла. Шуны искәртеп, мәгълүм шигырендә: «Юллар... озын иделәр», – дип яза ул. Шагыйрә Клара Булатова сүзләренә караганда, беренче вариантта – «Юллар... бикле иделәр». Аны сөекле хатынының алкалары һәм кабере генә каршылый...

...Вулканнарга керер идем,
Шундадыр ул... дисәләр, –

дип өзгәләнә шагыйрь.

Вулкан нинди куркыныч урын! Хатынын коткарыр өчен, Туфан шунда керергә дә әзер!

Шагыйрьнең – лирик геройның – саркып торган ярасы тән ярасы түгел, ә күңел ярасы. Шундый сырхаудан савыктыру өчен, аны аңлардай зат кирәк. Йөрәк дәвасы булырлык кеше очрый да кебек Туфан тормышында. Шагыйрь аны, патша кызы дәрәҗәсенә күтәреп, Тәнәкә дип атый. Илһамланып, аңа сөю хатлары, мәхәббәт шигырьләре яза. Клара Булатова да, байтак еллар үткәч, үз чиратында, очрашуларда, ачык дәресләрдә Туфан турында истәлек-хатирәләр сөйли. Мәхәббәт тарихын шигъри юлларга сала. «Җырлы чаклар кайтавазы» мәкаләсендә: *«Вакытында мин аны аңлый да, бәяли дә белмәгәнмен. Миндә, әдәби сәләте әле борынлап кына килгән бер авыл кызында, Хәсән абый беркем дә күрмәгән, күрергә, белергә теләмәгән әллә күпме шагыйранә сыйфатлар тапкан, аларны илаһилаштырган. Үзенең олы шагыйрьлегe белән зурайтып, үстереп, кристаллаштырып җырга салган да шигъри образ – Тәнәкәне тудырган... Эзләнеп, өзгәләнеп, карыша-тартыша, үз-үзе белән көрәшә-көрәшә... Шулай булмый мөмкин дә түгел иде ләса. Давылларны кичкән Туфан һәм бөтен байлыгы сабый чактан отып калган шигырьләр, җырлар, бәетләр тулы тузган башлы чандыр кыз. Ә арада – гомер белән гомер арасы»,* – дип яза ул.

Луиза Салиәскәрова

Язучы Рафаэль Мостафин «Изге җан» дигән мәкаләсендә болай дип бәян итә: «*Сөргеннән кайткач та Туфан сөекле хатынына тугрылыклы булып кала. Өйләнергә аны ничә кат үгетләп карыйлар – риза булмый. Үлгән хатыны истәлеге каршында үзен бурычлы дип саный: «Луиза бит үз каны белән минем тормышымны саклап, теге дөньяга бик иртә китеп барды... Ахирәт көнне яңадан очрашсак, нинди күзләр белән аның күзенә карармын? Юк, һәркемнең гомере дә бер генә, хатыны да бер генә булырга тиеш».*

Туфан, рус шагыйре Михаил Дудин сүзләре белән әйткәндә, уникаль күренеш булды. Аны фотографлар сурәткә төшерде, рәссамнардан Бакый Урманче, Рәшит Имашев, Мансур Рәхимов, язучы Марсель Галиев олуг шагыйрьнең портретын иҗат иттеләр. Ләкин Туфанның йөз чалымнары барысында да бер үк иде.

Нахакка җәберләнгән шагыйрь. Маңгаенда тоткынлык еллары салган тирән сырлар. Эчтән бертөрле үз-үзен тыю. Юксынулы, сагынулы караш…

Туфан безнең күңелләргә шундый булып кереп калды. Чөнки шигырь аша «Кайсыгызның кулы җылы?» дип эндәшкән Туфанга хатыны Луиза Салиәскәрова кебек тугры мәхәббәт белән җавап бирүче, аны алыштыручы беркем дә табылмый…

Рухия Ахунҗанова, *Татарстан язучылар берлеге әгъзасы,*
Шәйхи Маннур исемендәге премия лауреаты ■

Мөслим бабай варислары

Роза Хәбибуллина

Роза Хәбибуллина

Ике гасыр арасы

Галим бабай белән Сәгыйдә әби балалары XIX гасыр азагында туып, XX гасырда яшәделәр: Гайшә, Газизә, Хөсәен, Хәким, Шакир, Сабир, Хафиз. Исемнәре җисемнәренә бәхет, гүзәллек, көч, акыл, гайрәт юрап торган мәгънәле. Болар минем әткәй Шакир Галимов һәм аның алты туганы.

Ахыры. Башы журналның 5 нче (2021) санында.

Гайшә – иң өлкән түтәйләре. Ул Атлас авылы кешесенә кияүгә чыккан, бик бәхетле булган: тормышлары ныклы, калай түбәле йортлары зур, иркен, атларны, мал-туарларны күп тотканнар. Утызынчы елларда аларны, кулак, дип, илнең ерак читенә – Иркутскига сөргәннәр. Черемхово дигән шахтерлар бистәсендә урнашканнар. Ватан сугышы башлангач, уллары Мәгъсумне – кулак баласын армиягә алмаганнар. Совет мәктәбендә укыган егет Калининга хат язган. Бөтенсоюз старостасы Калинин рөхсәт иткән. Мәгъсум сугышның азагына кадәр катнашып, орден-медальләр тагып кайткан. Соңыннан институт тәмамлап, Ерак Көнчыгышта геолог булып эшләгән.

Газизә апаларының гомере фаҗигале тәмамланган: егерме беренче елгы ачлык вакытында авырып үлгән. Ике улы да бер-бер артлы дөнья куйганнар.

Иң өлкән Хөсәен абыйны да күрергә насыйп булмады. Колхозда эшләгән ул. Бер ул һәм бер кыз үстергәннәр. Кызлары Рәшидә Галимова китапханәче булып эшләгән. Бүгенге көндә Рәшидә апаның оныклары, онықчыклары Мөслимдә, Түбән Камада яшиләр.

Хәким абый туганнар арасында корырак-катырак холыклы, сүзендә торучан, сер бирмәс, хәкимнәргә хас горурлыгы белән аерылып торды. Әтисе Галим карт сыйфатлары тышкы кыяфәтендә дә чагыла иде: таза, ныклы гәүдәле, киң күкрәкле, көчле ир, кече яшьтән авыр эшләрне җигелеп тартты: колхозда, пожарныйда эшләде, почтада атлар карады. Ул да, Галим карт кебек, атлар ярата иде. Рәйханә апа белән дүрт кыз һәм бер ул үстерделәр. Хәким абый картайгач та матур, төз, шат күңелле, тормыш сөючән, эшчән карт булды.

Бер мәҗлестә Хәким абыйның: «Галимнекеләр хатын аермыйлар!» – дигәне исемдә. Галимнекеләргә әллә гел уңган-булган киленнәр генә килгәнме, абыйлар барысы да хатыннарына искиткеч итагатьле, гомумән, хатын-кызларга илтифатлы иделәр. Бу, һичшиксез, аларның тәрбияле, эчке культуралары югары булудан.

Нәселнең беренче укымышлысы

Әткәм Шакир Галимов 1918 елдан укытучы булып эшли башлаган. Беренче бөтендөнья, аннан соң Гражданнар сугышында катнашып, каты яраланып кайткач, укыту эшен дәвам иткән. Мөслимдә, Метрәйдә, Муханда укыткан. 1926 елда партияга кергән. Колхозлар оеша башлагач, аны Мөслимнең яңа оешкан «Путиловец» колхозына беренче рәис итеп сайлыйлар. Ул әлеге вазыйфада озак эшләми, Казанга партия җитәкчеләре әзерләү курсында укып кайтып, «Путиловец» колхозында парторг була. 1932 елны Шакир Галимовны Әмәкәй авылындагы тулы булмаган урта мәктәп директоры итеп билгелиләр. Аннан соң Исәнсеф авылына директор итеп күчерәләр. 1937 елны ул да репрессиягә эләккән, «халык дошманы» дигән ярлык белән эштән чыгарылып, ярты ел тикшергәч, бәхетенә, мәрхәмәтле кеше – Минзәләнең райком секретаре (кызганыч, фамилиясен онытканмын): «Нишләп Галимов халык дошманы булсын, Ленин чакыруы буенча партиягә кергән, иң ышанычлы, намуслы коммунист!» – дип яклап калган. Ни кызганыч, ул кеше үзе дә соңрак репрессиягә эләккән…

Сугыш елларында әткәйне, Минзәлә районының Бикбау җидееллык мәктәбендә тарих укыткан җирдән, Калморза авылына – «Кызыл яр» колхозына рәис итеп билгеләделәр. Иң артта калган, дәүләт планын үтәмәгән, колхозчыларга бер грамм да ипи өләшмәгән, фуражга түгел, чәчәргә дә орлык

җитмәгән, атлары күтәрәмгә калган, эшне тартырлык ирләре сугышка китеп беткән колхозны аякка бастырачагына ышанып тапшырганнар. Ул еллар гомеренең иң авыр, иң җаваплы – батырлык еллары булгандыр!

Калморза халкы аны намуслы, мәрхәмәтле булганы өчен ихтирам итте, ышанды. Ышанычтан да көчле аргумент юк!

Әткәемнең үзен аямыйча эшләве, икмәк өчен көрәштә колхозчыларны оештырып, зур уңышларга ирешүе нәтиҗәсендә, «Кызыл яр» колхозы дәүләт планын ел саен 150 процентка үти башлады, колхозчыларның тормышы да җиңеләя төште. Ул районда гына түгел, республикада да алдынгылар рәтендә булды.

Шакир Галимов хатыны Газизә белән Әмәкәй мәктәбендә эшләгәндә. 1930 нчы еллар

Халкыбыз явыз дошманны җиңеп, илебезне, Европаны фашистлардан азат итеп, Рейхстагка Җиңү байрагы элгән икән, монда әткәйнең һәм Калморза халкының да зур өлеше бар! 1945 елда СССР Верховный Советы Президиумы Шакир Галимовны «Почет билгесе» ордены белән бүләкләде. 1946 елда ул «За доблестный труд в Великой Отечественной войне 1941-1945 гг.» медаленә лаек булды.

1950 елны без гаиләбез белән туган авылыбыз Мөслимгә кайттык.

Әткәй бик тыйнак, намуслы, илебезгә, халкыбызга бирелгән чын коммунист иде. Мөслим бабабызның ихтирамга лаек, тарихта якты эз калдырган дәвамчысы булды. Ул нәселебездә беренче интеллигент, зыялы, укымышлы кеше иде. Яшь чагында туганнарының балалары аны «Шәкерт абый» дип йөрткәннәр.

Сабир абый

Сабир абый да Олы Чакмак мәдрәсәсендә укыган. Совет властена белемле кешеләр кирәк булган, шуның өчен Сабир абый җитәкче эшләрдә эшләгән: Мөслимдә Авыл Советы рәисе, Заготконтора директоры, Заготскот директоры вазыйфаларын башкарган. Туганнар арасында аңа, шаярып, «академик» дигән исем тактылар: бергә җыелган чакларда үзе кызыксынган темаларга фән-техника яңалыклары турында сөйләшергә ярата иде ул.

Сабир абый Гайшәбикә апа белән өч кыз һәм бер ул тәрбияләп үстерде, аларга югары белем бирде. Галим картның уллары озын гомерле булдылар: сүз куешкан кебек, 82 яшьне тутырдылар.

Хафиз абый

Хафиз абый – төпчек малай, гомер буе бабайлар нигезендә – төп йортта яшәде. Ул озак еллар буе «Путиловец» колхозында бригадир булып эшләде. Ленинградның «Путилов» заводы эшчеләре трактор җибәргән булган, шуңа күрә колхозга шул исемне биргәннәр. Төп нигездә яшәгән киң күңелле Хафиз абый белән Зөһирә апа бик кунакчыл, бар туганнарга сыену урыны, «почта тартмасы» булдылар.

Колхоз бригадиры көн саен колхозчыларга эшкә әйтеп йөргәндә, бер тыкрыкта котырып этләр өрә икән. Хафиз абый, ачуы килеп: «Тыкрык мени бу! Эт тыкрыгы!» – дигән. Ул вакытта Ык аръягындагы әрәмәдән бик еш бүреләр чыгып, малларга зыян салганнар, шуңа халык эт асраган, мылтык тотучылар да булган. Хафиз абыйның сүзе «Эт тыкрыгы» булып ябышып калган.

Хафиз абыйның улы Рафак 38 яшендә вафат булгач, алар оныклары Ирекне карап үстерделәр. Ирек гаиләсе белән Чаллыда яши.

Безнең буын

Егерменче гасырда яшәгән Мөслим бабайның дәвамчылары – Галим картның җиде баласының балалары – туганнан туганнар бик күп идек. Бар гомерен Мөслим җирлегендә яшәп, туган җиренә, халкына хезмәт итте туганнарым.

Без Минзәлә районыннан Мөслимгә кайтканда миңа унбиш яшь иде. Район үзәгендә әткәйнең Хәким абыйсы, энеләре Сабир һәм Хафиз абыйлар гаиләләре белән яшәделәр. Сабир абыйның улы Энгель минем белән бер яшьтә, Хафиз абыйның улы Рафак ике яшькә генә өлкәнрәк иде.

Мөслим урта мәктәбендә укыдык, ике туганымны да армиягә озаттым, хатлар, фотолар алыштык, соңрак барыбыз да Мөслимгә кайтып төпләндек. Хафиз абыйның улы Рафак бухгалтер булып урнашты. Ул бик мәрхәмәтле, тырыш, туган җанлы, баһадирдай егет иде. Армияда флотта хезмәт итеп кайткач, өйләнеп, институтны читтән торып тәмамлады ул.

Мин Мөслим урта мәктәбендә рус теле һәм әдәбияты укыттым. Сабир абыйның улы Энгель, Сәмәркандта хезмәт итеп, шунда ук институт тәмамлап, агроном булып кайтты. Хәким абыйның улы Өлфәт белән ул өйләнеп, шахтадан кайткач таныштык, дуслаштык. Өлфәт тә миннән ике яшькә генә өлкәнрәк. Бик бәхетле идек. Барыбыз да эшләгән урыннарыбызда тырышып, «дилбегә кактырмыйча» хезмәт иттек, заманабыз өчен кирәкле кешеләр булдык. Ни кызганыч, бердәнбер сөекле улы Ирекне калдырып, Хафиз абый белән Зөһирә апаны, бар туганнарны кайгыга салып, Рафак 38 яшендә һәлак булды… Урыны җәннәттә булсын.

Җир улы

Энгель Сабир улы Галимов (1934-2013) районда гына түгел, республикада да танылган, данлыклы шәхес иде.

Әле дә күз алдымда: институт тәмамлап, диплом алып кайтканда, ул озын, төз гәүдәле, киң күкрәкле, борынгы грек вазаларындагы атлетлар кебек таза, көчле спортчы иде. Энгель спортның күп төрләре белән шөгыльләнде: ул гимнаст та, көрәшче дә, штангачы да, альпинист та булды. Институт тәмамлагач, Каракалпак Республикасының башкаласы Нукуста агроном булып эшләде. 1965 елда туган авылыбызга кайтты. Менә шул елдан аның авыр, ләкин шатлыкларга, җиңүләргә бай тормышы Мөслим халкының күз алдында узды. Энгель Галимовны районның иң зур хуҗалыгы булган Киров исемендәге колхозга баш агроном итеп билгеләделәр. 1977 елда ул әлеге колхозга рәис итеп сайланды. Энгель Галимов җитәкчелек иткән елларда хуҗалыкта игенчелек һәм терлекчелек тармаклары күтәрелеш алды, авыл хуҗалыгы культуралары игүнең прогрессив технологияләре кертелде.

Энгель Галимов эшләгән чорда колхозда искиткеч зур төзелеш эшләре башкарылды: Катмыш бригадасында мөгезле эре терлекләр өчен моңа кадәр күрелмәгән зур комплекс, Вәрәшбаш бригадасында сарыкчылык комплексы, колхозчылар өчен торак йортлар, авылларда мәдәният йортлары төзелде. Басулар мул уңыш белән сөендерде. Ул гектардан 40 центнерга кадәр җитте. Шушы уңышлар өчен Киров колхозы СССР Халык казанышлары күргәзмәсенең беренче дәрәҗә дипломына лаек булды. Аңа ТАССР Министрлар Кабинетының Мактау грамоталары, КПСС Үзәк комитеты һәм ВЦСПСның Күчмә Кызыл байрагы тапшырылып, ул хуҗалыкта бөтенләйгә калдырылды. Энгель Галимовның авыл хуҗалыгы өлкәсендәге фидакяр хезмәте лаеклы бәяләнде. Ул Почет билгесе ордены, В.И.Ленинның 100 еллык юбилеена «Фидакяр хезмәт өчен» медале белән бүләкләнде. 1975 елда аңа «Татарстанның атказанган агрономы» дигән мактаулы исем бирелде. Аңа СССР Халык казанышлары күргәзмәсенең бронза (1967), көмеш (1969) медальләре тапшырылды. ТАССР Югары Советы Президиумының һәм ТР Президентының мактау Грамоталары, «Хезмәт ветераны» медале белән бүләкләнде. Энгель Галимов «Мөслим муниципаль районының мактаулы гражданины» дигән мактаулы исемне горур йөртте.

Энгель Сабир улы замананың батыр улы, Мөслим ыруының данлыклы дәвамчысы булды. Без, туганнар, аның белән горурланып яшәдек.

Әнвәрә апа

Мөслим урта мәктәбендә миңа якын туганнарым белән бергә эшләргә насыйп булды. Әнвәрә Хәким кызы Галимова югары белемле, үзенә дә, укучыларга да таләпчән, гадел педагог иде. Ул математика укытты. Әнвәрә апа нәкъ шул фән өчен яратылган кебек – төгәл, җыйнак, зирәк фикерле, гаҗәп акыллы зат, сердәшем дә булды. Холкы корырак тоелса да, эчке кичерешләре искиткеч тирән, күңеле нечкә, кешеләр (укучылар) психологиясен бөтен нечкәлекләре белән аңлый торган укытучы иде ул.

Күп балалы гаиләдә үскән Әнвәрә апаның балачагы, яшьлеге сугыш елларына туры килде, тормыш йөген бик иртә, өлкәннәр белән бергә тартты. Мәктәптә укыган елларда каникул вакытларында колхозда эшләде, югары класста укыганда җәй көне бригадир булды.

...Канкойгыч сугыш барган көннәрдә Мөслимдә септик ангинадан йөзләгән кешеләр кан косып үлә башлый. Кешеләр кар астында калган бодайны җыеп ашап агуланалар. Больницада авыруларга урын, табиблар, шәфкать туташлары, санитаркалар җитми.

10 нчы класснның алты кызы больница хезмәткәрләренә ярдәмгә килә. Алар арасында Әнвәрә дә була. Чыгарылыш сынаулары алдыннан кызлар ай буе авыруларны карыйлар, ашаталар, юындыралар, бар эшләрне дә сыкранусыз башкаралар. Унсигез яшьлек Әнвәрәнең күзеннән яшь кипми, кечкенә балалар үлсә, үзәге өзелә: аның үзенең ике сеңлесе шул авырудан вафат була Авыру әкренләп чигенә. Имтиханнар җиткәч, кызлар мәктәпкә кайталар. Шул фаҗигале көннәрдә алар өлгергәнлек аттестаты алалар.

Сынаулар вакытында класс җитәкчесе Нурдидә Галиева болай дип киңәш бирә: «Әнвәрә, укуыңны дәвам ит, сине Зәки Ханнанович бик мактый, аннан яхшы математика укытучысы чыгачак, ди».

Көннәрдән бер көнне Олы Чакмак мәктәбенең алтынчы сыйныфына зифа гәүдәсенә килешеп торган ак якалы зәңгәрсу-кара күлмәк кигән, коңгырт чәче турыдан ачылган, калын толымнары билдән түбән төшкән гаять җитди карашлы яшь кенә кыз керә дә: «Укучылар, мин сезгә математика укытачакмын», – ди. Шул сәгатьтән алып Әнвәрә Хәким кызы Галимова гомер буе сайлаган хезмәтенә тугры булып, балаларны яратып, укытучы исемен горур йөртә. Хезмәтен югары бәяләп, аңа «Халык мәгарифе отличнигы» дигән мактаулы исем бирелә, ул күп санлы Мактау грамоталары, «Хезмәт ветераны» дигән медаль белән бүләкләнә.

Әнвәрә апаны да, Энгельне дә ямансулап искә алам, ни кызганыч, алар инде бакыйлыкка күчтеләр, урыннары җәннәттә булсын. Аларны Мөслим халкы да юксына.

Үрәтник Хафиз оныгы

Галим бабайның абыйсы үрәтник Хафиз Ибраһимовның нәсел дәвамчысы – миңа өченче буын кардәшем Илгиз Гариф улы Закиров та, Әнвәрә апа кебек, Мөслим урта мәктәбендә математика укытты. Күпкә яшьрәк булса да, аның белән дә байтак еллар бергә эшләдек. Ул килеп эшли башлагач та:

– Илгиз Гарипович, безнең бабаларыбыз бертуган, Сез минем энем буласыз! – дидем.

– Рәхмәт, Роза Шакировна, беләм, беләм, рәхмәт! – дип елмайды ул.

Туганлык хисләре өстенлек алгангамы, мин аның чын ирләргә хас тәрбиялелегенә, зыялылыгына, тотнаклылыгына, сабырлыгына, кирәк вакытта таләпчәнлегенә соклана, куана идем.

Шундый ирләр укытканда, коллективта тынычлык, оешканлык, бердәмлек була.

Илгиз Гарипович озак еллар мәктәптә завуч вазыйфасын башкарды, аны укучылар да, коллегалары да ихтирам итте. Югары гражданлык, җаваплылык хисе тоеп укыткан педагогның хезмәтен хөрмәтләп, аңа «РСФСРның халык мәгарифе отличнигы» дигән исем бирелде. Ул район мәгариф бүлеге, Республика Мәгариф министрлыгы Мактау грамоталары белән күп мәртәбәләр бүләкләнде. Тәҗрибәле мөгаллим югары дәрәҗәгә – «СССРның халык мәгарифе отличнигы» дигән исемгә лаек булды. Шулай да укытучы өчен иң югары бүләк – укучыларның һәм аларның әти-әниләренең, халыкның хөрмәте-ихтирамы һәм рәхмәте!

Илгиз Гарипович хәзерге көндә лаеклы ялда.

«Аксакал»

Безнең буыннан Мөслим ыруының ике «аксакалы» – Хәкимов Өлфәт Хәким улы һәм мин – Роза Шакир кызы Хәбибуллина Мөслимдә яшәп ятабыз. Икебез дә олыгайдык: Өлфәт – 89да, мин – 86 яшьтә. Өлфәт гомер буе МСОда шофер булып эшләде, хатыны белән баһадирдай өч ул һәм бер кыз үстерделәр. Галим нәселенең ныклыгын алган Өлфәт әле һаман машинада рульдә йөри иде, короновирустан да җиңел генә савыкты. Гомер буе бер урында хезмәт кую кешенең тәртипле, тырыш, намуслы булуы турында сөйли. Ул коллективта ихтирам казанды, зур бүләкләргә лаек булды. Сугыш вакытында ун яшеннән колхозда эшли башлаган туганым юбилей медальләре, «Ветеран труда» медале белән бүләкләнде. Хәзерге көндә дә эшләгән оешмасы белән арасын өзми: МСО коллективы – яшьләр ветеран абыйларын зур хөрмәт белән бәйрәмнәргә чакыралар, бүләклиләр.

Үзем турында

Әйткәнемчә, мин дә Мөслим бабай варисларының Мөслимдә яшәүче өлкәннәренең берсе булам. Алабугада институт тәмамлагач, Мөслим урта мәктәбендә рус теле һәм әдәбияты укыта башладым. Һөнәремне, укучы балаларны яратып, тырышып эшләдем. Яңадан яшьлегемә кайтсам, тагын укытучы булыр идем. Укытучы – иң изге хезмәт иясе, чөнки укучыларга, эшеңә сарыф иткән көч, энергия, уй-хыялларың балаларның ихтирамы, мәхәббәте, бәхет булып кайта! Хезмәтемне күреп, югары бәяләп, «РСФСРның халык мәгарифе отличнигы» дигән мактаулы исем бирделәр. Татарстан Мәгариф, СССР Мәгариф министрлыкларының, СССР Фәннәр Академиясенең, Татарстан Комсомол обкомының, район мәгариф бүлегенең Мактау грамоталары белән бүләкләндем. «Укытучы-методист» дигән югары исемгә лаек булдым, «Хезмәт ветераны» һәм юбилей медальләре белән бүләкләндем.

Пенсиягә чыккач, минем белән хикмәтле үзгәреш, бөтенләй башка тормыш башланды. Биш ел район хастаханәсенең әдәби-фәнни китапханәсендә китапханәче булып эшләдем. Менә шул вакытта яза башладым. Язган әсәрләрем киштәдә бик озак ятканнан соң, бар кыюлыгымны җыеп, кульязмаларымны Тукай премиясе лауреаты язучы Фоат Садриевка бирдем. Укып чыккач, ул әсәрләремне «Казан утлары» журналына илтеп тапшырды. 2003 елда «Яшьлегем серләре» дигән беренче повестем басылып чыкты. Бу минем өчен искиткеч зур шатлык булды! 2004 елда икенче повестем – «Миләш елы» «Казан утлары» журналында дөнья күрде. Журналның баш мөхәррир урынбасары, якташ әдибебез Флүс Латыйфи әсәрләремә югары бәя бирде:

– Роза апа, әсәрләрегездә күтәрелгән проблемалар яшьләр өчен бик мөһим! – диде һәм, елмаеп: – Әсәрләрегезнең теле матур, мамык кебек йомшак, – дип өстәде.

Мәрхүм Флүс Латыйп улының рухы шат, урыны җәннәт түрендә булсын!

Шулай итеп, якташларыбыз Флүс Латыйфи һәм Фоат Садриев әсәрләремә юл ачты. Аларга рәхмәтемнең чиге юк! Фоат Садриев әсәрләремнең тәнкыйтьчесе һәм мөхәррире булды, киңәшләр бирде.

Уңышлар канатландырды, илһамландырды, дәртләнеп, бик тыгыз эшләдем, әсәрләрем дөнья күрә торды «Медицина» нәшриятында «Калморза», «Яшьле-

гем серләре», «Верность долгу» дигән китапларым басылып чыкты, соңгысы Мөслим районы медицинасы тарихы булып, мәрхүм ирем Ильяс Габдулла улы Хәбибуллин белән берлектә язылды.

2011 елда Татарстан китап нәшрияты «Миләш елы» исемле китабымны чыгарды. 2013 елда мине, 79 яшем туларга берничә ай кала, Татарстан Язучылар берлегенә кабул иттеләр. Бу көн дә минем иң бәхетле көннәремнең берсе булды. «Безнең мирас», «Казан утлары» һәм «Мәйдан» журналларында, «Рухият» нәшрияты чыгарган җыентыкларда повестьларым, очеркларым, хикәяләрем чыгып торды, барысын да санап тормыйм. Сигез китабым дөнья күрде. Шулардан «Мулла килене» дигән китабым, 2015 елдагы конкурста җиңеп, «Ел китабы» дип игълан ителде һәм Беренче дәрәҗәдәге диплом, премия белән бүләкләнде.

2014 елда татар әдәбиятын үстерүгә керткән хезмәтем өчен Татарстан Мәдәният министрлыгының Мактау Грамотасы, Саҗидә Сөләйманова исемендәге әдәби премия тапшырылды. 2018 елда «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән югары исем һәм медаль алдым.

Олы яшьтә булсам да, әле һаман эшлим. 2019 елда «Мәйдан» журналында ике повестем басылып чыкты. 2020 елда «Рухият» нәшриятында «Сиңа дигән җырым» исемле китабым дөнья күрде.

Раббыбыз биргән гомеремне, хезмәтемне, әсәрләремне халкыма багышлап яшәү бәхетенә шөкер итәм!

Үзең турында язу кыен булса да, башкарган эшләремне санап киттем инде, укучыларым гаеп итмәсен!.. Язганнарым киләчәк буыннарга ядкяр булып калсын иде...

***

Безнең шәҗәрә Муса бабайдан башлана: Муса – Мөслим – Абдий – Габделваһап – Габделгази – Ибраһим – Мөхәммәтгалим – Шакир. Шәҗәрәбездә мин тугызынчы буын. Оныкчыкларым уникенче буын хасил итә. 2019 елда Мөслим бабайның тууына 350 ел тулды. Авылыбыз нигезләнүгә якынча 315 ел. Мөслимнең нәсел дәвамчылары районыбызның һәр авылында да бар! Бик күп авыллардан, мәсәлән, Шураннан, Симәктән, Торыштан, Чакмактан безнең чибәр кызларыбызны никах укытып алып киткәннәр.

Авырулар килә дә китә, ямьле җәй көннәренең берсендә Кояшлы Ык аланнарында меңәрләгән халык шаулап-гөрләп юбилейны бәйрәм итәр, иншәАллаһ!

Без – мөслимнәр

Авылыбызның бүгенге тарихын яңа яшь буын яза. Эшләре уң, максатлары изге булсын дип телик!

Мөслимебез елдан-ел матурлана, төзекләнә, ямьләнә бара. Татарстанда гына түгел, бөтен Россияда иң төзек, кешегә яшәргә иң уңайлы авыл дигән дәрәҗәле исем алдык. Бу – халкыбызның тырыш эшчәнлеге нәтиҗәсе. Алар арасында Мөслим бабайның варислары бик күп.

Бер шигем дә юк: районыбыз башлыгы Рамил Хәмзә улы Муллин да – Мөслим бабай варисы. Мөслим халкына тырышып хезмәт итүче, зур җиңүләргә ирешкән батыр егет!

ИншәАллаһ, киләчәгебез имин булыр! ■

Безнең мирас №6 июнь 2021

«Истәлек итеп сакларсың!»

Эльмира Сәлахова



Альта Мәхмүтова. 1957 ел

Соңгы вакытта бик күп гыйлем ияләрен югалта башладык. Алар белән гыйльми хәзинәбезнең бер өлеше китеп бара сыман. 2021 елның 10 апрель иртәсендә энциклопедик галимәбез Альта Хаҗи кызы Мәхмүтова бакый дөньяга күчте. Туган авылы Менделеев районындагы (ул вакытта Алабуга районы) Бәзәкә авылыннан укырга дип 11 яшендә чыгып киткән остазыбыз мәңгелек йортын да туган туфрагында тапты.

Альта Хаҗиевна сугыш чоры баласы, авыр тормыш юлын үткән көрәшче, горур, көләч йөзле, мөлаем, затлы, зыялы ханым иде.

Әтисе Хаҗиәхмәт ага сугыштан авыр яралары белән ярым тере хәлдә авылга кайтып егыла. Әмма аның әсирлектә булганын бик озак вакытлар онытмыйлар. Бары тик 1956 елдан соң гына аклана ул. Хаҗиәхмәт аганың тормышы җиңел

булмый, шулай да һәр баласына ныклы терәк әзерли, аларны укыта. Авылда башлангыч мәктәпне генә бетергән кызчыкны, урыс телен дә белсен, гыйлем алсын, дип, 1948 елда Бондюгның беренче мәктәбенә укырга бирәләр. Сыйныфта урысча юньләп сөйләшә алмаган бердәнбер татар баласы була ул. Чит мохиткә килеп кергән сабый гына диярлек татар кызына авыр була. Әмма Альта Хаҗиевна бирешә торганнардан түгел. Өч ел Бондюг мәктәбендә белем алып, классикларның әсәрләрен укып, урыс телен урысларның үзләреннән дә камилрәк өйрәнә ул. Аның, туган телен яхшы белгән кебек, урысча да искитмәле матур итеп сөйләшүенә, ике телдә дә камил итеп лекцияләр укуына соклана идек. Галимәнең китаплары урыс телендә булсынмы, татар телендә булсынмы – матур әдәби тел белән язылган, алар бер сулышта укыла. Әйе, сүз тәмен белеп иҗат итә, фәнни эшчәнлек алып бара торган талантлы тарихчы иде ул.

Белем алу чорына әйләнеп кайтыйк. Альта Хаҗиевна укуын Алабуга педагогия училищесында дәвам итәргә дигән карар кабул итә. Туган авылыннан 35 чакрым ераклыктагы Алабугадан туган нигезгә кайтып йөрү тагын да кыенлаша. Галимә үз истәлекләрендә бу вакытларны авылдан ераклаштырган еллар итеп искә ала. 1955 елда башлангыч сыйныф укытучысы дигән таныклык алып чыккач, әнисе белән әтисе югары белем алырга кирәклеген әйтеп караса да, кыз бала: «Башта мәктәптә эшләп карыйсым килә», – дип, үз сүзен кистереп әйтә. Шулай итеп, Альта Хаҗиевна чак кына Урта Азия якларына укытучы булып китми кала, язмыш юллары аны башкалабыз Казанга илтә. 1955 елның 15 августыннан башлап, 10 ел дәвамында, Казан мәктәпләрендә башлангыч сыйныф балаларын укыта ул. Гомеренең соңгы елларына кадәр беренче укучыларын искә ала, аларны сагынып сөйли иде Альта Хаҗиевна.

Альта Мәхмүтова. Алабугадан туган авылы Бәзәкәгә кайткач. 1951 ел

Әтисе Хаҗиәхмәт

1965 елда читтән торып Казан университетының тарих-филология факультын тәмамлый, СССР тарихы кафедрасы аспирантурасына укырга керә. 1967 елдан башлап гомеренең 40 елдан артык өлеше университетта мөгаллимлек хезмәте белән бәйле аның. 2010 елда укытудан туктаса да, фәнни эштән һич кенә дә читләшмәде Альта Хаҗиевна. Киресенчә, аның эшчәнлеге соңгы ун елда тагын да алга китеп, югарырак баскычка күтәрелде, бер-бер артлы китаплары, фәнни мәкаләләре басылып чыкты, дисәк, һич хата булмас.

Укытучы

Альта Хаҗиевна зур галим булып җитешкәч тә талантлы укытучы булып калды. Бу очракта ул дәресне аңлатучы гына түгел, ә студентларының тормышында төп урынны тотучы шәхес тә иде. Университетта Татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләре факультеты оешкач, беренче студентларның әнисе дә булды ул. Тәүге елгы студентлар аны хәзер дә әни дип йөриләр. Факультет деканы Тәлгать Галиуллин, урынбасары Альта Хаҗиевнаны студентлар белән таныштырганда, «әниегез» дип тәкъдим итә иде. Дөрестән дә, сирень төсендәге йомшак кофта кигән, гел елмаеп торучы мөлаем ханым туган җиреннән аерылып, беренче тапкыр шәһәргә килгән балалар өчен Казандагы әниләре булды. Галимә студентларның укулары өчен генә борчылып калмады, яшәү шартларыннан да хәбәрдар булды, кирәк чагында ярдәм дә итте. Кайбер студентларны саклап-яклап та калды ул. Җитәкчеләр дә аның сүзен тыңлый иде.

Студентларының бик күбесе Альта Хаҗиевнаның якын кешесенә әйләнеп китте, университетны тәмамлагач та аралашып яшәделәр. Минем тормышымда да Альта Хаҗиевнаның роле гаять зур. Беренче курс алдыннан, студентларны җыеп, белгечлек буенча төркемнәргә бүлә башладылар. Укырга «тарих» бүлегенә килсәм дә, татар теле, әдәбияты белән тарихны бергә укыта торган бүлектән куркып, ике юнәлештә дә уку бик авыр булыр дип уйладым. Шулай итеп, гаризамны тел-әдәбият төркеменә яздым. Сентябрь алдыннан, бу хатамны төзәтим дип, әни белән янә деканатка килдек. Килүемнең сәбәбен аңлаткач, декан урынбасары Альта Хаҗиевна елмайды да: «Сине болай да тарих төркеменә яздым инде!» – диде. Беренче тапкыр гына күргән авыл баласының теләген кайдан сизде икән ул?!

5 нче курсны тәмамлаганда, студентларны эшкә билгеләүче комиссия төзелде. Анда, әлбәттә, Альта Хаҗиевна да утыра. Без инде барыбыз да: «Кайларга җибәрерләр икән?» – дип борчылабыз. Мин дә туган җиремнән яки Казаннан еракка китүне күз алдына да китерә алмыйм. Комиссия каршысына кереп утыргач, Альта Хаҗиевна: «Ул аспирантурада кала!» – дип әйтмәсенме! Алга таба укуны, гомумән, планлаштырмаган идем, бу хакта бернинди сөйләшү дә булмады. Шулай итеп, укытучым минем язмышны яңа бер юлга борып җибәрде.

Нәтиҗәдә, миңа Альта Хаҗиевна белән коллега булу бәхете язды. Инде мәрхүм булган мөхтәрәм остазлар – Миркасыйм ага Госманов, Альта Мәхмүтова, Җәүдәт абый Миңнуллиннар белән аралашу, алар белән татар халкы тарихы кафедрасында эшләү үзе бер зур мәктәп иде, күңелдә матур хатирә булып калды.

Курс, диплом эшләре темаларын бүлгәндә Альта Хаҗиевнага студентлар ябырылып килә иде. Ул җитәкчең булды исә, эшләтә дә, таләп тә итә, шул ук вакытта чыганаклар табарга юнәлеш тә бирә, бик тәфсилләп аңлата һәм хәтта хәреф, өтер хаталарын калдырмыйча укып, тикшереп тә чыга иде. Темалары да бик кызыклы: уку-укыту, мәгариф тарихы белән бәйле булыр иде. Соңгы елларда студентлары-

КДУның татар халкы тарихы кафедрасы галимнәре. 1998 ел

на авыл тарихлары белән бәйле курс һәм диплом эшләре бирә башлады. Дөрес, үз аспирантлары булмады. Әмма кафедрадагы һәр аспирант, хәтта чит илдән килгәннәре дә аның ярдәмен тоеп яшәде. Гомумән, татар халкы тарихы кафедрасы бербөтен тату гаилә булды. Аның «атасы» – Миркасыйм ага түрдә утырса, янәшәдә «анасы»– Альта ханым булыр иде.

Гыйльми эшчәнлеге

Альта Хаҗиевна дүрт яшеннән капитан булырга хыяллана, ләкин 1944 елда кабул ителгән яңа уставка «кызларны капитанлыкка укырга алмаска» дигән пункт кертелә. Әнисе аңа бу документны күрсәткәч: «Алайса мин синең кебек укытучы булам», – дип, хыялын үзгәртә кыз бала. Аның укытучы булу хыялы да, капитан булу хыялы да тормышка ашты, дисәк, ялгыш булмас. Дулкынлы, давыллы диңгезләрдә йөзмәсә дә, гыйлем дәрьясына чумды, тарихи чыганакларны ерып барган капитан булды ул.

Альта Хаҗиевнаның кандидатлык диссертациясе темасы үз заманы өчен бик кыю яңгырый: «Борьба за женское образование у татар (90-е гг. XIX в.-1917 г.)». Татар чыганакларын кулланып язылган әлеге хезмәт милли мәгарифебезнең бөеклеген күрсәтә. Ул заманда әлеге проблеманы болай кыю итеп актырта алу зур батырлык иде. Яшь кенә кызның мондый җитезлеге, кыюлыгы, әлбәттә, күпләргә ошамый. Диссертацияне яклаганда зур каршылыклар булганын без соңгы елларда гына белдек.

Альта Хаҗиевна кебек шәхесне сындырып буламы соң! Алга таба аның берсеннән-берсе яхшырак хезмәтләре дөнья күрә торды. 1982 елда кандидатлык диссертациясенә нигезләнеп язылган «Становление светского образования у татар (Борьба вокруг школьного вопроса. 1861-1917)» дигән китабы, кечкенә күләмле булса да, бу тема буенча язылган бар хезмәтләрдән дә камилрәк.

Хатын-кыз мәгарифе тарихын, татар халкының асыл туташ һәм ханымнарын барлап, алар турында язылган «Пора и нам зажечь зарю свободы!: джадидизм

и женское движение» исемле китабы 2006 елда дөнья күрде. Альта Хаҗиевна тарихның безгә билгеле булмаган сәхифәләрен җанландырды. Горурлык хисе, зур соклану белән укый торган хезмәт иҗат итте ул. Татар ханым һәм туташлары турындагы «Милләт аналары» исемле саллы җыентыгы «Шәхесләребез» сериясеннән басылып чыкты.

Альта Хаҗиевна галим һәм дин әһелләре Бубилар эшчәнлеген, мирасын өйрәнде, аларга багышлап күп санлы мәкаләләр язды. «Лишь тебе, народ, служенье! (История татарского просветительства в судьбах династии Нигматуллиных-Буби)» дигән хезмәте өчен галимә 2010 елда Ш.Мәрҗани исемендәге премиягә лаек булды.

Остазыбызның һәр мәкаләсе, доклады фәнни яңалык иде. Без аның белеменә һәм тәҗрибәсенә җитү турында хыялланган тарихчылар гына булсак та, ул һәрвакыт яшьләр белән санлашты, киңәшләште. Китапларын кульязма рәвешендә чагында ук коллегаларына биреп укытты һәм фикерләрен сорады. Миңа Альта Хаҗиевнаның соңгы елларда чыккан барлык китапларының да кульязмасын укырга насыйп булды. Бу минем өчен бик зур мәртәбә иде. Туган авылы тарихына багышланган «Бәзәкәм – гомер бишегем» китабын язганда да, без озаклап сөйләшә, киңәшә идек. Ул: «Авыл тарихына караган чыганакларны син миннән яхшырак беләсең бит!» – дип, мине үсендереп тә җибәрә иде. Әлеге китабына рецензия язуны да миңа ышанып тапшырды. Яше олы булса да, архивларга йөрде, табылган һәр материалга балаларча сөенде. Олыгайган көнендә җанга рәхәтлек бирә торган туган җир, туган туфрак темасы белән шөгыльләнү аңа яшәү дәрте өстәде. Альта Хаҗиевна әлеге хезмәтенең гомер юлы йомгагы булачагын яхшы аңлады, шуны башкарып чыгар өчен Аллаһы Тәгаләдән көч-куәт сорады.

Остазыбыз туган авылына ел саен кайтты. Бу китабы белән ул, беренчедән, Бәзәкәне дөньяга танытса, икенчедән, авыл тарихын ничек язарга кирәклеген күрсәтеп, үрнәк хезмәт тудырды. Китапның татар телендәгесе тарихи вакыйгаларга хис-кичерешләр кушып язылган булса, урыс телендәгесе фәнни итеп, бай чыганакларга сылтамалар белән башкарылды. Берсе – бәзәкәлеләр өчен булса, икенчесе тарихчыларга, төбәкне өйрәнүчеләргә адресланды. Альта Хаҗиевна китапны язганда ук аны нинди укучы укыячагын алдан белде, укучысы телендә иҗат итте. Бәзәкә авылы кешеләре дә галимәне зурлады, яратты. Китабын укучыларга матур итеп тәкъдим иткәндә дә аның сөенече чиксез иде. Бәзәкә авылы тарихы үз укучыларына барып ирешкәч, Альта Хаҗиевнага «Бәзәкә авылының почетлы кешесе» дигән мактаулы исем дә бирделәр. Моның өчен ул аеруча сөенгән иде.

Күркәм кеше

Соңрак мин Альта Хаҗиевнаны мөгаллимә, коллега итеп түгел, ә гап-гади татар ханымы буларак белә башладым. Әйткәнемчә, 2010 елда ул университетта укытуын туктатты, мин дә шул елны киттем. Аңа студентлар белән аралашмау авыр булды. Әмма ул аптырамады, күп очрашуларга йөрде, чакырылган конференцияләрнең берсеннән дә калмады. Барлык көч-куәтен, энергиясен авыл тарихына багышланган китабына материаллар җыюга юнәлдерде. Университеттан киткәч, аның белән кафедрада күрешә алмагач, озаклап телефоннан сөйләшә идек. Без инде коллегалар түгел, ә төрле темаларга сөйләшә торган якын кешеләргә әйләндек. Бу вакытта аның характерын мин үзем өчен белмәгән яктан ача башладым. Ул – аның гадилеге иде. Гади, якын итеп сөйләшә, гаиләмдәге һәр кешенең хәлен

сорап чыга, аннан бер темадан икенчесенә күчә-күчә телефоннан сәгатьләр буе гәпләшә... Вакыт тыгызрак булып, хәбәрләшми торсам, үзе шалтыратып, яратып кына шелтәләп тә ала иде. Кайвакыт шалтырату белән ул сүз әйткәнче үк: «Беләм, беләм, Сез мине хәзер ачуланасыз», – дип сүз башласам, кеткелдәп көлеп куя. Балаларны бик ярата иде Альта Хаҗиевна. Кызым Гөлмәрьям турында сораша, ә Самир белән Кәрим (сеңлесе Әнисә апаның оныклары) хакында сөйли башласа, бәхетле әби була да куя. Ул, гомумән, туган җанлы иде. Олы туганнары Шәриф абый белән Наҗия апалар турында җылылык белән сөйләгәннәре истә калган. Сеңелләре Алисә һәм Әнисә апаларның гаиләсе өчен хөрмәтле апа булды ул.

Альта Хаҗиевнаның олы яшьтә, хәтта аяклары авырткан вакытта да җиңел, хәрәкәтчән кеше булуына шакката идем. Конференцияләргә бару аңа бер авырлык та тудырмады. 2019 ел ахырында, таягын юлдаш итеп алды да, Алабуга шәһәреннән үк Болгарга конференциягә килде, секция җитәкләде, чыгышы белән барысын да үзенә каратып торды. Искитмәле хәтерен ул соңгы вакытка кадәр җуймады. Бөтен нәрсәне, без яшьләр кызыгырлык дәрәҗәдә хәтерли иде, хәтта үз студентларының исемнәрен дә онытмады. Галимә катнашындагы соңгы чара 2020 елның 29 августында булды. Татар конгрессы җыенында Альта Хаҗиевна элекке студентлары, хезмәттәшләре белән күреште.

Ул һәр чарага тәфсилләп әзерләнер, доклад белән генә чикләнмичә, матур кием дә алыр иде. Альта Хаҗиевна үзе дә кул остасы – матур җепләрдән искитмәле баш киемнәре, кофталар бәйләп кияргә яратты. Кием табу авыр булган елларда аның үз кул җылысы белән теккән затлы-зәвыклы киемнәренә, мөгаен, күпләр кызыккандыр.

Альта Хаҗиевнаның мине сокландырган мөһим бер сыйфатына аерым тукталасым килә. Бу – аның киң күңеллеге һәм күңел чисталыгы. Белмим, галимнең дошманы булмагандыр. Булса да, тирәлегендә озак тора алмас иде. Мәгариф темасы белән гомер буе шөгыльләнгән Альта ханым әлеге мәсьәләдә үз фикерен әйткән берәүдән дә көнләшмәде, башкаларга киртә булмады. Киресенчә, халкыбыз тарихының байлыгын, аның киң кырлылыгын аңлап, бу юнәлештә эшләүчеләргә ярдәм күрсәтте ул. Әмма хезмәтен файдаланып та, аның исемен атамый гына язучылар булуына нык борчылды. Фәнни эштә кулланган һәр хезмәткә сылтама бирүнең мәҗбүри икәнен белгән Альта ханымга мондый гамәлләр аңлашылмый иде.

Галимә бервакытта да дан-шөһрәткә омтылмады. Аны тыйнаклыгы затлы итә иде. Соңгы вакытта дөньялар үзгәреп китсә дә, ул яңалыклардан артта калмады. 80 яшен тутыргач та интернетны кулланды, социаль челтәрләрне күзәтеп барды, компьютерда да оста итеп эшли белде. Әмма хәзерге техниканың берсе дә янәшә утырып сөйләшүне алыштыра алмый шул. Шәхесләребез исән вакытта яннарында күбрәк булырга, алар белән озаграк аралашып калырга кирәк икән! Бу язмам мәрхүмәнең якты истәлегенә бер ядкяр булсын.

***

Миндә Альта Хаҗиевнадан кадерле истәлек булып китаплары, аның кызым тугач үз куллары белән бәйләп бүләк иткән паласы һәм иңнәремә салып: «Истәлек итеп сакларсың!» – дигән шәле калды. ■

Каракош

Эльмира Шәрифуллина

Фазыл Туйкин

Казан дәүләт университетында укыганда (1968-1973) «Фазыл Туйкин иҗаты һәм эшчәнлеге» дигән диплом эшем Туйкиннарга карата туган ихтирамымны гомерем буена сакларга, алар турында очраган бар мәгълүматны җыеп барырга, алай гына да түгел, аларның искиткеч зур эшчәнлеге, ачы язмышы турында кайтып-кайтып уйланырга мәҗбүр итә. Бактың исә, мин алар белән Казанга килгәнче, университетка укырга кергәнче үк «таныша» башлаганмын икән. Ничекме?

1966 елда, Минзәлә педагогика училищесын тәмамлагач, Мамадыш шәһәрендә эшли башладым. Мәдәният йортындагы драмтүгәрәккә дә йөрим. Режиссерыбыз – баскан җирендә ут уйната торган, бик тә сөйкемле сөякле Фарсин абый. Үзешчәннәр белән «Соңгы каракош» спектаклен әзерлибез. Әсәр сәнәкчеләр күтәрелеше турында.

Үсмер чагымда үзебезнең җирлекне тетрәндергән сәнәкчеләр фаҗигасе хакындагы хәбәрне ишеткәнем бар иде. «Сәнәкләрен алга каратып тоткан бик күп ир-ат, Түке ягыннан килеп, безнең авылны йөгереп узып, Качкынга таба киттеләр. Зөбәердән дә кушылучылар байтак булган, – дип сөйли иде әнкәй. – Бунт оештыручы әйдаманнарны Качкын зиратына тезеп бастырып атканнар. Күп тә үтми, әлеге канлы мәхшәр булган җиргә, атын кара тиргә батырып: «Атмаска!» – дигән фәрман белән, чапкын килеп җиткән. Әмма эш узган булган...»

«Соңгы каракош»та да вакыйга бик киеренке. Авыл укытучыларын җәзалау, үтерү... Бер гаилә, бер ата, бер ана балалары арасында коточкыч шәфкатьсезлек... Адәм балаларының бер-берсенә ышанмавы гына түгел, аңларга да теләмәүләре. Аксакалларның сүзенә колак салмау гына түгел, аларны хурлыклы рәвештә түбәнсетү, рәнҗетү... Хәер, әсәрнең эчтәлеге шушы мәкаләләрдән шактый аңлашыла.

Соңгы каракош

Совет кешеләре Бөек Октябрьнең 50 еллыгын промышленностьта һәм авыл хуҗалыгында гына түгел, культура өлкәсендә дә зур уңышларга ирешеп каршылау теләге белән яшиләр. Данлыклы юбилей хөрмәтенә район Культура йорты үзешчәннәре дә сәхнәгә кую өчен «Соңгы каракош» спектаклен әзерләделәр.

Революция һәм аннан соңгы беренче елларда яшь Совет властена күп төрле дошманнарга каршы көрәшергә туры килде. Ак бандалар һәм аларның ялчылары татарлар арасында да фетнәләр оештырдылар. Крестьяннарның әлегә икеләнеп кемгә иярергә белмичә торучы өлешен сәнәк, балта, тәртә кебек әйберләр белән «коралландырып», революционерларга, коммунистларга каршы котырттылар. Ләкин революцион халык аларны яңадан баш күтәрә алмаслык итеп дөмектерде. «Соңгы каракош» спектаклендә әнә шул чордагы вакыйгалар тасвирлана. Билгеле, бу чорны күреп белмәгән, ул вакыттагы кораллар, кием-салым, кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләре белән таныш булмаган хәзерге яшьләр өчен катлаулы һәм җаваплы образлар тудыру җиңел түгел. Ләкин озак һәм җитди эшләү, иҗади эзләнү коллективка кыенлыкларны җиңәргә мөмкинлек бирде.

Юныс Фарсин, спектакльнең режиссеры, пенсионер.
«Хезмәт» (Мамадыш районы һәм шәһәре газетасы), 1967.

Иҗади уңыш

«Соңгы каракош» спектакленең бөтен уңышы – анда авторлар бирергә теләгән фикерләрнең тулы чагылдырылуында һәм чынбарлыкка охшатып бирелүендә.

Мулла кызы Суфия (башкара Эльмира Шәрифуллина) авылда укытучы булып эшли. Ул Хафизәнең (Рәйсә Хөсәенова) уң кулы. Бергәләп авылда мәктәп ачалар. Мәктәпкә 80 бала йөри. Шундый яңа тормыш башлаган йортка Гаяз (Зиннур Хәсәнов) кайтып төшә. Ак офицер Гаяз, кайту белән, авылда фетнә оештыра.

Икенче каракош – Карислам аркылы элекке хаким сыйныфларның кара эше чагыла. Карислам «коммунистларсыз Совет власте оештыру» турында уйлый. Ак офицер Гаяз белән ул, милли дошманлык тудыру максатыннан чыгып, рус авылларына – татарларны, татар авылларына русларны кертеп сугыш оештыру планын тәкъдим итә. Карарга чирканыч бу Карислам образын Алексей Никифоров әйбәт уйный.

Йосыф Хәнәфиев икейөзле Солтан образын бөтен тулылыгы белән бирергә тырышкан.

Әсәр яңа тамашачы күңелендә тирән эз калдырырлык. Бу спектакльне төрле профессиядәге иптәшләрдән төзегән үзешчән сәнгать коллективының зур иҗади уңышы дип бәяләргә кирәк.

*С.Хәйретдинов (Сәмигулла Хәйретдинов. – **Э.Ш.**).*
«Хезмәт», 1967.

Тамашачылар фикере

Пәрдә ачыла һәм сәхнәдә революция елларында барган кискен сыйнфый көрәш вакыйгалары башлана. Мамадыш Культура йорты үзешчәннәре «Соңгы каракош» спектаклендә бу көрәшне бөтен үткенлеге белән бирергә тырышканнар.

Әйтергә кирәк, моңа ирешкәннәр дә алар. Спектакльдә сыйнфый бәрелеш елларындагы кешеләрнең чын йөзе ачыла.

Абыйлы-сеңелле Гаяз белән Суфия – ике лагерь кешеләре. Ак офицер Гаяз һәм укытучы Суфия арасында килеп чыккан каршылык әсәргә зур драматизм бирә. Бу рольләрне башкарган Зиннур Хәсәнов һәм Эльмира Шәрифуллина шушы драматизмны тамашачыларга җиткерер өчен зур көч куйганнар, дип әйтәсе килә. Гаяз, максатына ирешү өчен, бернинди кабахәтлекләр алдында да тукталып калмый. Зиннур Хәсәнов аның омтылышына хас булган мәкерлелекне ачык штрихлар белән күрсәтә.

Карислам – үлеп баручы сыйныфның икенче вәкиле. «Коммунистларсыз Совет власте!» – дип кычкырып йөрүче бу кеше, иске дөньяны коткарып калу өчен, мөмкин булганның барысын да эшли. Алексей Никифоров Карисламның ерткычлыгын, ялагайлыгын ышандырырлык итеп бирә алган.

Солтан (Й.Хәнәфиев), Хафизә (Р.Хөсәенова), Әхмәт (З.Хәнәфиев), мулла (И.Бакиев), Сания (Н.Җиһаншина), Мостафа (М.Госманов) һәм башкалар образларны ачу өстендә эшләүгә зур тырышлык куйганнар.

Һәвәскәр художник Х.Ибраев тарафыннан эшләнгән дикорацияләр дә тамашачыларга зур тәэсир ясый, пьесаны яхшырак аңларга ярдәм итә. Юныс ага Фарсин җитәкчелегендәге бу коллектив зур иҗади уңышка ирешкән. Спектакльгә карата тамашачылар уңай фикерләр әйттеләр.

Ш.Рәхимов, китапханәче, Югары Ушмы авылы.
«Хезмәт», 1967.

Әсәр, чынлап та, тетрәндергеч иде. Ул тамашачыга көчле тәэсир итә, халык елап та, нәфрәтләнеп тә (хәтта репликалар кычкырып та) карый иде. Бу инде пьесаның тәҗрибәле кул белән язылуына үзе бер ныклы дәлил.

– Әдәбиятта бөтенләй диярлек яктыртылмаган бу канлы тарихны күтәреп чыккан кыю авторлар кемнәр икән? Тагын нинди әсәрләре бар? Аларын кайдан укырга була?.. – дип сорадык без режиссердан.

– Бөгелмәдән, ирле-хатынлы укытучылар, – диде Фарсин абый, – Фатыйма Бикчәнтәева һәм Абдулла Баһаветдиновлар. – Пьесаның исеме берничә, ахры, кайбер коллективлар «Каракош» дип тә уйнаганнар икән, – дип өстәде режиссер халыкта «Каракош явы» дип тә, «Кулаклар фетнәсе» дип тә йөртелгән фаҗига турында.

Арабызда югары белемле журналистлар, редакция тирәсендә шактый саллы

язучылар булса да, авторларның исем-фамилияләре арадан беребезгә дә таныш түгел иде. Фарсин абыйга биргән сораулар озакламый (минем өчен) тагын калкып чыкты. Алдарак әйтеп кителгәнчә, Фазыл Туйкин иҗатын ныклап өйрәнә башлагач. Әдәбият дөньясында, кайбер чыганаклар буенча, сәнәкчеләр фетнәсе турында ике пьесаның исеме мәгълүм: «Мәгариф корбаннары» һәм «Соңгы каракош» («Каракош»). Икесе ике әсәрме боларның? Икесен ике автор язганмы? Әллә?.. Эзләнүләрем дипломны яклаганнан соң да дәвам итте. Үзем катнашып уйнасам да, кулымда «Соңгы каракош» пьесасының тексты юк, хәтта үзем башкарган укытучы Суфиянныкы да сакланмаган. Мамадыш мәдәният йортыннан, спектакльдә бергә уйнаган Илдус абый Бакиевтан, Рәйсә Хөсәеновадан да эзләтеп карадым. Аларда да берни сакланмаган. Аннан Минзәлә театрына мөрәҗәгать иттем, хатыма мондый җавап килде:

«Мензелинский театр[1]
ДИРЕКТОР
Г.Мензелинск

№13

13 апреля 1974 г.

Хөрмәтле иптәш Эльмира!

Сез бу «Каракош» мәсьәләсе буенча Академия Наукка һәм авторларына мөрәҗәгать итегез.

Алар Сезгә тулырак җавап бирерләр.

Авторларының адресы: Г.Бугульма, ул.Коробковская, д.66, кв.5. Богоутдинов Абдулла һәм Бикчантаева.

Ихтирам белән театрның баш режиссеры: **Мулланур Мостафин**».

Конверттагы адрес: 423700, Мензелинск, ГДК.

Авторларның адресларын тапканнан соң, билгеле инде хатны Бөгелмәгә юлладым. Алардан кыска гына итеп язылган менә мондый хәбәр алдым:

«Хөрмәтле Эльмира туган![2]

Фазыл белән Кәбир Туйкиннар белән бергә эшләдем. Карашларын, иҗат әйберләрен беләм. Ләкин Фазыл аганың драматик әйберен укыганым юк. Үзеннән дә бу турыда сүз ишеткәнем булмады.

«Бу турыда матбугатта да сүз булган икән», – дисез. Бәхетсезлеккә каршы ул мәкалә белән мин таныш түгел. Нинди газета-журналда ул әйбер булган? Кайчан басылган? Шуларны табыгыз. Югыйсә бу хәбәрне берәр кешенең (алар бездә байтак) «үрдәге» итеп санарга туры килә.

Фазыл аганың кульязмалары, көнлек дәфтәре бергә эшләгән укытучыларның аның турындагы истәлекләре, укытучылар семинариясендә чыгарылган стена газетасында басылган әйберләре сездә бармы? 1929 нчы елга кадәр аның әйберләренә байтак кына рецензияләр басылды. Аларны таптыгызмы?

Эшегездә уңыш телибез.

Ихтирам белән: **Фатыйма, Габдулла**».

Конверттагы адрес: Бугульма, Ворошилова 18-5. Ф.Б.

Конверт мөһерендәге число: **24.04.74.**

[1] Хат Минзәлә театрының махсус бланкасына язылган.
[2] Хатта язылу вакыты күрсәтелмәгән.

Афиша

Эзләнү, хәбәрләшү туганнары белән дә дәвам итте.

«Эльмира туташ!

Сезне Җиңү бәйрәме белән тәбрик итеп, эшегездә зур уңышлар, тормышыгызда тынычлык, үзегезгә корычтай ныклы сәламәтлек, көзгедәй якты тормыш, бәхетле гомер теләп калучы Әхсән Хәсән углы Туйкин диеп белерсез.

Беренчедән, гафу итегез, Эльмира туташ, Сезнең хатыгызны күптән алсам да, шушы көнгәчә җавап яза алмадым. Сәбәбе: Сезне канәгатьләндерерлек җавап таба алмам микән дип йөрү иде.

Ләкин көттерүемнән уңа алмадым. Эзләгәннәрне таба алмадым. Гафу итегез.

Фазыл абый Туйкинның, сәнәкчеләр вәхшәте соңында, Карабаш авылында булган вакыйгаларга бәйле «Мәгариф корбаннары» дигән исем белән язылган бер сәхнә әсәре бар иде. Без шул ук әсәрне үзебез ике мәртәбә (соңгы мәртәбә 1934 ел январенда Зәй-Каратай мәктәбе сәхнәсендә) сәхнәдә уйнаган идек. Соңгы елларда минзәләлеләр күрсәтеп йөргән «Соңгы каракош» («Каракош») спектаклен Азнакайда карагач, мин аны уйнаучылар белән беседа ясадым. Шунда алар аның авторлары Бөгелмәдә яшәүче Бикчәнтәевләр икәнен әйттеләр. Ләкин мин алар янына бара да, аңлаша да алмадым. (Кыскасы, «Әдәбият караклары» белән гаугалашасым килмәде.) Матбугатта бу хакта сүз булуын белмим.

«Соңгы каракош» спектакленнән бер күренеш. Суфия ролендә – Э.Шәрифуллина, Гаяз ролендә – З.Хәсәнов. 1967 ел

Елын ачык хәтерләмим, 1960-1962 нче еллар тирәсендә, Башкортстаннан бер язучы (фамилиясен оныттым) Ф.Туйкин язмаларын, кайчандыр, кайсы журналларда, номер һәм даталары, битләре белән яки III класс укучылары өчен чыккан уку китабында (битләрен, елларын күрсәтеп) басылган нәрсәне күрсәтә дә: «Нигә сез мондый караклык белән шөгыльләнәсез?!» – дигән нәфрәт белдереп, «Социалистик Татарстан» газетасы битендә, Казанның бер язучысын каһәрләгән иде. Мин соңгы көннәрдә шушы нәрсәне эзләп, Сезгә хат яза алмый йөрдем.

1962 елгача Азнакай район газетасы «Коммуна» редакторы Зарипов хәзер Чаллыда партия работнигы икән. Ул аны хәтерлидер...

Бәширә, Шәфига, Сафия Туйкиналарда Фазыл абыйның кайбер кульязмалары бар икән дип ишеткән идем. Шулардан җавап көтәм. Ни килеп чыгар? Белмим.

Сезнең кулданиләр барлыгын да беләсе килә иде. Ничек аңлаша алырбыз икән?

Сүз күп иде. Хәзергә мохтасар калдык.

*Хат көтәм. (имза – **Э.Ш.) 3.05.74. Әхсән».***

Конверттагы адресы: 423300, р.п.Азнакаево, ул.Глинки 9, **Туйкин А.Х.**

Машинкада басылган, шәмәхә копировка аша чыгарылган «Соңгы каракош» пьесасын Казандагы халык иҗаты йортыннан алдым, дигән иде Фарсин абый. Шушы сүзгә таянып, Казандагы халык иҗаты йорты хезмәткәрләреннән берничә тапкыр сорап, эзләтеп карадым. Табылмады.

Өметсез шайтан ди, бәлки, бу язманы укыган берәрсенең колагына нинди дә булса хәбәр чалынмасмы?..

Әмма минем өчен әлеге эшләремнең иң зур нәтиҗәсе, иң олы табышым – агалы-энеле Кәбир һәм Фазыл Туйкин балаларының, туганнарының: «Сезнең «Казан утлары» журналының 1977 елгы 6 нчы санында газиз әтиләребез турындагы «Илебез – кадерле җиребез!» дигән язмагыз чыкканнан соң, без, «халык дошманы» балалары, турырак басып, башыбызны күтәребрәк йөри башладык, рәхмәт Сезгә!» – дигән хатлары, хәбәрләре булды. ■

КАРА ТӘКЪДИР

(Ачы язмышлы шәхесләр)

ДЕРЕН-АЙЕРЛЫ ОСМАН (1898-1929)

Кырымның Таврия губернасындагы Дерен-Айерлы авылында игенче гаиләсендә туган. Кырым АССР Совнаркомы рәисе (1924-1928).

«Татар милләтчелеге ул – изелгән милләтнең милләтчелеге», – дип әйтә торган булган Осман Дерен-Айерлы. Аның сүзен бераз үзгәртеп: «Милләтчелекне күрергә теләмисез икән, шовинизмны бетерегез!» – дип әйтергә кирәктер.

1930 елның 28 июлендә, милләтчелектә гаепләп, Османны үлемгә хөкем итәләр. Осман Абдул Гани Дерен-Айерлы 1949 елда туберкулездан вафат була.

ҖАМАНАКЛЫ МӘННАН (1916-1942)

Кырымтатар шагыйре. Кәрим Җаманаклының энесе. Хәрби диңгезче. Кара диңгездә хезмәт итә.

1942 елның сентябрендә Севастопопль өчен барган сугышта һәлак була.

ҖАМАНАКЛЫ КӘРИМ (1905-1965)

Кырымтатар шагыйре. Галим, остаз. Кырымда, Кизләү (Евпатория) янындагы Җаманак саласында туган.

1944 елда Кәрим милләттәшләре белән бергә Урта Азиягә сөрелә, бер ел Сәмәркандта яши. 1945 елда ул Татарстанның Алабуга каласында яшәргә рөхсәт ала. Кәрим Рәшит улы Җаманаклы (Рәшидов) 1965 елның 1 августында Алабуга шәһәрендә вафат була.

Дәвамы. Башы журналның 10 нчы (2020) санында.

ҖАУТҮБӘЛИ ЗИЯТДИН (1905-1991)

Кырымтатар шагыйре. Кырымда Керчь янындагы Җаутүбәли авылында игенче гаиләсендә туган.

Аны 1938 елда кулга алалар. 1946 елга чаклы ул ГУЛАГның төрле зинданнарында утыра. 1956 елда гына Зиятдин Җаутүбәли (Миңлегазизов) иреккә чыга. 1991 елның 16 июнендә Сәмәркандта вафат була.

ҖИҺАН НОГМАН ЧӘЛӘБИ (1885-1918)

Кырымтатар шагыйре. Сәясәтче, дәүләт эшлеклесе. Кырымдагы Бөек Сунакә саласында мулла гаиләсендә туган. Таврия мөфтие. Кырым Халык Демократик Хөкүмәтенең җитәкчесе.

Ногман Чәләби (Чәләбҗиһан) 1918 елның 26 гыйнварында кулга алына һәм 23 февральдә большевик матрослар тарафыннан судсыз-нисез үтерелә. Гәүдәсен Кара диңгезгә ташлыйлар.

ҖӘЛИЛ МУСА (1906-1944)

Татар шагыйре. Оренбург өлкәсенең Мостафа авылында игенче гаиләсендә туган. Советлар Берлеге Каһарманы (Советлар Союзы Герое).

Камалышта калып, әсирлеккә эләгә. Фашизмга каршы яшерен оешма төзи. Бер хаинның җиткерүе аркасында, әлеге оешма әгъзалары кулга алына. Мусага һәм аның аркадашларына Дрезденда Империя суды була. Ул унбер татар батырының да башын чабарга дигән хөкем карары чыгара. Әлеге карар 25 августта гамәлгә ашырыла.

ЗАКИРОВ ИСХАК (1911-1944)

Татар шагыйре. Казан шәһәрендә туган.

Исхак Закиров 1944 елның 14 июлендә Витебск өлкәсенең Городилово авылы тирәсендә ротасын һөҗүмгә күтәрә һәм дошман ныгытмаларына якынайганда каһарманнарча һәлак була.

*Текстны басмага **Рабит Батулла** әзерләде.* ■

Истә, һаман да истә!

Галим Вәли Хангилдинның тууына 130 ел



Тел галиме, педагог, ТАССРның атказанган фән эшлеклесе (1961) Вәли Нигъмәтулла улы Хангилдин 1891 елның 4 июнендә Уфа губернасының Бәләбәй өязендәге Иске Сынлы (Сынны) авылында туган.

1911-1914 нче елларда ул Уфаның «Галия» мәдрәсәсендә укый.

1920-1922 нче елларда – Екатеринбургтагы Татар-башкорт педагогика техникумында директор, 1923-1931 нче елларда – Уфада башкорт педтехникумында уку-укыту мөдире.

В.Хангилдин 1930 нчы елларда мәктәпләр өчен татар теле дәреслекләрен әзерләшә.

1943-1966 нчы елларда ул СССР ФА КФ Тел, әдәбият һәм тарих институтында эшли.

1942 елда Вәли Нигъмәтулла улы татар синтаксисына кагылышлы беренче диссертацияне Казан дәүләт университетында яза.

1959 елда В.Н.Хангилдинның «Татар теле грамматикасы (Морфология һәм синтаксис)» исемле монографиясе дөньяга чыга.

В.Хангилдин 1971 елның 2 июнендә вафат булды.

Язучы Гарәфи Хәсәновның тууына 100 ел

Язучы, 1974 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы Гарәфи Хәсәнов (Гарәфетдин Хәким улы Хәсәнов) 1921 елның 13 июнендә Казанда туган. 1940 елда ул Яңа бистәдәге 13 нче татар урта мәктәбен тәмамлый.

Г.Хәсәнов 10 яше тулар-тулмас ук яза башлый һәм 1932 елда «Яшь ленинчы» газетасында аның «Әй күңелле лагерьда» дигән беренче очерк-хикәясе басыла.

1942 елның 27 маенда ул, «милләтчел оешма әгъзасы» буларак, НКВД махсус киңәшмәсе тарафыннан 58-2, 58-10 ч.2, 58-11 статьялары буенча кулга алына. Красноярск краенда тоткынлыкта булганда, 1948 елда яңадан сөргенгә хөкем ителә. Красноярск краендагы Зур Улуй районының Симоново авылындагы балалар йортында һәм интернат-мәктәптә эшче, тәрбияче хезмәтендә була. 1955 елда җәза срогы 5 елга калдырыла. Гарәфетдин Хәсәнов шуннан соң амнистия буенча ирекккә чыга. 1990 елда тулысынча аклана.

1965 елда ул гаиләсе белән Казанга күчеп кайта һәм хезмәт эшчәнлеген дәвам иттерә.

1968 елда әдипнең табигатькә багышланган беренче мөстәкыйль китабы – «Унике батыр» исемле хикәяләр җыентыгы дөнья күрә. Шулай ук Г.Хәсәнов тәрҗемәсендә С.Михалковның «Три поросенка» («Өч дуңгыз баласы», 1935) әкияте, Н.Кононенконың «Маленькие испанцы» («Бәләкәй испаннар», 1937) хикәясе һәм Дж.Родариның «Чиполлино маҗаралары» китабы (1967) дөнья күрде.

Г.Хәсәнов 1992 елның 14 апрелендә вафат булды.

Шагыйрә
Роза Хәлиуллинаның
туына 90 ел

Шагыйрә, 1981 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы Роза Заһит кызы Хәлиуллина 1931 елның 14 июнендә Татарстанның Актаныш районындагы Әҗәкүл авылында туган.

Ул, җиденче сыйныфны тәмамлаганнан соң, Такталачык хастаханәсе каршында ачылган алты айлык курсларда укый һәм 1948 елга кадәр шул хастаханәдә күз авырулары буенча шәфкать туташы булып эшли.

1952-1956 нчы елларда Роза Хәлиуллина – медицина училищесы студенткасы. Училищены дәвалаучы акушер дипломы белән тәмамлап чыккач, ул озак еллар Казанның төрле медицина оешмаларында һәм сәнәгать предприятиеләрендә эшли.

Р.Хәлиуллина иҗат белән 1960 елда шөгыльләнә башлый. Шул вакыттан алып аның шигырьләре республика балалар газетасы «Яшь ленинчы»да, «Татарстан яшьләре» һәм «Социалистик Татарстан» газеталарында, «Ялкын», «Азат хатын» («Сөембикә») һәм «Казан утлары» журналларында еш басыла. Соңга таба шагыйрәнең аерым әсәрләре күмәк җыентыкларга кертелә («Беренче карлыгачлар», 1969; «Беренче адымнар», 1971; «Кызлар җыры», 1977; кечкенәләр өчен «Бөрлегәнгә медаль», 1973; «Чүкеч – нәни булышчы», 1977) кебек мөстәкыйль китаплар булып та чыга.

Р.Хәлиуллина 2014 елның 15 гыйнварында Казанда вафат булды.

Язучы
Габделхәй Сабитовның
туына 90 ел

Язучы, 1976 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы Габделхәй Вәли улы Сабитов 1931 елның 28 июнендә Минзәлә районының Югары Тәкермән авылында туган.

1949 елда Күзкәй урта мәктәбен тәмамлагач, Иске Мәлкән һәм Түбән Тәкермән мәктәпләрендә укыта, читтән торып, Казан дәүләт университетында, 1956-1960 нчы елларда Мәскәүдәге М.Горький исемендәге әдәбият институтында укый, соңыннан телестудиядә, «Ялкын» һәм «Чаян» журналлары редакцияләрендә эшли.

Габделхәй Сабитов, күп кенә хикәяләр язып, бу жанрның остасы булып танылды. Аның «Кичерелмәс гөнаһ», «Чулпан таңны уята» драмалары, «Мәхәббәт һәм нәфрәт» дигән комедиясе төрле сәхнәләрдә уйналды. Шулай ук ул – «Туган җир туфрагы», «Үлемсез Акылгали», «Карурманның күзләре бар», «Чулпан таңны уята», «Тармаклы яшен», «Айбаш» дигән китаплар авторы.

Эрих Распеның атаклы «Барон фон Мюнхгаузен маҗаралары»н, П.Л.Трэверсның «Мэри Поппинс», Феликс Зальтенның «Бемби» («Урман әкияте») повестьларын татар теленә ул тәрҗемә итте.

Г.Сабитов 1995 елда вафат булды һәм туган авылы зиратында җирләнде.

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Безнең мирас №6 июнь 2021

Матбугат һәм туган тел

Рүзәл Юсупов, филология фәннәре докторы

Хәзер шундый уңышсыз ясалган, аңлашылмый торган гайре табигый берничә сүзне анализлап, кайберләрен исемлек рәвешендә күрсәтеп китәрбез.

Газета-журналларда һәм тел белән эш ителгән башка өлкәләрдә кулланыла торган **ассызыклау** сүзен алып карыйк. Бу **подчеркнуть** сүзенең хәрефкә-хәреф тәрҗемәсе. Ләкин ул татар телендәге сүз ясалышы кагыйдәсенә (нормасына) туры килми һәм аның мәгънәсен дә аңларлык түгел. **Сызык** сүзенә **-ла** кушымчасы ялганып, яңа мәгънәле сүз ясап булмый: **сызыкла(у**) дигән сүз юк һәм була да алмый. Аны хәрефкә-хәреф тәрҗемә итәргә күнеккән каләм ияләре, кайчандыр *подчеркнут*ь мәгънәсен чын татарча итеп белдерә алмаганлыктан гаҗиз булып, шундый гарип сүз төзеп куйган булганнар һәм хәзерге журналистлар аны уңышлымы-юкмы, дөресме-түгелме икәнлегенә төшенеп тормыйча гына иркен кулланалар (алай эшләү инде гадәткә кергән).

Мәсьәләгә җитдирәк карасаң, татар телендә **подчеркнуть**ның нәрсәгә дә булса игътибар юнәлтеп, аның әһәмиятен аерып күрсәтү мәгънәсен белдерерлек чаралар бар, аларны эзләп таба белергә генә кирәк. Шунысы да бар: русча язучылар *подчеркнуть* сүзен күп очракта котылгысыз кирәкле сүз буларак түгел, *сказал, отметил* сүзләренең синонимы ролендә генә кулланалар. Шунлыктан, аның мәгънәсен бирү өчен, күбесенчә «ассызыклап» торасы юк, бәлки, **әйтте, дип әйтте, диде, сөйләде** кебек сүзләр генә куллану да җитә. Мәсәлән: «Фәрит Мөхәммәтшин аның тәҗрибәле булуын *ассызыклады*» (...тәҗрибәле булуына *игътибарын юнәлтте*); «Бу бик җитди сан, дип *ассызыклады* Тимур әфәнде» (... *дип әйтте* Тимур әфәнде); «Минтимер Шәймиев аның төп сыйфатларын *ассызыклады»* (... сыйфатларын *санап чыкты)*.

Ассызыклау кебек язмышлы сүзләрнең берсе – **дәүләтчелек. Государственность**ны калькалаштырып төзелгән бу сүз, матбугат телендә актив кулланылса да, татар теленең сүз ясалышы кагыйдәләренә туры килми, аның мәгънәсен дә кире русчага тәрҗемә итеп карасаң гына чамалап була. Безнең телдә **дәүләтчелек**нең нигезен тәшкил иткән *дәүләтче* дигән сүз юк, димәк, булмаган сүзгә кушымча ялгап, яңа сүз ясау да мөмкин түгел. *Дәүләт төзелеше, дәүләт оешмасы* мәгънәсендәге *государственность* (государственный строй, государственная организация) асылда *дәүләт* дигән сүз. Димәк, аны күп урында шулай, татар кешесе аңларлык итеп, дәүләт дип кенә атарга була. Мәгънәсен бөтен төгәллеге белән белдерү ихтыяҗы булганда, *дәүләт төзелеше* дияргә мөмкин. Мәсәлән: «Безнең илнең күп халыклары совет власте чорында милли дәүләтләрен булдыруга ирештеләр». *«Гали Акыш – татар халкының дәүләтчелеген торгызуда ярдәм итәргә тырышкан олуг зат»*. Җөмләне «... дәүләтен торгызуда ярдәм итәргә тырышкан олуг зат» дип төзесәң, мәгънә дә аңлаешлы һәм дөрес итеп белдереләчәк, татар теле дә бозылмаячак.

Деятельностьның уңышсыз калькасы булса да, хәзер **эш, гамәл, хезмәт** сүзләре урынында хаксыз еш кулланыла торган **эшчәнлек** сүзе бар. **Эшчән – хезмәт сөючән, тырыш** дигән сыйфат мәгънәсендәге сүз (эшчән кеше). Шуңа **-лек** кушымчасы ялганып ясалган **эшчәнлек** – *эшчән, тырыш, уңган* сыйфатына ия булу мәгънәсендәге абстракт исем. Ләкин ул, ниндидер сәбәпләр аркасында, матбугат телендә бик популяр булып китеп,

---

Ахыры. Башы журналның 5 нче (2021) санында.

хәзер кирәксә-кирәкмәсә, әйтелгәнчә, **эш, гамәл, хезмәт** урынында бик күп кулланыла: «*Галимнәр эшчәнлеге турында күпләр белми*» (дөресе – «Галимнәр эше турында...»); *«Эшчәнлегебезне өч юнәлештә алып барабыз...»* (Эшебезне өч юнәлештә алып барабыз); *«2018 ел эшчәнлегенә йомгак ясау»* (2018 елдагы эшкә йомгак ясау) һ.б.

Журналистлар – яңа сүз куллаңырга маһир халык. Бу, гомумән алганда, начар сыйфат түгел. Ләкин алар еш кына, теге яки бу яңалыкның файдалымы-юкмы, урынлымы-юкмы, ул дөрес сүзме-юкмы икәнлеген уйлап тормыйча, аны бик тиз кулланылышка кертеп җибәрәләр. Шундый ялгыш, сәер сүзләрнең берсе **– иң-иң(нәр).** Ул, текстан (сөйләмнән) аңлашылганча, **иң яхшы, иң уңган** һ.б. сыйфатларга ия затларны белдерә: «Ф.Мөхәммәтшин иң-иңнәргә дәүләт бүләкләре тапшырды»; «Бу залда иң-иңнәр утыра». Безнең телдә *иң-иң* – сыйфатның югары дәрәҗәсен белдерә торган кисәкчә сүз һәм аны исем ролендә йөртүнең берниндә дә хаҗәте юк.

Рус теленнән букваль (хәрефкә-хәреф) тәрҗемә итү кайчакта чамасыз дәрәҗәгә җитә: татар теленә оригиналның грамматик формаларын күчереп кую белән шөгыльләнә башлыйлар һәм нәтиҗәдә туган телнең табигый төзелешен бозарга керешәләр. Болай эшләү инде гафу ителерлек нәрсә түгел. Соңгы вакытларда бу хәл рус телендәге иркәләү-кечерәйтү суффиксларының функцияләрен (вазифаларын) татар теле исемнәренә тагуда ачык чагылыш таба. Рус сүзләрендәге иркәләү-кечерәйтү мәгънәсен аларның татар телендәге тәңгәллекләренә **-чык, -чек** кушымчасын ялгап белдерү гадәткә керә бара. Менә бу мисалларга игътибар итик:

«**Кызчык**ның мәктәптә киярга формасы юк»; «Минем өчен син һәрвакыт нәни **кызчыг**ым булып калырсың»; «**Кызчыклар** курчакларга киемнәрне үзләре тегә». Хәзер матбугатта күп очрый торган *кызчыклар* дөрес кулланылмый, әлбәттә. **Кызчык** татар теле өчен хас түгел.

Правнук (**правнучка)** мәгънәсен белдерү өчен ясалган **оныкчык** сүзен куллануны да аклап булмый. Аны оныкның баласы, кызы, улы дип әйтеп була һәм шулай әйтергә кирәк тә. Мәсәлән, «Камилә әби кызы, ике оныгы һәм оныкчыклары янында» дигән җөмләне, саф татарча итеп, болай төзергә кирәк: «Камилә әби кызы, ике оныгы һәм аларның (оныкларының) балалары янында».

Инде хәзер кайберәүләр өчен газеталарда **шәһәрчек, хикәячек, китапчык, мәйданчык** кебек сүзләрне куллану да (хәлбуки, бу ялгыш гамәл булса да) гаҗәп күренеш булып саналмый. «А.Хәбибуллин... Балашиха *шәһәрчегендә* яши»; «...нәтиҗәләрен *китапчык* итеп бастырып чыгарырга уйлыйбыз»; «11 *хикәячек* бу санда басылып та чыкты»; «... халыкара *мәйданчыкта*... кирәкле мәсьәләләр буенча фикер алыштык».

Хәзерге татар телен начар белгән журналистларның «новаторлыгы» аркасында телебездә **икетуган, туганнан туган** дигән сәер атамалар барлыкка килде: «Котдус абый – Чыңгыз Айтматовның әнисе Нәгыймә апа белән *икетуган*»; «Насыйбуллина Флераның *икетуган* сеңлесе Яруллина Асия...»; «Кызның *икетуган* апасы белән элемтәгә кердек»; «*Туганнан туган* апамны табарга булышты»; «Әтиемнең *туганнан туган* энесе Гаяз Семеновны җәзалап үтерделәр». Кемнәр була икән соң бу икетуган, туганнан туган кешеләр? Газета укучы ничек, кемнәр дип аңларга тиеш икән аларны? Аларны саф татарча һәм халык аңларлык итеп әйтергә (язарга) мөмкиндер бит! Әлбәттә, мөмкин. Моның өчен бары тик телне яхшы белергә һәм тырышыбрак эшләргә генә кирәк.

Кайбер журналистларның тел белән үзләренчә, белдекләләнеп, тел фәне кагыйдәләрен исәпкә алмыйча эш итүләре кирәксезгә, ягъни кулланылыштагы әдәби тел сүзе була торып, диалекталь (билгеле бер урында яшәүчеләр теленә генә хас) сүзләр куллануларында да күренә. Хәзерге матбугат хезмәткәрләре, мәсәлән, **арзан, арзанлы, арзанаю** сүзләрен онытып баралар булса кирәк: алар урынына **очсыз, очсызлы, очсызлану** сүзләрен куллану

гадәткә керә: «Монда бит бөтен әйбер **очсыз**» (дөресе – бөтен әйбер **арзан**).

Кайсыдыр каләм ияләренә **былчырак (пычрак)** сүзе ошамый: аны **саз** сүзе белән алмаштыралар: «Ник һаман да кешеләр саз ерып йөри?» (**былчырак** ерып йөри кирәк, сазны ерып йөреп булмый, анда батасың!)

Качу, тиз генә китеп бару урынына **таю, кинәт** урынына **кисәк, төп** урынына **төпкел** (күңел төпкелләре), **кармалау** урынына **кабалау** («Фермерның янчыгын кабалаучылар кимеми»), **икән** урынына **микән** («Нигә аларны эфирга чыгармыйлар микән?») кебек диалектизмнар куллану еш очрый газета битләрендә. Кайберәүләрнең тау ягы сөйләшенә хас **бармалы, кайтмалы** формалы сүзләр кулланып язулары да әдәби тел кануннарына туры килми. Матбугат билгеле бер район өчен генә түгел, бөтен татар халкы өчен бит, шулай булгач, аның теле дә һәркем аңларлык булырга тиеш ләбаса!

Газета журналистларының, телне куллануга җавапсыз карап, аны бозулары кирәксезгә рус сүзләреннән файдалануларында да чагылыш таба. Тел фәнендәге кагыйдә буенча тиешле төшенчәне, мәгънәне белдерергә туган телнең үз чаралары булмаган очракта гына кулланылышка алынма сүзләр кабул ителергә тиеш. Әмма газета чыгаручыларның кайберләре бу кагыйдәне яки бөтенләй исендә тотмый, яки белми: татар теленең үз сүзе булганда рус алынмасын кулланып яза. Мәсәлән: «Җәлил **подпольега** соңрак килгән» (татарчасы – «Җәлил яшерен оешмага соңрак кергән»); «Россия сырны... 10 тапкыр кимрәк **импортлаган**» («Россия сырны... чит илдән 10 тапкыр кимрәк **алган**»); «Нинди кухняны үз итәсең?» (Нинди ризыкларны (ашларны), кайсы милләт ризыкларын (ашларын) үз итәсең, яратасың?); «Владимир Путин кытай кухнясын ярата икән» (...кытай ризыкларын, ашларын ярата икән); «Әти-әниләрнең күбесе, форма алганда, **ретрога** өстенлек бирә» (...элекке фасоннарга (киемнәргә) өстенлек бирә); «Алар... **наив** рәвештә үзләрен дүртенче хакимият дип санадылар» (...Алар... самимилек (беркатлылык) белән үзләрен... санадылар); «...балалар **травмалары** 40 процентка кадәр арткан» (...балаларның имгәнүләре 40 процентка арткан); «Экология **катастрофасы**» (экология һәлакәте); «... немецларга плен төшә» (...әсирлеккә эләгә); «Хатирә әбинең иске өен күргәч, **шок булды**» (..өнсез калдым яки шаккаттым); «Россия икътисады яңа **шок халәте** көтәчәк» (...тагын бер тетрәнү кичерәчәк) һ.б.

Татар теле гыйлемендә хөкем сөргән рус алынма сүзләренең әйтелеше һәм язылышына караган кагыйдә буенча, 1920-1930 нчы еллардан, ягъни хәзерге татар теле формалашып, нормага салынып беткән чордан соң татар теленә рус алынмалары һәм интернациональ сүзләр, нигездә, чыганак телдәге әйтелеш һәм язылыш формасы белән, димәк, үзгәртелмичә үзләштерeләләр. Аңа да карамастан, кайбер журналистлар алынма сүзләрне үзләренең язмаларында яңадан «татарчалаштыру» белән шөгыльләнәләр. Хәзерге икетеллелек чорында мондый эш үзен акламый, әлбәттә. Берничә мисал: **тауар** (товар), **керәчен лампасы** (керосин лампасы); **нимес** (немец); **җәгърәфия** (география); **сәвит халкы** (совет халкы); **кампитр** (компьютер); **крәстиән** (крестьян); **пәлтә** (пальто); **кәчтүм** (костюм); **кәтлит** (котлет); **кәнфит** (конфет); **йогырт** (йогурт), **фәйләсуф** (философ); **тупыйк** (тупик) һ.б.

Матбугат теле дөрес, үтемле, тәэсирле булсын өчен, анда сүзләрнең стиль үзенчәлекләренең исәпкә алынуы да әһәмиятле. Сүзләрнең, лексик мәгънәләреннән тыш, стилистик мәгънә төсмерләре дә була һәм сөйләмнең камиллегенә, эчтәлекнең төгәллегенә ирешүдә шуларны да белеп эш итү мөһим. Безнең газета материалларында кайчакта тел кулланылышының бу ягына игътибар җитеп бетми. Һәркайсыбызга бик мәгълүм **чәчәк** һәм **чәчкә** сүзләрен алып карыйк. Болар төп мәгънәләре белән бер үк сүзләр. Әмма кулланылыш үзенчәлекләре буенча бер-берсеннән берникадәр аерылалар: **чәчәк** телебезнең барлык стильләрендә дә кулланыла торган гомуми кулланылышлы

сүз, **чәчкә** исә, нигездә, гади сөйләмдә, шигъриятттә кулланыла, ләкин аны рәсми стильдә, иҗтимагый-сәяси, фәнни-техник эчтәлекле материалларда куллану урынлы булмый. Димәк, дәүләт, хөкүмәт органы – республика газетасындагы җитди эчтәлекле хәбәрдә «Казан **чәчкәләргә** күмелә, **чәчкә савытлары** арта» дип язуны хуплап булмый (дөресе – Казан **чәчәк**ләргә күмелә, **чәчәк савытлары** арта).

«Штраф **чәпәячәкләр**» (газетадагы хәбәр исеме). Бу контекстта **чәпи** (гади сөйләм сүзе) һич кенә дә урынлы түгел.

«**Көчсезләргә** ярдәм итү» (**хәлсезләргә** ярдәм итү кирәктер); «10 минуттан артыграк басып тору **җилкәнең кирәген бирергә** мөмкин» (**кирәген бирү** дөрес кулланылмый, **зыян китерә, эштән чыгара** кирәк); «**Карт арысланның китүе»** (Нурсолтан Назарбаев турында болай әйтү – зур тупаслык); «Татарстан мәктәпләреннән татар телен **куып чыгарырга** җыенган...» (**телне куып чыгару** дип әйтү килешми: кысрыклап чыгару дисәң, дөресрәк булыр) һ.б.

Телнең, гомумән алганда, артык сүзләре булмый. Шулай да кайбер очракларда һәм кайбер урыннарда сүзне кирәксез, артык куллану күренеше бар.

«Артык» сүзләрнең иң күп һәм иң мәгънәсез кулланылганнары – **булып тора** һәм **булган**. «...республика Россиядә иң алга киткән төбәкләрнең берсе **булып тора**», «Ул регби буенча Латвия командасының баш тренеры **булып тора**». Нигә кирәге бар бу җөмләләрдә **булып тора**ларның?

«Халкыбызга хас **булган** сабыр холык, түземлелек», «Татар теле өчен хас **булган** авазларны дөрес итеп әйтергә өйрәтү», «Безнең өчен мөһим **булган** бу вакыйга», «Рус милләтеннән **булган** кыз (**рус кызы** дисәң, аның кайсы милләттән булуы аңлашылмыймы икәнни?). Бу җөмләләрдә **булып тора** һәм **булган** сүзләренең һич кирәксезлеге көн кебек ачык.

«...**Туган телгә карата мәхәббәте** көннән-көн үсә бара аның» (...**туган телне яратуы** көннән-көн арта бара аның булса, татарча дөресрәк булыр).

«Россия пенсия фондының Татарстан буенча **бүлекчәсе**» тәгъбирен «...Татарстан **бүлеге**» дисәң, татарча табигыйрак булыр иде.

«Артык» сүзләрнең күбесе рус теле сүзләрен ялгыш хәрефкә-хәреф тәрҗемә итү аркасында барлыкка килә. Мәсәлән, **булып тора – является** сүзенең, **карата – по отношению** тәгъбиренең калькалары. Урынсыз кулланылган кереш сүзләр дә – русчадан буквальтәрҗемәләр. Мәсәлән: «Бездә гигантомания – киң таралган күренеш. Гигант, әмма, гафу итегез, импотент». (Монда **простите**ның калькасы **гафу итегез**нең ни кирәге бар?) «Ул заманнардан соң, **кем әйтмешли,** күпме сулар акты...» (**Кем әйтмешли** (**как говорится** калькасы) нигә кирәк булды икән?)

«...Үлемсез әсәрләр тудыру – зур батырлык, әйтергә яраса, феноменаль күренеш» (**әйтергә яраса** – артык).

«**Нәрсә-нәрсә**, татар матбугаты болай да тышауланган иде» (**нәрсә-нәрсә** – русчадагы **что-что**ның бу урында бөтенләй кирәксез калькасы).

Матбугат теленең лексика өлкәсенә караган проблемалары фразеологизмнар дип аталган күчерелмә мәгънәле, образлы тәгъбирләрне куллануда да чагылыш табалар. Бу өлкәдәге сәер күренешләр дә, нигездә, рус теле чараларын дөрес тәрҗемә итә белмәү аркасында килеп чыгалар. Тәгаен итеп әйткәндә, рус фразеологизмнарын еш кына хәрефкә-хәреф тәрҗемә итү аркасында татар теле өчен табигый булмаган, кытыршы, гарип гыйбарәләр барлыкка килә. Матбугатта очрый торган шундый берничә фразеологик берәмлекне карап китик.

«***Күсәк белән оҗмахка кумыйлар» – «В рай дубинкой не загоняют»*** фразеологизмының хәрефкә-хәреф тәрҗемәсе татар теле өчен табигый әйтем түгел.

«**Ак көнләшү белән көнләшү»** дә уңышлы төзелмәгән, татарлар өчен көнләшүнең агы да, карасы да булмый. Көнләшү ул – татарларда тискәре күренеш. Русларның **белая зависть** мәгънәсен татарча күбрәк **кызыгу** сүзе белдерә, башка чаралар да бардыр.

Русчадан калька **бармак аша карау** фразеологиясен да уңышлы ясалган дип әйтеп булмый.

Матбугат телендә күптән кулланылып килгән **мәсьәләне кабыргасы белән кую** тәгъбирен «мәсьәләне кискен итеп кую яки җитди итеп кую» рәвешендә куллану максатка ярашлы булыр иде.

«**Кәгазьсез син бөҗәк кенә**» («Без бумажки ты букашка»ның букваль тәрҗемәсе) тәгъбирен «Кәгазьсез беркая да бара алмыйсың», «Кәгазьсез берни дә эшләп булмый» кебегрәк итеп төзергә кирәк иде.

«Сез үз тәлинкәгездә түгел идегез» («Вы были не в своей тарелке»ның сүзгә-сүз, хәрефкә-хәреф тәрҗемәсе) шулай ук оригинал мәгънәсен дә белдерми.

Язма телдә дә, сөйләм телендә дә киң таралган «**Бәйрәм белән! Яңа ел белән!»** кебек тәгъбирләр – шулай ук русчадан уңышсыз калькалар. Алар чын татарча «Бәйрәм котлы булсын! Яңа ел (бәйрәм) мөбарәк булсын! Бәйрәм белән котлыйм (тәбриклим)!» рәвешендә булырга тиешләр.

Мисаллардан күренгәнчә, рус теле фразеологизмнары татарчага һәрвакытта да образлы тотрыклы берәмлекләр белән тәрҗемә ителмиләр. Журналистлар моны исләрендә тотсыннар иде.

Дөрес сөйләмгә ирешү, фәнни итеп әйткәндә, сөйләм культурасын саклау өчен, фигыль сүз төркеменә кергән сүзләрне дөрес куллану әһәмиятле. Хәлбуки, безнең бүгенге телебездә, шул исәптән матбугат телендә дә, бу мәсьәләдә проблемалар шактый күп.

Хикмәт шунда: татар теле фигыльләренең күп төрле формалары һәм аларның, һәркайсының төп лексик-грамматик мәгънәләреннән тыш, төрле мәгънә төсмерләре бар. Үткән заман хикәя фигыльләренең генә дә **барды, барган, бара иде, барган иде, барган була (булган), бара торган иде, бара торган була (булган), барганым бар, барганым(ң) бар иде** формалары кулланыла.

Журналистлар менә шушы үткән заман хикәя фигыльләрен һәм сыйфат фигыльләрне кулланганда күп ялгышлар җибәрәләр. Алар күп төрле, шуңа күрә монда, барысын да сөйләп тормыйча, бер-икесен – аеруча киң таралганнарын гына әйтеп китик.

-ды, -де (-ты, -те) кушымчалы билгеле үткән заман хикәя фигыльләре эш-хәлне (процессны) язучы, сөйләүче үзе күргән очракта кулланыла: «Мин кичә театрга бардым».

-ган, -гән (-кан, -кән) кушымчалы билгесез үткән заман хикәя фигыльләре процессны сөйләүче (язучы), үзе күрмичә, башка кешедән ишетеп, укып, радио-телевидениедән ишетеп-күреп сөйләгәндә кулланыла: «Кичә Мәскәүдә боз яуган».

Әмма каләм ияләре, гадәттә, барлык очракларда да диярлек **-ды, -де (-ты, -те)** кушымчалы үткән заман хикәя фигыльләрен генә файдаланалар: «Әби патша татарларга… таш мәчетләр салырга **рөхсәт бирде**» (**рөхсәт биргән** кирәк); Америка астронавтлары берничә тапкыр айга менеп **төштеләр** (…айга менеп **төшкәннәр** булырга тиеш).

Фигыльләрнең мондый кызыклы һәм четерекле үзенчәлеге дә бар: процесс гамәлгә ашырылганда сөйләүче (язучы) үзе булып та, ул аны сизми калса, процесс субъектның ихтыярыннан башка гамәлгә ашырылса, фигыльләрнең **-ган, -гән (-кан, -кән)** кушымчалы төрләре кулланыла. Республика газетасындагы бер мәкаләнең исеме «**Утырттым да оныттым диярлек булмасын».** Мондый җөмләдә фигыль **онытканмын** формасында булырга тиеш.

Татар теленең аналитик фигыль формалары процесс башкарылуның күп төрле дәрәҗәләре: дәвамлылык, кинәтлек, әкренлек һәм башка төрле мәгънәләрен белдерә

алалар. Бу үзенчәлекләрне белеп куллану сөйләмне җанлырак, бизәклерәк итәргә мөмкинлек бирә. Ләкин практикада әлеге бай мөмкинлекләр тулы файдаланылмый. Фигыльләре дөрес кулланылмаган җөмләгә бер мисал: «Эшмәкәр, әледән-әле авылга кайтып, якташларының хәлләрен белешә, һәркемгә булыша» («...хәлләрен белешеп, һәркемгә **булышып тора**» кирәк): **тора** ярдәмче сүзе белән ясалган фигыльләр дәвамлылыкны белдерәләр (белешеп, булышып тора).

Матбугат материалларында телнең бозылуы сыйфат фигыльләр дип атала торган сүзләрне куллануда да ачык күренә: монда да, телдән файдалануның башка өлкәләрендәге кебек, элементар хаталар хөкем сөрә. Фикеребезне кайбер мисалларны анализлау җирлегендә расларга тырышып карыйк (мисаллар бер газетаның соңгы саннарыннан алынды).

«Россиядә ел башыннан **үлүчеләр** саны 32 мең кешегә кимегән». Монда сүз үлеп ятучылар турында түгел, үлгән кешеләр турында бара бит, шулай булгач, **үлүчеләр саны** дип әйтү ялгыш, **үлгәннәр** яки **үлгән кешеләр саны** дияргә кирәк.

«Беренче турдан **узучылар** редакциягә әңгәмәгә чакырыла» (Беренче турдан **узганнар**...).

Мондый мисаллар газеталарда йөзләрчә, меңнәрчә. Димәк, журналистларның күбесе **-учы, -үче** формалы хәзерге заман сыйфат фигыль белән **-ган, -гән (-кан, -кән)** кушымчалы үткән заман сыйфат фигыльләренең аермасын белмиләр: һәрвакыт **-учы, -үче** формалы фигыльләрне генә кулланалар.

Ниһаять, газета-журналлар телендәге проблемаларга караган тагын бер мәсьәлә ул – җөмләдәге сүз тәртибе. Мәгълүм булганча, сүзләр сөйләмдә билгеле бер тәртиптә урнашалар: һәр сүзнең үз урыны бар. Каләм иясе, сүз остасы, сөйләм камил булсын өчен, язганда һәм сөйләгәндә сүзләрнең урнашу тәртибен сакларга тиеш. Ул тәртип бозылса, сөйләм дә ямьсезләнә, кытыршылана, мәгънә дә тоныклана, бозыла. Менә бер җөмләне укып карыйк: «**Зәп-зәңгәр**, **озын кара керфекләр** белән каймаланган нур чәчеп торган күзләр дисеңме... – бар да килешле». Бу җөмләдә **зәп-зәңгәр** сүзе ялгыш урынга куелган булу аркасында сөйләмдәге фикерне аңлау кыенлаша: **зәп-зәңгәр, күзләргә** караганлыктан, шул сүз алдыннан куелырга тиеш, ә ул җөмләнең башында ук куелган. Җөмлә «Озын кара керфекләр белән каймаланган, нур чәчеп торган **зәп-зәңгәр күзләр** дисеңме...» рәвешендә булырга тиеш.

Бу җөмләдә, шулай ук сүзләр дөрес урнаштырылмау аркасында, җитди мәгънә ялгышы килеп чыккан: «Донецк Халык Республикасы вәкилләре **40 тапкыр ут ачмау килешүен бозды**». «**Ут ачмау килешүен 40 тапкыр бозды**» дип әйтәсе урында «40 тапкыр ут ачмау...» булып чыккан.

Сүз тәртибенә караган тагын бер ялгыш: безнең каләм ияләре аныклаулы мөнәсәбәттәге ике сүздән торган сүзтезмәләрдә, рус теленә ияреп, ялгыш аныклаучы компонентны аныкланмыштан соң куялар: «**Галим-тюрколог** Әхмәт Зәки Вәлиди хезмәтләре...». Дөресе – «**Тюрколог-галим**... Вәлиди хезмәтләре». Чагыштыру өчен: **Гали-итекче** түгел, **итекче Гали**, **галим-телче** түгел, **телче галим.**

Сүз тәртибенә караган гасырлык тупас ялгыш – сәгать исәбен әйтү. Безнең журналистлар, шулай ук русча сүз тәртибенә ияреп, чын татарча итеп, **сәгать 10, унынчы 25 минут, ун тулырга 5 минут** рәвешендә язасы, әйтәсе урында **10 сәгать, 9 сәгать 25 минут** һ.б. өлгесен кулланалар.

Сүзебезне йомгаклап әйткәндә шул: бүгенге матбугат язмаларында туган телебезне тупас бозып куллану күренешләре зур урын алып тора. Чаң сугып, ашыгыч рәвештә тиешле чаралар күрелмәсә, татар матбугаты теле тагын да ныграк корама-калька теленә әверелә баруын дәвам иттерәчәк. ■

Онытылмасын Гай бабай

Әхтәм Зарипов

Гай Таһиров

«Гай бабай» дигәнем – татар милләтенең беренче профессиональ балетмейстеры, беренче балетыбыз «Шүрәле»не сәхнәгә куючы балетмейстерларның берсе, Опера һәм балет театрының беренче директоры, «Татар биюе» һәм «15 татар биюе» дигән китаплар, бию сәнгатенә караган 40 исемдәге мәкалә һәм рецензияләр авторы, 1938 елдан алып төрле театрларда 400гә якын оригиналь биюләр куючы оста. Гай Таһировның Опера һәм балет театрлары сәхнәсендә куйган – 35, Г.Камал театры сәхнәсендә куелган спектакльләрдә – 37 оригиналь биюен, Татар җыр һәм бию ансамблендә – 60, Минзәлә күчмә театрында һәм мәдәният сарайларында куелганнарыннан тыш, Чуаш, Азәрбайҗан, Мари, Удмурт Җыр һәм бию ансамбльләрендә, Игорь Моисеев ансамблендә язмалары һәм турыдан-туры катнашында куелган биюләрен дә санаганда, аларның саны 500гә җитә. Театрларга, сәнгать сарайларына тамаша кылырга чакырган төрле афишаларда, режиссерның исем-фамилиясе белән беррәттән, балетмейстерныкы – Гай Таһиров та тора. Ул – Гайнулла Хаҗимөхәммәт улы Таһировның замана модасына ияреп үзгәрткән исеме. Балет сәнгатеннән ерак булганнарның бүген бу исемнәрнең икесен дә белмәүләре гаеп түгел.

2017 елның декабрь аенда аның тууына – 110, 2022 елның декабрендә – 115, 2027 елда 120 ел тулуны билгеләп үтүчеләр табылу ихтималы бар, әлбәттә. 1995

елның сентябрь аенда бакыйлыкка күчкән татар милли бию сәнгатен нигезләүче, милли балетыбызның бабасы, Идел буе милләтләренең бию үрнәкләрен махсус язмада калдырган бердәнбер һөнәрман, бик кызганыч булса да, онытылуга таба бара шикелле. Мәдәният институтының рәхмәтле белгечләре тырышлыгы белән гомеренең 60 елын милли бию сәнгатен саклап калуга һәм үстерүгә, аның өчен профессиональ белгечләр әзерләүгә багышлаган Гай бабабыз иҗатын пропагандалау буенча фәнни-гамәли конференцияләр үткәрелсә дә, остазның дәрәҗәләрәк чараларга да лаек булуы бәхәссез хакыйкать.

Муса Җәлил исемендәге Опера һәм балет академия театрының артындагы мәйданга татар милләтенең горурлыгына – Рудольф Нуриевка һәйкәл куелган. Милләтең кем, дигән сорау бирелгәндә татар димәсә дә, без аның белән мактанабыз. Опера һәм балет академия театрыбызга каршы як мәйданда «Ленин» дигән «сәнгатькяр» һәйкәле «мәңгелек»кә басканлыктан, татар милли балет сәнгатенең аталары Фәрит Яруллин белән Гай Таһировның, мәрмәр истәлек тактасына урын табылса, милләтебез бик рәхмәтле булыр иде.

Гайнулла Хаҗимөхәммәт улы Таһиров Кемерово өлкәсенең төрле милләт вәкилләре төзегән һәм яшәгән Анжеро-Судженск дигән ташкүмер чыгаручылар шәһәрендә туып-үсә.

1925-1928 нче елларда ул, Казанга килеп, театр техникумында һәм балет студиясендә укый. Укуын тәмамлагач, иҗади хезмәт юлын Татар дәүләт академия театрында биюче артист һәм хореограф буларак башлый. Шунда ук аның татар театрының иң чибәр артисткасы Галимә апа Ибраһимова белән кушылган булуы ихтимал. Чөнки җитәкчелек Галимә апаны да, Гай абыйны да Мәскәүгә укуларын дәвам итеп, һөнәрләрен камилләштерергә җибәрә. Галимә апа драма артистлыгы буенча белемен үстерсә, Гай абый исә Зур театр каршындагы хореография училищесында осталыгын шомарта. Мәгълүм булганча, 1933-1938 нче еллар – татар операсының беренче һөнәрманнарының белем өстәп йөргән чаклары. Укуларын тәмамлагач, алар, бергәләп, яңа оешкан Опера һәм балет театрына эшкә кайталар. Шул кайтуыннан Гайнулла Таһиров балет труппасында артист, баш балетмейстер һәм директор буларак эшләп, 1952 елда Татарстан Җыр һәм бию ансамбленә баш балетмейстер вазыйфасына күчә һәм 1972 елга кадәр шунда иҗат итә. Казан Мәдәният институты ачылгач, Гай Хаҗиевич яңа институтта бию-балет сәнгатенә белгечләр әзерли, Идел буе халыкларының биюләре буенча сабаклар бирә.

Аның озакка сузылган укытучылык еллары, Галимә Ибраһимова белән тормышлары, гарип булып туган кызларын тәрбияләп үстерүләре, ул баланың республикада тамак авыруларын дәвалаучы бердәнбер мәшһүр табиб булып җитлегүе, соңыннан өчесенең дә фаҗигале үлемгә дучар булулары хакында мин «Сөембикә» журналында (12 нче сан (2019)) «Чибәрлек – кешенең сыңар канаты» дигән мәкалә бастырган идем. «Онытылмасын Гай бабай» дигән бу мәкаләмне Гай Таһиров белән аның үлеме алдыннан булган соңгы очрашуым тәэсиреннән язам. Ул очрашуга мин, әлбәттә, соңгысы булыр дип бармаган идем. Ниятем – бу серле гаилә турында китап язу өчен мәгълүматларымны арттырып, мәхәббәтсез яшәп мәрхүм булган парларның фаҗигале тормышлары белән тәфсиллерәк таныштырырга теләү иде. Бу ниятемнең мәхәббәтсез яшәгәннәр, яратышып яшәмәгәннәр дигән гөнаһлы уйларга нигезләнгән булуын аңламаганлыгыма хәзер генә төшендем шикелле. Шулай, Галимә апаны да, аларның кызлары табибә Флүрәне дә җирләгәч, останың хәленә керергә, хәсрәтен аз булса да, уртаклашып җиңеләйтергә дип, ялгыз калган Гай абый Таһиров фатирына килдем. Ләкин

көткән истәлек-хәбәрләр урынына мин Гай бабай авызыннан зарлану сүзләре генә ишеттем. Әлбәттә, бу сүзләр язмышыннан зарлану түгел, ә балет-бию сәнгатендәге бүгенге җитешсезлекләргә кагылышлы иде. Ул, күрешеп сүзебез башлану белән, афишаларга төрелгән язмаларын тартмадан алып алдыма салды да: «Мә, укы, таныш, аңла һәм телевидениенең баш режиссеры, күп телефильмнар авторы буларак, үз карарыңны әйт. Фикереңне түгел. Мине синең фикерең түгел, ә нинди карарга килүең кызыксындыра…» – диде.

…Мин, әлбәттә, ык-мык килеп, аптырап калуымны сиздерергә тырыштым. Шуннан соң ул, дилбегәне үз кулына алып, алдымда яткан язмаларны аңлатырга кереште:

– Менә бу иероглифлар – минем «Шүрәле» балетының махсус язмалары һәм ноталары.

– «Шүрәле» балетын мин үзебезнең театр куелышында гына түгел, ә башка театрлар сәхнәләштерүендә дә карадым бит, Гай абый.

– Син караган «Шүрәле» балеты партитурасы түгел бу. Болар – балалар өчен үзем язган башка балет иероглифлары.

– Син «Шүрәле» балетының соавторымыни?

– Зур театр училищесында укыганда, безгә, курс эше буларак, балет либреттосы язу бурычы куелды. Мин әллә кая барып тормадым – тоттым да Тукайның «Шүрәле»се буенча либретто «әмәлләп», аңа безнең белән бер чорда укыган Нәҗип Җиһановтан музыкасын язуын үтендем. Нәҗип ялындырмады, эшне тиз тотты. Әнә күр: Нәҗип үз кулы белән язган ноталар алдыңда ята. Укы да, баш режиссер булуыңны күрсәтеп, шул шедеврны телевидениедә куйдыр. Мин әле үз көчемдә. Ярдәм итәрмен.

– Гай абый, син ялгышасың. Телевидениедә баш режиссерның андый вәкаләтләре юк. Ул – кушканны үтәргә тиешле бер солдат кына.

– Ярый, балалар балетын куйдыра алмадың, ди. Күр әнә, алдыңда «Фатихның төше» дигән өр-яңа оригиналь балетның партитурасы һәм либреттосы ята. Куйдыр шуны! Миңа акчасы түгел, исән чагымда куелуы кирәк. Числосына игътибар ит: балалар балеты 1937 елда язылса, «Фатихның төше» аннан аз гына соңрак. Шуннан бирле куйдырам дип хыялланам. Әлбәттә, бу балет либреттосы һәм партитурасы хәзерге авторлар эшеннән нык аерыладыр. Әмма мин, автор, әлегә исән бит! Ничек кирәк шулай үзгәртү минем көчемнән килмәс эш түгел. Тәвәккәллик!

– Булмый, Гай абый, безнең телевидение, сәнгатькә хезмәт итүдән бигрәк, хакимияткә хезмәт итүе белән генә яши.

– Хакимияткә хезмәт милләткә хезмәт түгел бит, энем.

– Беләбез дә, белә торып бөләбез дә шул, абзый.

– Бик кызганыч…

…Гаҗәеп бай фантазияле, бию сәнгатендәге табышлары белән Идел буе халыкларының мәхәббәтен яулаган остаз либреттоларының һәркайсына тукталып, аңлатмалар биреп китү минем көчтән килә торган эш түгел. Игътибарыбызны партитура һәм либреттолардан аның кайбер кульъязмаларына юнәлтәбез. Менә караламадагы бер кульъязма. Ул чордагы Мәдәният министрына җибәрелгән хатның күчермә нөсхәсе (черновигы) икән.

– Җавап килдеме? – дип сораганымны сизми дә калдым.

Гай абыйның җавабы гыйбрәтле иде:

– Кайсы түрәне «үзе җавап бирә иде» дип әйтергә була?» Юк бездә кешечә сөйләшә белгән түрәләр. Аларның һәркайсы үзләренең түрә статусын саклау

белән генә мәшгуль. Сәнгатькә җитәкчелек итүче вак түрәләр дә, алар үрнәгендә җитәкчелек итеп, плагиатлык белән шөгыльләнергә юл куялар. Әллә кая барасы юк: минем ничә биюем, аз гына үзгәрткән кебек итеп, башка балетмейстер исеме белән тәкъдим ителә. Укы әнә, бу мәкаләм минем шул башбаштаклыклар турында.

– Үзгәртергә, төзәтергә көчемнән килмәгәч, аны укып эч пошырудан кемгә файда, Гай абый…

– Бөтен бәла әнә шул һәрнәрсәдән файда эзләүгә генә кайтып кала шул…

– Файдасыз дөнья зыян китергәнгә, «хәйләсез – дөнья файдасыз», дип аклаңалар.

– Кызганыч, мин аклана да, саклана да белмәдем. Теләмәдем дә.

…Яшермим, Гай бабайдан минем адреска тәнкыйть сүзләре күп әйтелде. Алар белән килешсәм дә, кабул итмәгән кебегрәк тәэсир калдырырга тырыштым. Янәсе, заман башка, сәнгать тә яңачарак, сәнгатькярләр дә таләпчәнрәк.

Талантның кайчан да талант булуы хакындагы, таланттан һәрчак сәнгать кенә таләп ителүе турындагы фикердән качарга тырыштык. Дөнья төрле талантлар һәм төрле холыклы кешеләр булуы белән кызыклы дигән фикергә килеп аерылыштык. Озакламый мин аның да фаҗигале үлеме турында ишеттем. Нихәл итмәк кирәк… «Булганны сакламыйбыз, югалткач үкенәбез», – дип кабатларга гына кала.

«Талантлар авылда туа, шәһәрдә үлә», – диләр. Гай абый – Анжеро-Судженск дигән шахтерлар шәһәрендә туып-үскән талант. Бу шәһәр Теодор Драйзер повестенда да телгә алынган, ул төрле җирләрдән, төрле илләрдән килгән халыклар төзеп яшәгән шәһәр.

«Халык» дигән төшенчә – бик күп милләтләрне үзенә сыйдыра торган төшенчә. Анжеро-Судженск шәһәрендә яшәүче милләтләрнең вәкилләре шахтада бергә булсалар да, җир өстенә чыккач, һәркайсының үз дөньясы, үз теле, үз сәнгате, үз милләтенең йолалары, гореф-гадәтләре, уеннары, җыр-биюләре. Гайнулла Хаҗимөхәммәт улы шул төрлелекләр белән аралашып, төрле милләт яшьләре белән гореф-гадәт, йолалар уртаклашып үскән егет. Ул, үскәндә, татарларны үз иткән удмурт, мари, чуаш яшьләре белән якын мөгамәләдә булып, аларның җыр-биюләрен, уен үзенчәлекләрен, йолаларын яхшы белүе профессиональ үсешендә әһәмиятле роль уйнаган булуы, төрле милләтләрнең бию аерымлыкларын күрсәткән язмаларында чагылыш табуы бик табигый. Бердәнбер кызы нәсел калдырмый фаҗигале үлемгә дучар булганлыктан, Гай аганың мирасын барлап, киләсе буыннарга калдырыр варисы юклыктан, аның язмаларын архивка тапшыру эшен рәхмәтле шәкертләре башкара. Ул, һичшиксез, бик зур әһәмияткә ия, милләтебез рәхмәтенә лаеклы эш. Әмма ярты эш. Тулы эш булсын өчен, шул архив материалларын шәрехләп милләтебезгә ирештерү, әлеге дә баягы, шәкертләренә кайтып кала.

Аның өчен остазның кульъязмаларын, либретто һәм партитураларын хәзергечә күздән кичереп, заманча редакцияләп, аерым бер китап итеп бастырып чыгарырга кирәк.

Милли сәнгатебезгә ихтыяҗ арткан елларда булмас эш түгел бу. Тәвәккәллек һәм ихлас теләктәшлек кенә кирәк. Әлеге сыйфатлар исә остаздан шәкертләренә мул күчкән.

Онытылмасын Гай бабай, дибез икән, бу фикер аның китабын чыгару белән расланырга тиешлеге бәхәссез хакыйкать. ■

ТАТАР ҖЫРЧЫЛАРЫ. КАДЕРЛЕ МИЗГЕЛЛӘР

• Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Клара Хәйретдинова нәкъ Казан артында – Биектау районының Өнсә авылында дөньяга килгән. Җәйнең уртасында – шаулап аткан чәчәкләргә, «мине өз» дип мөлдерәп торган җиләкләргә мул вакытта тугангадыр – аннан һәрчак зиннәтле купшылык бөркелеп тора. Атлаганда да үз дәрәҗәсен белеп атлаган, әйтер сүзен сайлаганда да аны адресатына һичшиксез барып җитәрлеген тапкан ханым ул. Клара ханым белән аралашкан бернечә дистә елда мин аның киң күңеллелегенә, юкка-барга вакланмаучан холкына, ханбикәләргә хас көязлегенә сокланам.

Сабакташларның Тукай әдәби музеенда очрашуы. 2019 ел

Мәскәүдә Бөтенсоюз эстрада сәнгате иҗат остаханәсендә укып кайткан яшьләр, Камал театрына Щепкин училищесын тәмамлап кайткан артистлар кебек үк, шаулы, данлы буын. Барысы да гомерләрен эстрада сәнгатенә багышлады. 2019 елда Тукай әдәби музеенда әлеге төркемнең Мәскәүдә укый башлавына 50 ел тулуны бәйрәм иттек. Ул истәлекле очрашуда яшьләрне 1969 елда укырга туплап җибәргән легендар шәхес Мәхмүт ага Нигъмәтҗанов та бар иде.

СССР Үзәк мәдәният хезмәткәрләре йорты. Сулдан уңга: Эльба Закирова, Мөнир Мөхәмматҗанов, Виктор Шәрәфетдинов, Нәзифә Кәримова, Татьяна Романова, Клара Хәйретдинова. Мәскәү, 1970 ел

Клара Әкъргам кызы Хәйретдинова 1997 елдан Казан дәүләт консерваториясенең җыр кафедрасында вокал буенча педагог, доцент. Шулай ук Ильяс Әүхәдиев исемендәге Казан музыка көллиятендә дә укыта. Мөгаллимнәр һәм талантлы шәкертләр, гомумән, тәҗрибәсе булган күп җырчылар бу хакта хыялланадыр. Клара ханымның горурланырлык шәкертләре аз түгел. Мәсәлән, Артур Исламов, Илүсә Хуҗина, Айгөл Хисмәтуллина, Роман Байлов, Айгөл Гардисламова, Эльвира Авзалова, Алсинә Җәгъфәрова, Диләрә Палатова, Аршак Алтунян, Энҗе Шәймурзина, Диләрә Төхвәтуллина. Татар сәхнәсенә чын осталарны чын осталар гына үстерә ала!

1994 елда Клара Хәйретдинова Венециянең атаклы «Ля Фениче» театрында җырлый. Әлеге данлыклы залда чыгыш ясаган беренче Татарстан җырчысы ул. Клара ханым талантлы, тырыш, үзе кебек үк затлы кыз үстерде. Кызы Самира Латыйп Казан дәүләт консерваториясенең хор-дирижерлык факультетын тәмамлаган. Хәзер Мәскәүдә «Орфей» классик музыка радиосында музыкаль тапшырулар, Мәскәү консерваториясенең Зур залында, Мәскәүнең халыкара Музыка йортында һәм башка күп кенә дәрәҗәле залларда концертлар алып бара, эстрада җырчысы буларак танылган.

Оныгы Сабина музыка мәктәбенең фортепиано классын тәмамлаган. Хәзер Мәскәүдә Россиянең иң алдынгы университетларының берсе – Югары экономика мәктәбендә анимация режиссеры белгечлеге буенча белем ала.

Мәскәүдә укып кайтканнан соң, Клара Хәйретдинова Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең әдәби-музыкаль лекторий бүлеге солист-вокалисты булып эшли башлый. Соңрак Казан консерваториясенә В.А.Лазько классына укырга керә һәм аны 1979 елда тәмамлый. Филармониядә Клара Хәйретдинова 1980 елга кадәр эшли. 1980-2006 нчы елларда – ул инде М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры солисты.

Журналга ***Зимфира Гыйльметдинова*** *әзерләде.* ■

Җуелмас хәзинә

«Баламишкин» җыры

«Халык җырлары безнең киләчәктә мәйданга киләчәк әдәбиятымызга, бер дә шөбһәсез, нигез булачактыр».

Габдулла Тукай

Баламишкин

(Татар халык җыры)

Ват, җимер коймасын,
Юлга атын куймасын;
Кызлы кеше кызын тыйсын,
Егетләрне тыймасын.

Әнкәй миңа хат язган,
Утын бетте, кайт, диеп.
Хатка каршы хатлар яздым,
Өй почмагын сат, диеп.

Зимагур булды башларым,
Бер нужа да күрмәдем.
Караңгы төн, ява яңгыр,
Өстемдә бер күлмәгем.

Халык арасында бик популяр булган «Баламишкин» – зимагурлар җыры.

Халык бу көйгә төрле сүзләр, башка строфалар да иҗат иткән. Аның берничә тексты барлыгы билгеле. «Баламишкин» революциягә кадәр үк татарлар арасында бик популяр булган.

Узган заманнарда татар ир-егетләре бәхет, мал, байлык эзләп, озын һәм кыен юллар үтеп, хәтта чит илләргә кадәр барып чыкканнар. Бу турыда тарихи мәгълүматлар шактый. Туган авылларын, йорт-җирләрен, гаиләләрен һәм сөйгән ярларын калдырып бәхет эзләргә киткәннәрнең йөрәк сагышлары, сагыну хисләре, эчке кичерешләре аларның үзләре тарафыннан иҗат ителгән җырларда чагылыш тапкан. ***«Туган җирне сагыну, аны калдырып китүкә үкенү, ачыргалану, ялгызлыктан моңаю – бу төркем җырларның төп мотивларыннан берсе»,*** – дип яза фольклорчы-галим **Илбарис Надиров.** Ул зимагур сүзен рус телендәге ике сүзнең җыелмасы дип карый, ягъни, «зима-горе».

Зимагур җәен азмы-күпме акча эшли, тамак та тук, өс тә бөтен. Сезонлы эшләр беткәнче, зимагур «байларча» яши. Аннан соң, эшләр бетеп кышка кергәч, акча

Жырчы, «Татар жыры» конкурсы лауреаты Рәяз Фасыйхов

табу кыенлаша. Шулай итеп, бар чагында бүредәй, юк чагында шүредәй яшәргә күнеккән кешеләр өчен кыш бик рәхәт булмаган, чыннан да, кайгы булган икән.

Тышкы кыяфәте белән дә, эчке кичерешләре белән дә истә калырлык ул. Аягында чабата, башында озын чәч, киемнәре тузып беткән. Дөнья малына ул «фани мал» дип, акчага «кырчын ташы» (ягъни корчаңгыдан дәвалау өчен файдаланыла торган таш) дип карый. Бар тапканын ашап-эчеп бетерә, аңа «диңгез тубыктан».

Зимагурга бунтарьлык хас. Җәмгыять тәртипләренә ризасызлык та белдерә ул. Шул ук вакытта оптимист та. Дөньядан ваз кичеп, күңел төшенкелегенә бирелеп кайгы-сагышта утырырга да җыенмый. Горур да ул. Туган илен сагынса да, аның бу хәлендә иленә кайтасы килми.

Бу җыр җырчы Рәяз Фасыйхов репертуарында бар.



«Баламишкин» җырының нотасы

(Сәхифә «Тәртип» радиосында яңгыраган «Саф вә раушан күзге» тапшыруы материаллары нигезендә әзерләнде. Тапшыруның авторы һәм алып баручысы – Гөлфия Мөхәммәтгәрәева.) ■

Милли музейда – ПЕ-2 самолеты

1992 елда ПЕ-2 самолетының бәреп төшерелгән урыны табылды. «Сокол» эзтабарлар отряды Ленинград белән Новгород өлкәсе чигендәге тирән упкында самолет калдыкларына тап була. Җаен бу урыннарга керү мөмкин булмау сәбәпле, эзтабарлар ике кыш дәвамында чокырдан самолет һәм һәлак булган экипаж әгъзаларының мәет калдыкларын чыгара. Кызганыч, бу вакытта нинди дә булса документлар табылмый. Самолетның сакланып калган фрагментында 70х70 мм размерлы Кызыл Йолдыз бар. Димәк, һәлакәткә кадәр экипаж һава сугышында яхшы нәтиҗәләр күрсәткән һәм дәүләт бүләгенә лаек булган.

2007 елда эзтабарлар очкыч төшкән урынга янә берничә мәртәбә барып, экипажның элегрәк табылмаган мәет калдыкларына, самолет (13/15) һәм аның моторының (М-105 №РА 125-475) номерларына юлыга. Оборона министрлыгының Үзәк архив материалларыннан 1941 елның 20 декабрендә шушы номерлы самолетның 116 нчы аерым армия авиация күзәтү эскадрильясе составында булуы ачыклана.

20 елга якын барган тикшерү эшләреннән соң шундый мәгълүмат табыла: «1942 елның 8 гыйнварында 13/15 номерлы ПЕ-2 самолеты сугышчан биремне үтәү өчен җибәрелә һәм үз аэродромына әйләнеп кайтмый. Экипаж: очучы, кече лейтенант Лихачев Леонид Васильевич, очучы-күзәтүче, лейтенант Кузнецов Степан Петрович һәм атучы-радист, сержант Дианов Анатолий Николаевич».



Чудово-Тосно-Новгород төбәгендә сугышчан бирем үтәлә һәм самолет кайту ягына юл тота. Аннан соңгы вакыйгалар барышы турында архив документлары сөйли. 54 нче немец Люфтваффе эскадрильясенең оператив сводкасыннан аңлашылганча, алар тимер юл районында саклап озатучыларсыз гына рус бомбардировщигы очуы турында хәбәр ала. Лейтенант Ханс Йоахим Хайер самолеты совет очкычын бәреп төшерү өчен һавага күтәрелә: сугыш башлана. Күрәсең, очучы Лихачев атучы-радист өчен уңайлы һөҗүм урыны сайларга тырышкан, әмма немец очучысы читкә тайпылырга өлгергән һәм, пулеметтан ут ачып, совет очкычының ягулык багын тишкән. Пе-2нең сул як двигателе яна башлаган. Очучы самолетны аэродромга алып барып җиткерергә тырышкан, әмма моңа бер двигательнең генә көче җитмәгән. Ут ялкыны экипаж кабинасына үрмәләгән. Икенче атуында Хайер рус очучысын җәрәхәтли. Шулай итеп, экипаж янып баручы очкычны ташлап чыгарлык хәлдә булмый. Самолетның, бик нык селкетә башлау сәбәпле, бер канаты каерылып төшә. Нәтиҗәдә, ул, штопорга кереп, кисәк кенә аска ыргыла һәм зур тизлектә кипкән сазлык өстенә барып төшә.

1942 елның 8 гыйнварында 10 сәгать 12 минутта лейтенант Хайер радиоэлемтә буенча совет бомбардировщигын бәреп төшерүе турында хәбәр итә. Бу – ПЕ-2 самолетының фактик һәлак булу вакыты. Ләкин дошманнан да үч алына! 320 сугышчан очыш ясап, 53 мәртәбә җиңүгә ирешкән, Тимер рыцарь тәресен алган немец очучысы Хайер шул ук елның 9 ноябрендә совет самолеты белән бәрелештә һәлак була.

ПЕ-2 самолетының двигателе Милли музейга «Ватан» берләшмәсе тарафыннан тапшырылды. Аның белән Бөек Ватан сугышы музеена килеп таныша аласыз.

*Журналга **Ленар Нәгыймов** әзерләде.* ■

Көлке куа килә...

Гамил Афзал (1921-2003)

Сәхипҗамал әбинең уйлары

Кияүләргә барып чыгам
Бал калагы яларга;
Киленнәргә барып керсәм,
Бала бирә карарга.

Кияү бирде чәен, балын,
Шикәрен дә, борыч та.
Өйгә кайтсам, килен килгән
Ярма сорап бурычка.

Күзге катык, көмеш кашык
Киявем белән кызыма.
Язгы катык, ярык кашык
Киленем белән улыма.

1955

Туфан Миңнуллин (1935-2012)

Туфан Миңнуллин.
Н.Хаҗиәхмәт шаржы

Клава апа кайда?

1948-1950 нче еллар. Олы Мәрәтхуҗа авылында үзешчәннәр куйган спектакль бара. «Артистлар» – сәхнәдә, суфлер – сәхнә артында. Баш рольне башкаручы Шәһит «Клава апа да шунда» дигән реплика әйтергә тиеш. Суфлер шул сүзләрне сәхнә артыннан пышылдый. Әмма Шәһит ишетми. Суфлер кат-кат кабатлый. Шәһит, ниһаять, «ишетә» һәм: «Кладовай башында», – дип әйтеп куя.

Шамил Маннап (1938-2012)

«Авыр туфрагың җиңел булсын!»

Мәгълүм ки, халыкка дача өчен җирнең юньлесен бирми хөкүмәт. Йә ул элеккеге карьер булыр, яки сазлык. Яисә чокыр-чакыр. Андый җирне алдыңмы инде, гомер буе туфрак ташып чиләнәсең.

Әнә, язучыларның «Весна» дип аталган дачалар җиреннән элек кирпеч заводы өчен сары балчык чыгарганнар. Хәзер инде, киресенчә, шундагы үз җиренә һәркем үзе булдыра алганча балчык-туфрак ташый.

Хәкимҗан Халиков урман туфрагын зур биштәргә тутырып, аркасына асып ташый.

Беркөнне аңа каршы Габделхәй Сабитов очрый.

– Авыр туфрагың җиңел булсын, Хәкимҗан дус! – дип «куәт бирә» ул.

Хәкимҗан маңгаендагы борчак-борчак тирне учы белән сөртә:

– Сүзең хак, кордаш. Эшләр болай барса, мондагы күп язучыга синеңчә сәлам бирергә туры килмәгәе...

Тәлгат Нәҗмиев (1950-2014)

Яңасына кирәк

Мансур абый Закиров Авыл Советы рәисе булып эшләгәндә Сабаның Тимершык ягында яңа зират ачылып, искесе ябылды. Шуннан берәү, моңа килеп:

– Мансур абый, абыстай үлде, иске зиратка күмик әле, – дип рөхсәт сораган.

Рәис коры гына:

– Булмый. Абыстай яңа зиратка кирәк! – дигән.

Роберт Миңнуллин (1948-2020)

Язучылар берлегенең идарә утырышында

Берлек рәисе Илфак Ибраһимов идарә әгъзаларының кворумын барлап чыга.

– Вахит Имамов утырышта катнаша алмый. Ул, машинасы ватылып, кире Чаллыга кайтып киткән.

Роберт Миңнуллин сорап куйган:

– Ватылган машина белән ничек кайтып киткән соң ул?

...Рәис бу сорауга җавап бирә алмаган.

Роберт Миңнуллин.
Ф.Вахитов шаржы

Сәхифәне ***Ләбиб Лерон*** *әзерләде.* ■

Безнең мирас №6 июнь 2021

Без барыбыз да – балачактан

«Балачак мирасы» сәхифәсе – иң әүвәл сезнең өчен, өлкәннәр. Халкыбызның күңел җәүһәрләрен – такмак-такмазаларны, табышмак-башваткычларны, әкиятләрне, әдипләребезнең хикмәтле һәм гыйбрәтле, мәгънәви һәм тәрбияви әсәрләрен хәтерегезгә сеңдерегез, аларны озын-озакка сузмыйча, балаларыгызга һәм оныкларыгызга җиткерегез, нәниләргә бишек җырларын көйләргә дә онытмагыз. Кыскасы, укыгыз, уйланыгыз һәм бер нәтиҗә ясагыз да... һәрвакыт безнең «Балачак мирасы» белән бергә булыгыз!

Сафа Гыйльфан (1902-1950)

Уф, ардык!

Йөгердек,
Сикердек,
Уйнадык,
Бакчада
Саф һава
Суладык,
Уф, ардык!

Шакмаклар,
Тартмалар
Өйгәләп,
Биналар
Ясадык
Бергәләп,
Уф, ардык!

Өч сәгать
Шауладык,
Гөж иттек,
Инде ял
Сәгате
Дә җитте,
Уф, ардык!

Без тагын
Торгачтын
Уйнарбыз,
Бакчада
Саф һава
Суларбыз,
Уф, ардык!

Җырладык,
Биедек,
Куандык,
Хәрефләр
Тезгәләп
Юандык,
Уф, ардык!

Ашадык
Тәмле аш,
Күмәчләр,
Чәй эчтек
Шикәрләп
Һәм сөтләп,
Уф, ардык!

Ял өчен
Бер сәгать
Күп вакыт,
Әйдәгез,
Сөйләшми
Тын ятыйк!
Уф, ардык!

Ә хәзер
Әйдәгез,
Тиз тыныйк,
Йокыга
Китәбез,
Күз йомыйк,
Уф, ардык!

Куркак юлдаш

(Татар халык әкияте)

Элекке заманда ике кеше юлга чыккан. Боларга зур урман аркылы үтәргә туры килгән. Урманга керүләре булган, боларның каршысына кинәт кенә бер аю килеп чыккан. Моны күргәч, бу ике адәмнең берсе, бик куркып, агач башына менеп качкан. Икенчесе, үлгәнгә сабышып, тиз генә сузылып яткан.

Аю, юлда яткан әлеге кеше янында әйләнә-әйләнә, башларын, аякларын иснәгән дә, тимичә-кагылмыйча, үз юлына киткән ди.

Аю киткәннән соң, агач башындагысы төшеп, иптәшеннән сораган:

– Аю синең колагыңа шыпырт кына нәрсә әйтте? – дигән.

Җирдә ятканы әйткән:

– Аю миңа, юлга чыксаң, иптәшең үзеңнән батыррак булсын, дип әйтте, – дигән.

Тургай ни дип сайрый?

(Сайравыч)

Чепи чапуш, пуш,
Әйдә гөрле бән пуш, пуш,
Дәрдән кошы, дәрдән кошы,
Моксаләфин,
Сәүсәкинә,
Пүсәкинә,
Топиһу-трр-пррр!..

Әниләргә һәм нәниләргә

Бишек җыры

Әлли-бәлли, бәбкәсе,
Бадъян агач сиртмәсе.
Май китерер әбисе,
Бал китерер бабасы.

Әлли-бәлли итәргә
Ал бишеге бар аның.
Алдында йоклатырга
Үз әбисе бар аның.

Ал бишеге бар аның,
Гөл бишеге бар аның.
Өзгәләнеп сөяргә
Үз әнисе бар аның.

Әлли-бәлли, бәбкәсе,
Кая киткән әнкәсе?
Каенлыкка җиләккә,
Бәбкәенә бүләккә.

Сәхифәне ***Ләбиб Лерон*** *әзерләде.* ■

МАЙ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында

● Күренекле милләттәшебез, профессор, Татарстан фәннәр академиясенең Галимҗан Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институтының шәрәфле әгъзасы, «Азатлык» радиосының элекке хезмәткәре, татар-төрек галиме Надир Дәүләт 76 яшендә вафат булды. Ул 1 майда Истанбул шәһәрендәге Фәрикөй зиратында – әти-әнисе кабере янында җирләнде.

● 3 майда мөселман дин эшлекләләре, имамнар, мөгаллимнәр, зыялылар, татар җәмәгатьчелеге Казан шәһәренең Яңа бистә зиратына остазларны искә алу чарасына җыелды. Беренче булып татар халкының йөзек кашлары булган шәхесләр – тарихчы-галим Миркасыйм Госманов, җырчы Илһам Шакиров, драматург Туфан Миңнуллин, шагыйрь Хәсән Туфан турындагы хатирәләр яңартылды. Алга таба Әдмәдзәки хәзрәт Сафиуллин, Зәкәрия хәзрәт Минвәлиев, кабере быел яңа табылган шәех Мөхәммәд Гали ишан, Казанның соңгы ишаны Гарифулла хәзрәт Гайфуллинга туктальп, аларның тормыш юллары бәян кылынды. Аннары зиратның үзәк өлешендә – Габдулла Тукай кабере тирәсендә дәфен кылынган олпат затлар – мөгаллим, мөдәррис Шәйхелислам Хәмиди, мәгърифәтче, журналист һәм нашир Әхмәдһади Максуди, күренекле дин галиме Галимҗан Баруди, язучы Фатих Әмирхан, меценат, Мәрҗанинең шәкерте Мөхәммәдсадыйк хәзрәт Галикәев һ.б. янына тукталдылар. Аннары Каюм Насыйри, Габделхак Саматов, Маһруй Мозаффария һ.б. мәгърифәтче галимнәр, имамнар, мөгаллимнәр һәм меценатларның каберләре зиярәт кылынып, барлык катнашучылар Шиһабетдин Мәрҗани кабере янына җыелды. Биредә Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсәнең чыгарылыш курс шәкерте, Коръән-хафиз Камил Мостафин «Тәбарәк» сүрәсен укыды һәм Ильяс хәзрәт Җиһаншин зиярәт кылынган барлык мәрхүмнәрнең рухлары шат булуын, соңгы урыннары җәннәттә булуын сорап дога кылды. Шул ук көнне Казандагы Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәчеттә ифтар узды.

● 4 майда күренекле музыка белгече, РФнең һәм ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе Йолдыз Нәкый кызы Исәнбәт вафат булды. Мәрхүмәнең җәсәде Яңа Татар бистәсе зиратында җирләнде.

● 5 майда «Миллият йорты» кафесында «Безнең мирас» журналы редакциясе, матбугат һәм радио-телевидение әһелләрен, республикабызда чыккан газета-журналларның баш

мөхәррирләрен, танылган журналистларны, галимнәрне, язучыларны, сәнгатькярләрне чакырып, ифтар уздырды. Ифтар вакытында соңгы елларда вафат булган күренекле шәхесләребез рухына дога кылынды.

● 8 майда татар зыялылары «Сәйяр» беренче татар труппасының сәнгать җитәкчесе, татар профессиональ театрына нигез салучыларның берсе, күренекле артист, талантлы режиссер, оештыручы һәм җәмәгать эшлеклесе Габдулла Кариевның (1886-1920) тууына 135 ел тулуны билгеләп үтте. Алар Яңа Татар бистәсе зиратында могтәбәр шәхесебез каберенә чәчәкләр куйдылар һәм рухына дога кылдылар.

● 11 майда «Казан Экспо»ның Халыкара күргәзмәләр залында, Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнеханов катнашында, IX Республикакүләм ифтар узды.

● 14 майда Нижневартовскиның А.С.Пушкин исемендәге 1 нче лицеенда татар телен өйрәтү буенча өченче сыйныф ачылды. Анда лицей укучылары гына түгел, якын-тирә микрорайоннарда яшәүче балалар да үз туган телен үзләштерәчәк. Балаларга татар телен башлангыч сыйныфлар укытучысы өйрәтәчәк. Ул Казан федераль университетында махсус

курслар узган, татар теле һәм әдәбияты укытучысы дипломын алган. Балалар туган телне аның авторлык методикасы буенча өйрәнәчәк. Әлеге сыйныфны ачуда Нижневартовск шәһәренең «Мирас» Татар милли-мәдәни автономиясе иҗтимагый оешмасы рәисе Рафаил Мөхәммәтҗанов башлап йөргән. Моннан ике ел элек җәмәгатьчелек инициативасы белән шәһәрнең 8 нче мәктәбендә татар телен өйрәтү буенча икенче сыйныф ачылган иде.

● 17 майда Татарстан Республикасы мәдәният министры Ирада Әюпова Россиядә яңа төзелгән Мәдәни инициативалар Президент фондының Россия Федерациясе Президенты грантлары конкурсларын үткәрү буенча координация комитеты әгъзасы итеп сайланды. Комитет рәисе итеп Россия Федерациясе Президенты Администрациясе җитәкчесе Сергей Кириенко билгеләнгән. Комитет әгъзалары арасында РФ мәдәният министры Ольга Любимова, «Беренче канал»ның генераль директоры Константин Эрнст һәм башкалар бар. Ирада Әюпова – комитет әгъзалары арасында бердәнбер төбәк мәдәният министры. ■

МИРАСВОРД

Надир ... (татар галиме)

Сирия каласы

Тур Хейердал көймәсе

Композитор ... Яхин

Драматург Гамир ...

Рахит (иск.)

Фәнзаман Баттал туган авыл

Иван Крылов повесте

Шагыйрь Хәсән ..., драматург ... Миңнуллин

Ялтыравык тасма

Фин-угыр халкы

Эре бөртекле әйберләрне төеп ваклау өчен махсус савыт

Ингушетия мәркәзе

... Емельянов (керәшен татар шагыйре)

Кирәй ... (башкорт әдибе)

Гарәп илләрендә – вак акча

Зиннур Мансуровның 1988 елда чыккан шигырьләр-поэмалар китабы

Давыт ... (татар шагыйре, тәрҗемәче)

... Барбюс

Кытай фәлсәфәсендәге категория

Дирижер костюмы

Удмуртларның элекке исеме

Печелгән дөя

Буддистлар гыйбадәтханәсе

Гаскәрнең ачык һавада куну яки ял итү урыны

Гайсин, Баян, Әхмәдиев

Шагыйрь Наис ...

Ашлык, кибәк ташу өчен кабыктан ясалган зур әрҗә

Мәдинә Маликова романы

Нотык, чыгыш (диал.)

Язучы, «Онытылмас еллар» трилогиясе авторы

VII-XI гасырларда Азиядә яшәгән төрки телле кабиләләр

Хәким Хәйруллин романы

Нәсел-...

Сәгыйть ... (башкорт язучысы)



...-ера

... Мөхәммәд хан

Васко ... Гама

Спектакль, кино, концерт турында язма игълан

... Думбадзе (грузин язучысы)

... Исхакый

5 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:
Сулдан уңга: Хәсни, «Дуга», Даль, ым, Нәкыя, Лазо, Максуд, шәт, «Идегәй», Вафа, Ройс, яга, йог, сака, сакс, тальян, Өнәр, күмә, Расих, Ләбибә, нар, аул, Такташ.
Өстән аска: Сөн, өндәмә, озан, Акатуй, кәз, кыл, СССР, Ильясов, Мәүла, аак, ук, Дифгат, Ринат, дая, Акаба, Иделле, Рәсүл, Гыйльми, угыз, хәя, АМО, йөгән.

Рәис Габдулла төзеде. ■

«Безнең мирас»

елъязмасы / июнь

Ает авылындагы (Башкортстан) Фатих Кәрим музее

825 ел элек (1196)

Бөек Болгар дәүләтенең күренекле галиме, болгар-татар язма тарих белеменә нигез салучы Якуб ибне Ногман «Болгар тарихы» исемле хезмәтен тәмамлый. Бу хакта галим вә сәяхәтче Әбу Хәмид әл-Гарнати язмаларында бәян ителә.

635 ел элек (1386)

Хәзерге Иран биләмәләрендә җитди яу-орыш алып барган Аксак Тимер берочтан бүгенге Грузия җирләрен дә басып ала, Алан капкасы дип йөртелгән Дарьял тарлавыгына вә янә бүтән әһәмиятле урыннарга үз яугирләрен урнаштыра. Шулай итеп, Туктамыш хан гаскәрләренә юл бикләнә.

155 ел элек (1866)

Казанда шәһәр почтасы оештырыла.

115 ел элек (1906)

Баку шәһәрендә «Рәһбәр» («Юл күрсәтүче») исеме белән атналык әдәби журнал нәшер ителә башлый. Мөхәррире – Мәхмүд Мәхмүдбәков.

100 ел элек (1921)

5 июньдә Уфа каласында Габдулла Тукай исемендәге клуб эшли башлый.

85 ел элек (1936)

22 июньдә Казанда күренекле тел галиме Гыйбад Алпаров (1888-1936) вафат була.

65 ел элек (1956)

«Совет әдәбияты» журналының июнь ае санында Абдулла Алишның концлагерьда һәм фашист төрмәсендә язылган шигырьләре дөнья күрә.

50 ел элек (1971)

19 июньдә Башкортстанның Бишбүләк районындагы Ает авылында Фатих Кәрим музее ачыла.

*Журналга **Марат Закир** әзерләде.* ■

Содержание. Июнь 2021

И останется в мире слово моё...: Габдулхай Сабитов.

Историческое наследие: «Шакирды, не будьте равнодушны!». Р.Марданов; «Нижневартовские татары». Ф.Байрамова; «Первые Сабантуи в ТАССР». Р.Шарафиева и Л.Губайдуллин.

Татарский мир: «Низменность реки Ик – неизведанная история». А.Бурханов.

Религиозное наследие: «Исламский мир». Габдурашит Ибрагимов; «Утямышево: религиозное движение». Н.Исхаков, Р.Исхакова.

В глубинах памяти: «Наследники дедушки Муслим». Р.Хабибуллина; «Сохрани как память обо мне!». Э.Салахова; «В памяти, до сих пор в памяти!».

Слово – украшение языка: «Пресса и родной язык». Р.Юсупов.

Художественное наследие: «Нельзя забыть Гай бабай». А.Зарипов; «Татарские певцы. Дорогие мгновения». З.Гильмутдинова.

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

Алхәбәр:



1737 елгы картада Мөслим авылы
(«Мөслимгә кайчан нигез салынган?». *Р.Мәсәгутов*)

- **«Милләтне җитештерүчеләр – аналардыр». Ләлә Мортазина**
- **Хәсән Туфан һәм Сирин. Әнвәр Шәрипов**
- **Әнвәр Гобәйдуллин рухына бер догам. Әхтәм Зарипов**
- **Мөслимгә кайчан нигез салынган? Руслан Мәсәгутов**
- **Әдип Маликов хатлары. Эльмира Шәрифуллина**

Габделхәй Сабитов — фотоларда

Унсигез яшьлек Габделхәй

Язучы Якуб Зәнкиевләрдә кунакта: Габделхәй Сабитов (басып төшкән), Якуб Зәнкиев, аның хатыны Рәшидә, Фәтхия Сабитова (Г.Сабитовның хатыны). Түбыл шәһәре. 1986 ел, 5 август

Ык елгасы буенда гаиләләр белән ял иткән мәл. Уңда – Габделхәй Сабитов кызы Зөлфия белән, Фасил Әхмәтов, Мирсәет Яруллин. 1971 ел

Г.Сабитов апасы Рәшидә белән. 1980 ел, сентябрь

«Ялкын» журналы редакциясендә эшләгән вакыт. Габделхәй Сабитов белән Илдар Юзеев Мамадышта укучылар белән очрашуда. 1964 ел, октябрь

Туганнар җыелган чак. 1970 ел, 4 гыйнвар

БИЛ АЛЫША ТАТАР ИРЛӘРЕ

Арча районының Кызылъяр авылы көрәшчеләре. Фото «Казан арты» тарих-этнография музее фондыннан алынды.

Владимир Васильев фотосы / Татар-информ

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – П2343
РОССИЯДӘ – П7074
beznenmiras.ru

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
журналына башкача язылу:

- *uslugi.tatarstan.ru* сайты ярдәмендә
- редакциядә
- *podpiska.pochta.ru* сайты ярдәмендә электрон версия

4 612750 670172

«БЕЗНЕҢ МИРАС» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 51), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.